Гадел Кутуй

САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

Гадел Кутуй



Гадел Кутуй

САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

ТАТАРСТАН
КИТАП
НӘШРИЯТЫ
1965

С (ТАТ.) 2
К86

Бу китапны җәмәгатьчелек тәртибендә язучы Габдрахман Минский төзеде.

КАЙНАР КӨННӘР ҖЫРЧЫСЫ

Гадел Кутуй совет поэзиясе күгендә үзенчәлекле бер якты йолдыздай егерменче еллар башында кабынды. Бу кабыну очраклы түгел иде. Бу кабыну шул елларның яшәү һәм көрәш көннәре романтикасыннан, революцион рухның илһамландыргыч көченнән ялкын алды. Кутуйның шагыйрь дә, гражданин да буларак формалашуы, күп кырлы әдәби-җәмәгатьчелек эшчәнлегенең үсә, көчәя бару юлында моның аеруча әһәмияте булды.

Яшь Кутуйның әдәбиятка атлау юлы, яшьлеккә хас булганча, гамьсез балачак гүзәллегенә төренгән: букча асып мәктәпкә барганга кадәр үк әле ул өйдә «әни мәктәбен» үтә. Олы җанлы, шагыйрь йөрәкле гади татар хатыны Динә апа яраткан Гаделшасына үзе чыгарган бәетләрен көйли, аннары яшь шәкерт туган авылы Татар Кынадысы мәктәбендә уку китабы «Туган тел» битләрендә Тукай шигырьләре белән очраша, һәм баланың саф күңелендә гаҗәеп бай дөнья — шигърият дөньясы ачылгандай була... Менә ул Алексеевск авылы мәктәбендә русча өйрәнә. Хәзер инде Гаделша Пушкин шигырьләрен Тукай тәрҗемәсендә генә укып калмыйча, оригиналында уку бәхетенә дә ирешә...

Кутуевлар Самарага күчеп киләләр. Булачак шагыйрь биредә танылган рус язучысы А. Неверов җитәкчелек иткән әдәбият түгәрәгенә йөри, В. Маяковскийның революцион поэзиясе белән таныша, бу зур шагыйрьнең иҗатына гашыйк була, аның кебек итеп дәртле иҗат пафосында яшәргә җилкенә, һәм, ниһаять, шушы яшьлек җилкенүе Кутуйны 1922 елда Казанга алып килә.

Гадел Кутуй әдәбиятка үз заманының революцион колачын, яңа белән иске көрәшендә туган кайнар һәм йөгерек көннәрен җырлап килде. Ул үзенең беренче әсәрләренең берсен «Кайнар көннәр», ә 1925 елда басылып чыккан беренче җыентыгын «Көннәр йөгергәндә» дип атады.

Шунысы характерлы, эскиз дип аталган бу нәни парча — «Кайнар көннәр»дә зур көрәш һәм шул көрәш полководецларыннан берсе, гражданнар сугышы каһарманы — Чапай образы чагыла. Моны-

сы инде бер Кутуй иҗаты өчен генә булмыйча, ә гомумән татар совет әдәбияты өчен дә интернационал мотив үсентеләренең яшь совет иленең беренче елларында ук шытып чыга башлавын күрсәткән әйбәт бер факт.

Гадел Кутуй үзенең иҗади һәм җәмәгатьчелек эшчәнлеге белән заман арасындагы бәйләнеш бердәмлеген тирәннән сизеп иҗат итте. Ә заман Кутуйдан шагыйрь дә, драматург та, публицист та, театр тәнкыйтьчесе дә, тәрҗемәче дә, әдәбият укытучысы да, ялкынлы оратор, актив җәмәгатьче булуны да таләп итте һәм шуңа шартлар тудырды. Кутуйны күреп белгән, аның белән эшләгән замандашлары аны әнә шулай: ару-талу белмәс, башлаган эшне очламый куймас, гаять тере, өлгер, искиткеч эрудицияле берәү итеп күзаллыйлар.

Үзенең бу хәтле күп төрле бай иҗатында Гадел Кутуй газета битләрендә басылган күп санлы мәкалә, фельетон, рецензияләре, микрофон алдында яисә трибунадан ясаган чыгышларыннан, яңгыравыклы шигырьләреннән алып зур күләмле «Тапшырылмаган хатлар» повестена кадәр бер бөек сыйфатны — кешенең рухи матурлыгын, мораль сафлыгын, ихтыяр көчен яклады, шуңа дан җырлады. Кутуй үзе дә, кеше буларак, матур йөрәкле, шат күңелле, көләч йөзле берәү иде.

Кутуй тормышның шатлыгын тоеп яшәде. Әле иҗатының шедевры булган «Сагыну» нәсерен язганга кадәр күп еллар элек үк без Кутуй шигъриятендә сагыну мотивларының бөреләнә башлавын күрәбез:

Чыңла!
Чыңла, сазым... Уйна, көем...
Бие, дустым лирика!
Бик сагындым,
Бик сагындым шатлыгымны...
Шатлыгыма пуля тиертмәм, —

дип язды ул 1928 елда.

Кутуйның шигъри авазы бөек Пушкин, Некрасов, Тукай, Шевченко, Блок, Горький, Маяковский поэзиясе традицияләрендә камилләште. Бу исә Кутуйны кеше буларак та рухи баетты һәм чыныктырды, нинди генә авырлыклар, гаделсезлекләр алдында да иелеп төшмәскә өйрәтте. Шуңа күрә дә шагыйрьнең иҗат бакчасында гел яз күкрәде, кояш яктыртты. Гомумән, Кутуй иҗатын кояшсыз, язсыз, сөю, елмаюларсыз күзаллау мөмкин түгел. Әле 23 яшендә чагында ук:

Мин — яшь шагыйрь — үлгәндә дә:
— Безнең кояш ВКП, — дип
Коммунарлар язлыгында үләрмен, —

дип җырласа, 20 ел узгач, 1945 елда, Берлин юлыннан язган бер хатында шагыйрь-солдат Кутуй: «Монда яз, җиңү язы туа», — дип, сугыш уты, туплар гөрселдәве астында, җиңү алып киләчәк язны күрде.

Без бу солдат-шагыйрьнең ялкынлы иҗаты турында сөйләгәндә, иҗатының башлангыч елларындагы әдәби агымнар арасында эзләнүләре һәм шул чагында ясаган теге яки бу ялгышларына басым ясап түгел, ә Кутуйны әдәбиятыбыз күгендә мәңге сүнмәслек йолдызларның берсе иткән фидакарь эшчәнлеген, халкына, Ленин партиясенә булган чиксез мәхәббәтен, саф бирелгәнлеген искә алып сөйләргә тиешбез. Шушы уңайдан, бу урында, Татарстан язучылар союзы архивында сакланган бер документны тагы бер искә алып китәсе килә.

Бөек Ватан сугышы елларында, фронттан гвардия полковнигы Михайловның Татарстан партия өлкә комитетына язган хатында менә нәрсә диелә:

«Иптәш Гадел Кутуев шикелле йөзләрчә патриотларны тәрбияләгән һәм фронтка биргән Татарстан партия оешмасына рәхмәтемне әйтеп бетерә алмыйм... Минем берләшмәгә килгәндә, Кутуев гади солдат иде, натурасы белән тыйнак иде, үзенең югары белеме белән, язучы булуы белән беркайда һәм беркайчан да һаваланмады. Фронтның кырыс чынбарлыгы таләп иткән һәр тапшырылган эшне, һәр боерыкны намус белән үтәде. Иптәш Кутуев сугышта һәрвакыт батыр һәм кыю иде. Үзенең түземлелеге, шат күңеллеге белән башкаларга үрнәк булды. Ул һәр сугышчан йөкләмәне үз вакытында үти иде...

Иптәш Кутуев Волга буе сугышларында катнашып, шунда КПСС сафына керде. Ул тәрбияче-оештыручы буларак, үзен искиткеч сәләтле итеп күрсәтте һәм дивизия парторгы итеп сайланды. Иптәш Кутуев фронтта үзен иҗат кешесе буларак та танытты. Ул частьның тарихын язды, әдәби монтажлар төзеде, Кызыл Армия матбугатында, сугышчыларның үзешчән сәнгать эшләрендә актив катнашты...»

Гадел Кутуй иҗатының икенче бер гүзәл ягы, бу аның Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Һ. Такташ алып барган бөек эшне — татар әдәбиятын тугандаш халыклар әдәбияты белән якынлаштыру, аралаштыру миссиясен дәвам иттерүе. Моның аеруча якты үрнәген без Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повесте тарихында күрәбез. Бу повесть рус телендә 9 басмада һәм башка телләрдә дә кат-кат басылды. Татар язучысы тудырган бу повестьның инглиз, француз, албан, корея һ. б. телләрдә дә басылып чыгуы совет әдәбиятының территория чикләрен зурайтуда зур өлеш кертте.

Гадел Кутуй иҗатының иң чәчәк аткан, шагыйрь буларак та, солдат буларак та авыр сынаулар кичеп чыныккан көннәрендә ара-

быздан китте... Ул 1945 елның 16 июнендә Польша җирендә хәрби госпитальдә үлде...

Күкрәге Кызыл Йолдыз ордены һәм солдат медальләре белән бизәлгән көрәшче шагыйрьгә ул көнне әле 42 яшь тә тулмаган иде.

1963 елның ноябрь көннәрендә совет җәмәгатьчелеге, әдәбияты һәм матбугаты татар әдәбиятының күренекле әдибе Гадел Кутуйның туына 60 ел тулу көнен тантаналы рәвештә билгеләп үтте. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының Зур залында Кутуйның замандашлары аны искә алдылар, бүгенге яшь буынга аларның олы туганнары узган батыр юл тарихын сөйләп, алар кебек булырга чакырдылар...

Менә нигә өчен без бүген татар совет шагыйре, солдат-патриот Гадел Кутуйны искә алганда, артыбызга әйләнеп узган елларга гына түгел, ә алдагы юлыбызга, киләчәк елларга таба да карыйбыз. Шул киләчәк елларга таба атлап баручы күп милләтле совет поэзиясе солдатларының беренче сафларында үз җырлары белән яңгыраган Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Нур Баян, Гадел Кутуйларны күрәбез...

Г. МИНСКИЙ

ШИГЫРЬЛӘР

ҖЫРЛЫЙМ ЧЫНЫН

Дус шагыйрьгә

Җырлыйм дисәм, җырлыйм чыны
Ялган җырлар миндә сатылмый.
Әйдә, дустым, җырлыйк дөресен.
Чын җырчылар хәзер атылмый.
Була шигырь... шунда шигырь...
Балаң кебек,
Үзең булып
Туа йөрәктән.
Ә үсә ул шундый начар...
Бүрәнәләр төшә беләккә!
Ә мин батыр:
— Әйдә, төшсеннәр, дим,
Бүрәнәләр тими йөрәккә!

Чыңла!
Чыңла, сазым... уйна, көем...
Бие, дустым лирика!
Бик сагындым,
Бик сагындым шатлыгымны...
Шатлыгыма пуля тиертмәм —
Чөнки,
Үзебез — гаммә[1], телебез — гаммә,
Ә илкәем — партия!
Шуңа бирдем бу йөрәкне;
Бер йөрәктән—күп йөрәккә,
Күп йөрәктән—бер йөрәккә мәдхиям!

---

[1] *Гамма*—масса мәгънәсендә. *Ред*

Шунда,
Шунда тәмем, шунда күңелем...
Шунда шаулау хәятым!
Шунда җырлар, тәмле җырлар,
Иң беренче,
Иң яраклы
Чын шагыйрьләр отряды.

КОЯШ ГЫЙШКЫ

Бүген белдем,
Кояш миңа гашыйк булган:
— Кутуйны мин үбәм, — ди.
Үбәр дә шул!

Яшьлек диңгеземдә йөзгән чакта,
Нурга урап мине үбүче—ул син идең,
Син идең ул—беләм мин!

Бүген белдем,
Көләч кояш көлә килә, көлә менә.
Карга кереп, кышның карын кимерә.
Ә кыш елый, агып елый:
— Туным җәл, ди.
Җиргә ятып яшен сөртә,
Суын агызып йөткерә.

Бүген белдем,
Көләч кояш көлә килә, көлә менә.
Кызны үпкән кебек мине үбә,
Үбә толымлап!
— Сагындым, ди, оялмый да...
— Кояш туган, оял инде, урам бит бу...
Күрәсеңдер әнә...
Бездән көлгән күгәрченнәр
Көлә-көлә язгы суда коена.

Я, әйтегез:
— Шагыйрь җаны шулай буламы?
Я булмаса,

— Кояш телен белгән кешене шагыйрь
диләрме?
Әгәр шулай булса,
— Мин ул түгел!
Мин—яшь шагыйрь—үлгәндә дә:
— Безнең кояш ВКП, — дип
Коммунарлар язлыгында үләрмен!

КӨЗ

Табигать тын. Җәй моңайган.
Болыт шәленә төренеп
Көз килә.
Карт имән дә
Көз кунакка
Яфрак коеп баш ия.
Көз матур ул.
Яңгыр чәчле
Толымнарын җиргә төшерә.
Төшерә дә батыр булып ашлык суга...
Ындырларга барып үкерә.

Бәлки берәү шунда,
Чәчкә юктан
Чыккан, дияр, елга көз исемле зур эрен.
Ә мин көзлим!
Көзгә тавыш бирәм!
Яраттым мин көзнең туклы ындырын!

БИШ МИНУТКА ДӨНЬЯ ТУКТАДЫ

Еллар...
Меңнәр тарихында булмаган көн:
Биш минутка дөнья туктады.
Бүген
Авыл, калаларны урап алган
Кызыл әләмнәрне
Кайгы басты...
Миллионнарча халык, урамнарга чыгып,
Актык кайнар сәламнәрен
Ильичына сөйләде.

Хәрәкәт юк.
Кайгы көе аны кумә.
— Ильич үлгән...
— Ильич күмелә.
— Кемнең сүзе?..
— Байракларны түбән!.
Бер... ике... өч... бум...
Бах...
Тырррах
Гууууу...
...Чү!
Завод... мылтык... коралларның тавышлары
белән
Меңнәр җылый...
Меңнәр сөйли...
— Ильич — иптәш — эшче...
— Ильич — коммун — крестьян...
— Ильич халык...
— Үлгән...
— Юк!
Күмдек.
Кайтмас артык... үлде.
Ләкин калды:
Ленинчылар...
Ильиччылар мәңгегә.

Я,
Әйтегез, дошманнарны
Кем кисәр дә,
Кем табар?
Ильич исеме белән ант иттек без
Ильич каберендә:
Эшче-крестьян
һәм
Ильич улы:
РКП!

1924

* * *

Комсомолны язам, туктамам...
Комсомоллар алар
Авыл саен ячейкалар — домналар...
Тракторны җигеп... җир кашыдык...

Орлык чәчтек үссен дип.
Шул вакыт мин аны үптем...
Миндә хисләр барын белсен дип —
Комсомоллар алар «монах» түгел.
Көлә-көлә...
Эш битенә йөрәк утын салалар.
Салалар да
Тормыш нурын алар ожмахлардан түгел,
Шундук ала баралар.
Кояш нурларыннан
Нурлы янгыр яуган чакта
Бер әчелеп Сәрвәремә карадым.
— Сөям, дидең, сөя алмадың...
Нигә инде мине алдадың!

Бүген ашлык суккан чакта
Чынлап үптем Сәрвәрне.
Шул үбүдән соңра инде...
Чәчәк атты авыл бәйрәме.

1924

ПУЛЕМЕТЧЫЛАР

Үткен җилле буран.
Кыр җигелгән... Кыр дулый.
Пулеметта ике кызылармеец
Ярлы илгә көн тугый:
Кыр — кырылдый,
Кыр — карылдый...
Кыр: та-та-та-та...

Кыр буранлы... Ут бураны...
Актык минутын сорый бу.
Пулеметка төште бомба...
— Хәйрүш!
Бомба екты... Тормый ул...

Оста план үткен барса,
Бер пулемет ала җиңү каласын...
— Пулеметлар көрәш мәйданына!
Кызылармеец белә аның кала аласын.

Берсе аның
Баш күтәреп... күзләп алдын...
Пулеметка сузды кул...
Хәлсез Хәйрүш:
— Нишлисең, — ди ул.
Пулеметны эшкә бирәм... чыда бераз.
Чыдамасаң... хуш...
Кыр — кырылдый,
Кыр — карылдый...
Кыр: та-та-та-та...

1925

КӨН — КАДАК

Көн — кадак.
Тормыш — чүкеч.
Без —
  Кеше!
Бәр чүкечне.
        Сал кадакка.
          Нык
            Төшер!

Без — усаллар.
Без — җылылар.
Бездә көннәр
Татлысы.
Җир шарын
Ярды бит
        уртага
Кызыл әләм
        камчысы.
Ярды.
        Ярылды.
Һәм утә ул...
Һәрберен.
Ул —
        чүкечләр.
Без — матурлык.
        Без — динамо.

Без
Хәзер — ут...
Көчләләр!

Көн — кадак.
Тормыш — чүкеч.
Без —
Кеше!
Бәр чүкечне.
Сал кадакка.
Нык
Төшер!

1925

АТТЫЛАР

Көрәш елларында
Шашкан тормыш
Уйный, көлә.
Уен арасында:
— Атыгыз, — дип приказ чыкса...
Кешеләр үлә.

Төн уртасы. Урам тып-тын,
Тик җил исә.
Менә төрмә.
Анда көрәшчене җиңә җиңү уйлары:
— Соңгы җиңү — үлем түгел,
Яшәү, — ди ул...
Их, ычкыналмый... Чылбырда аның
аяк, куллары.

Өзелеп көткән таң җиткәч,
Көрәшчене,
Томаннарга урап,
Тау битенә алып чыктылар.

Чыктылар да:
— Киемнәрен утка!
— Үзен баганага, — дип,
Күз алдына авыр бер туп куйдылар.

Татлы көрәш таны татлы була,
Эче була аның көрәш корбаны.
Киемнәрдән үскән төтен
Томаннарга кушылып
Ашыктырды үлем сигналын.
Аклар эше шашкан саен шашты,
Үлүченең авызына, дәшәлмәсен өчен,
Балчык салдылар...
Селкенмәсен өчен тере тәнне
Баганага кактылар...
Кактылар да
Менә шунда аны —
Безнең Мулланурны
Туптан аттылар.

1925

МОРҖАЧЫ

Һәр көн шулай иртән
Урам ера «кара карчыга»:
— Кемгә морҗа... кемгә морҗа арчырга!!?

Урам — диңгез.
Өйләр — пристань.
Пароход — үзе «карчыга».
Туктала да тагын суза:
— Кемгә морҗа... кемгә морҗа арчырга!!?

Төтен юлын арчып,
Майлап сылый морҗаны.
Ул шат үзе. Җырлап ала:
— Майларбыз, ди, шулай
Яңа дөньяны!

Һәр көн шулай иртән
Урам ера «кара карчыга»,
Туктала да тагын суза:
— Тормыш җиңел, корым авыр...
Арчырга. Арчырга!

1925

* * *

Кеше! Бугаз кылың нәзек...
Авазың тар,
Тавыш житми радио булырга.
Ә мин менә бүген теләр идем,
Теләр идем шунда —
Казан мәйданында
Барлык жанга яңа шигърем укырга!
Ах, бу бугаз... Кан бугазы
Житәмени? Киң шатлыкка
Кирәк иде бакыр тавышлар.
Ә бу нәрсә? Тавышмыни?
Бу тавышка Казан гына тоташкан.
Ә шатлыгым минем һаман,
Һаман тышка сорый:
— Минем турда бөтен илгә акыр, ди.
Акыр да син радио бул...
Минем бәйрәмемә
Бөтен станоклар илен чакыр, ди.
Нишлим инде?
Әллә юкса Эльбруска басып
Яңа телдә яңа чаңнар сугыйммы?
Я булмаса, барлык гудокларны жыеп,
Шулар аша
Яңа симфонияләр биримме?
Эх син көрәш... Тәмле көрәш!
Ничек итеп сиңа кереш аккорд бирием...
Һәм шул аккордта:
— Бөек Октябрьның бөек уңы житте
диием!..

* * *

Кызыл күлмәк киеп йөрим,
Кызыл күлмәк киеп урам ерам...
Яраттым шул — миндә кемнең ни эше?
Син каракүл һәм галстук...
Ә мин прастой күлмәк —
Күкрәгемдә күкрәсен дим
Канлы еллар билгесе!

1925

* * *

Яратам мин, яратам мин табигатьнең
утлы машинасын.
Яратам мин аның
Утлы яшен күзен... болыт морҗасын.
Яратам мин
Арыш, бодай тәнен кочып үпкән,
Җылап очкан
Янгыр тезмәсен!

1925

ИЛЛӘР ЯЗЫ

Дулкын, дулкын булып яна яз нурлары,
Яз күлмәген кигән май ае.
Май аеның исмен байрак итеп,
Шатлык чәчә бүген ирек мәйданы.
Менә бу җирләрне, күңелләрне күрәсезме,
Бозлы карлар анда тау иде.
Тау карларын эртер өчен
Һәр ел саен урамнарда яз йөри.
Майга маем диик,
Май ул бөек...
Майның бере бүген оратор:
— Прагул бетсен!
— Хезмәт үссен!
Күңелләрне шатлык каратсын!
Совет иле — киң ил,
Аны чыккач, тагын бик күп илләр,
Колонияләр күренә.
Майның бере болытларга менгән
Шатлык булып
Шул илләргә:
— Яз кирәк! — дип илерә.
Менә мин дә бүген авазымны күкрәү итеп
Майга тавыш бирәм...
Илләр язы кирәк диеп,
Кояш башына менеп байрак эләм,
Тыңлагыз!

— Көчләр яңрасын!
— Мин көрәшче дисәң,
Һәрбер адымың
Көрәш сафларына бәйлансын.

КАРТ ПЫЧКЫЧЫ

Мин карт инде.
Билем — ялан.
Бик күп еллар урман кистем.
Дәштем... Дәшәм:
— Кайда сез!
Урман,
Ул әле дә бик яшь әле,
Ә минем биттә еллар сөте каймаксыз!

Пычкы кисә,
Пычкы йөри,
Пычкы, пычкый
Пычкылтап!
Пычкы сырлый,
Пычкы керми,
Пычкы чыкмый,
Чыкмый һап!

Еллар белән санаганда
Мин карт инде.
Күңел — шаян
Пионер кебек шаулый, туймый ул.
Йөрәк коммун улын сагынып тибә.
Ярый, кичкә күрем...
Әйдә пычкы!
Бераз тагын уйныйк!

Пычкы кисә,
Пычкы йөри,
Пычкы пычкый
Пычкылтап!
Пычкы үткен,
Пычкы күмелә.
Пычкы чыга,
Чыга шәп!

КЫЗЫЛ МӘЙДАНДА

Кызыл мәйдан буйлап яшьлек үтте,
Яшьлек булып кырлар янрады.
Киләчәкне алып килгән кебек,
Керде илнең яңа сафлары.

Бу сафларда илнең батырлары...
Дан тукучы матур кызлары...
Алгы сафта бара Стаханов,
Бусыгиндай тимер уллары.

Болар ачты машиналар серен,
Һаваларга болар очтылар.
Илебезнең байлыкларын күреп,
Шатлык нурларына чумдылар.

. . . .
. . . .

Яктырды көн, янрады ил...
Һәм муллыкка күмелде.
Яшәү күңелле булганга,
Эшләве дә күңелле.

Без, иярләп техниканы,
Үттек норма киртәсен
Һәм шат илгә якынайттык
Коммунизм иртәсен!

Хезмәт бездә гарьлек түгел,
Хезмәт сөя һәр кеше!
Хезмәт бездә — дан, батырлык
Һәм бөек намус эше!

Дулкынланып ага халык
Байракчылар артыннан,

Ялкыннарын сибеп корыч
Шулай ага мартеннан.

Лачын кошлар — Чкаловлар
Ерак юллар үтәләр...
Алар безнең җылы хисне
Котыпларга илтәләр.

Иртә саен бакчаларга
Кояш төшә алланып,
Демченколар бакчасында
Шикәр үсә балланып.

Кояш карый чая кызга,
Сыйпый аның йөзләрен...
Һәм күрә ул кыю кызның
Якты, зирәк күзләрен.

Кара төндә яшен төсле
Ыргый алга вагоннар.
Кривоносны котлагандай,
Шаулап кала каеннар.

Ул китерә илгә байлык.
Ул китерә ташкүмер...
Эшелоннар гөрләвендә
Җырлап бара шат гомер.

Хезмәт бездә гарьлек түгел,
Хезмәт сөя һәр кеше!
Хезмәт бездә — дан, батырлык
Һәм бөек намус эше!

1928

ӨЧ ИГЕЗӘК ТУРЫНДА ХИКӘЯ

Төрмә булып үткән бер заманда,
Байлар хөкем сөргән чорларда —
Газап күргән ярлы семьясында
Өч игезәк туган дөньяга.

Өч игезәк...
Ләкин бар да кызлар...
— Зур кайгы, — дип ана сыкраган.
Үскән саен кызлар:
— Әннә! — диеп,
— Ашарга! — дип икмәк сораган.

Бу семьяда кызлар бик күп булган,
Ә ир бала бер дә тумаган.
Өч игезәк тугач, мескен ата:
— Минем, — дигән, — бәхет булмаган.
Җиргә үги булган бу өч кызга
«Артыклар» дип исем биргәннәр.

— Артыкҗамал,
— Артыккамал,
— Артыкбиби булып
Йөрсен, дигәннәр.

Бик күп еллар үткән,
Еллар илгә
Зур көрәшләр алып килгәннәр.
Шул көрәштә җиңгән чын батырлар
«Артыклар»га бәхет биргәннәр.

Детдомнарда йөреп, бу яшь кызлар
Җылы хисләр белән үскәннәр,
Илебезнең вузларына кереп,
Белем китапларын үткәннәр.
Артыкҗамал хәзер бөркетсыман
Һаваларга очып менә, ди;
Язгы чәчәк кебек ефәк зонтта
Салмак йөзеп җиргә төшә, ди.
Ул тикшерә данлы Ватан күген,
Өйрәнә ул көрәш юлларын,
Һәм белә ул:
Аның самолеты
Тар-мар итәр дошман полкларын.
Зур заводта эшли кенчесе,
Эшкә аны Серго өйрәткән.
Артыккамал өчен Серго үзе
Кояш булып кергән йөрәккә.

Гадел Кутуй тормыш иптәше Галимә ханым
һәм балалары белән.

Артыкбиби «Ильич» колхозында.
— Дан кызы, — дип аны атыйлар,
Ул агроном...
Кыю эше өчен
Колхозчылар аны мактыйлар.
Күкрәгендә аның ил ордены,
Күзләрендә — бәхет ялкыны.
Хужа итте аны бөтен илгә
Партиянең бөек законы.

Батыр кызлар бүген бергәләшеп
Туган өйдә кунак булдылар.
— Тансык кызлар кайтты! — диеп картлар
Шатлык нурларына чумдылар.

1937

БЕЛМИЛӘР

Авылдашлар миңа ятим диләр,
— Туганнарың юк, — дип сөйлиләр.
Туганнар күк якын дусларым бар,
Иптәшләр бар — шуны белмиләр.

Яшьләр миңа абый диләр,
— Син картайдың, — диеп сөйлиләр.
Ә күңелем минем мәңге яшь бит,
Ил яшәртә — шуны белмиләр.

Минем күзләремә карап кызлар:
— Бик кечкенә, — диеп сөйлиләр.
Ә бу күзләр киләчәкне күрә,
Күздә көч бар—шуны белмиләр.

Мәҗлестәшләр миңа: Мә, эч! — диләр,
— Шунда бәхет!—диеп сөйлиләр.

Иҗат төннәрендә исерәм мин, —
Шул бәхетне алар белмиләр.

Ә берәүләр мине ярлы диләр,
— Тора белмисең,— дип сөйлиләр.
Бөтен ил минеке — шул байлыкны
Ул мескеннәр әле белмиләр.

Иптәшләрем мине салкын диләр,
— Җансыз кеше, — диеп сөйлиләр.
Ышанмагыз! Җылы йөрәгем бар.
Мин гашыйкмын — шуны белмиләр.

1940

ОЗАТУ ҖЫРЫ

Саубул, улым, чиккә оч син,
Бәхет яусын юлыңа;
Завод өчен тыныч бул син:
Анаң кала урыңа.

Лачын коштай очып,
Дошманны ку иленә;
Яшен ташы булып оч син,
Оч син фашист өстенә!

Бомбаларың туры төшсен,
Бетсен этләр оясы;
Биегрәк күтәрелсен
Алсу ирек кояшы.

Сәлам хатың килгән саен,
Бәйрәм күлмәк киярмен;
Минем улым батырларча
Бурычын үти диярмен.

Мин көтәрмен кайтуыңны,
Сөеп каршы алырмын;

Син күрсәткән батырлыкны
Орденыңнан танырмын.

Саубул, улым, чиккә оч син,
Бәхет яусын юлыңа;
Завод өчен тыныч бул син:
Анаң кала урныңа.

1941

ХАЛЫК БАРА

Хаклык илен, шатлык җирен яклап,
Баһадирлар бара сугышта.
Бара шулай, әйтерсең лә давыл—
Циклон кутәрелде Котыпта.

Һава ярып оча Чкаловлар,
Буденныйлар оча атларда,
Чапаевлар, Батыршиннар оча,
Бирмәбез, дип, илне ятларга!

Гөрст-гөрст итеп утлы бомба ява;
Бомба түгел, безнең нәләт ул.
Бум-бум итеп яшен-ядрә ява;
Ядрә түгел, безнең нәфрәт ул.

Җир тетрәтеп гранаталар ява,
Туфрак яна, һава ярыла.
Изге Ватан өчең халык бара
Үлем алып дошман явына.
Яшен түгел, безнең уклар ява,
Безнең туплар дөнья яңрата;
Безнең уттан җирдә, каргалардай,
Шакалларның башлары ята.

Бу сугыш — изге сугыш,
Һәм анда
Миллионнарча дуслар таптык без;

Баһадирлар баһадиры —
Бөек партиядән
Зур көч алдык без.

Хаклык илен, шатлык җирен яклап,
Баһадирлар бара сугышта.
Бара шулай, әйтерсең лә давыл —
Циклон күтәрелде Котыпта.

1941

ПАРТИЗАНКА

Кара төндә сугыш кырларында
Якты яшен булып иң алда,
Гайрәт биреп безнең батырларга
Ут эчендә йөри кем анда?

Әнкәбез ул — партизанка,
Ант иткән ул җиңәргә,
Ант иткән ул — партизанка
Дошманнарны кисәргә.

Төртеп утлар иген кырларына,
Дошманны кем ачка калдыра?
Ватып күперләрне юлларында,
Дошманны кем хәлдән тайдыра?

Әнкәбез ул — партизанка,
Ант иткән ул җиңәргә,
Ант иткән ул — партизанка
Дошманнарны кисәргә.

Камышлыкка посып пулеметтан
Кем ега ул кара кошларны?
Кем ул анда куе камышлыктан
Күмә утка явыз дошманны?

Әнкәбез ул — партизанка,
Ант иткән ул җиңәргә,
Ант иткән ул — партизанка
Дошманнарны кисәргә!

1941

БАТЫР КАБЕРЕНДӘ

Ялгыз кабер тора тау башында,
Яшь бер батыр анда күмелгән:
Танда искән кыр җилләре аңа
Күп-күп итеп чәчәк китергән.

Баш очында аның шаулый нарат,
Ә наратта кошлар сайрыйлар.
Эссе көндә аны каплый болыт,
Ә суыкта нурлар карыйлар.

Бер яшь батыр ята тау башында,
Дусты килгән аны күрергә.
Ул ант итә аның баш очында
Дошманнарга җәза бирергә:

— Мин ант итәм үбеп туфрагыңны,
Мин ант итәм синең кабреңдә,
Һич кызганмам явыз дошманнарны,
Син яшәрсең минем хәтремдә!

1941

ЯҢА ЕЛ БҮЛӘГЕ

Мин карт инде, күзем начар күрә,
Ә шулай да сөлге чигәм мин:
Кайнар хисем кушып, бу сөлгене
Сугышчыга бүләк итәм мин.
Һәр таң саен егет битен юар,
Ап-ак сөлгем алып кулына;
Газиз ана кебек теләк телим:
Бәхет яусын батыр юлына!
Ак сөлгене кулына алган саен,
Егет татыр йөрәк тойгымны.
Шифа бул син аңа, ялардан
Һәм үлемнән сакла улымны!

Барып җит син аңа яңа елга,
Яңа бәхет китер улыма;
Безгә җиңү, безгә шатлык телим,
Үлем алып дошман явына.

1941

ЯҢА ЧАСТУШКАЛАР

Әй, баш кына да баш кына,
Гитлер башы таш кына;
Шул таш башны ватар өчен
Яшь егетләр ашкына...
Эх-ма,
Яшь егетләр ашкына!

Гитлер сораган Геббельстән:
— Инде безгә ни кирәк?
Геббельс әйткән: — Алдау өчен
Кара кирәк бер чиләк...
Эх-ма,
Кара кирәк бер чиләк!

Әй, туп ата шул, туп ата,
Туплар дөнья яңгырата;
Безгә кергән дошман башлар
Җирдә тәгәрәп ята.
Эх-ма,
Җирдә тәгәрәп ята!

Безнең гаскәр — данлы гаскәр,
Зур юл үтәрбез әле;
Гитлерын да, Лейларын да
Җиргә күмәрбез әле.
Эх-ма,
Җиргә күмәрбез әле!

Сирәк-мирәк шулай кирәк,
Сиңа, җаным, ни кирәк?
Бар халыкта тик бер теләк:
Гитлер бетсен тизрәк...
Эх-ма,
Гитлер бетсен тизрәк!

1941

ИРТӘНГЕ УЙЛАР

Алтын колач җәеп кояш калка,
Җылы нурлар җиргә тарала;
Кояш матурлыгын кочар булып
Мин тез чүгеп карыйм аңарга.

Окоп янындагы күл төбендә
Мин күрәмен нурлар уйнавын:
Нурда, саф һавада коенам мин,
Җиңел булсын диеп юлларым.

Мин исним дә сирень чәчәкләрен,
Дошман якка карыйм һәм көләм;
Шушы сирень чәчәгендә чөнки
Җиңү музыкасын ишетәм.

Автоматым кысып, горур атлап,
Ап-ак төнле юллар үтәм мин,
Чөнки һәрбер тыныч адымымда
Җиңү музыкасы иштәм мин.

Юлларымда күрәм туп, танклар,
Һәм күрәм мин халык яуларын.
Бронзадай гаскәр сафларында
Мин ишетәм хаклык яңравын.

Хыял күзем белән илгә карыйм,
Карап туймыйм — рәхәт күңелгә!
Рус шәһәрен ярсып яклаганда,
Күзләремә Казан күренә!

. . . .
. . . .

1942

ТУГАН ИЛ

И туган ил, и матур ил,
Калдың бездән еракта,
Калсаң да бездән еракта,
Күңелдә син һәр чакта.

Суың тәмле, кырың ямьле,
Шифалы һаваларың,
Сугышларда дан казанды
Синең батыр улларың.

Искә төшә җәйге таңнар...
Рәхәт иде ул чаклар,
Бүген дәле янадыр күк
Без кабызган учаклар.

Искә төшә бәйрәмнәрең,
Табыннарың, казларың,
Бер карауда гашыйк иткән
Зифа буйлы кызларың...

И данлы ил, и шанлы ил,
Син минем туган илем,
Киткән чакта эчкән суың
Тәме авызда минем.

И туган ил, и матур ил,
Нур күмә калаларың,
Һәр иртә-кич сине, илем,
Сагына балаларың.

Безне озаткан сукмакларны
Капламасын үләннәр,
Яз кайтмасак, көз кайтырбыз,
Сез көтегез, сөйгәннәр!

Хәрәкәттәге армия,
Берлин юлы. *1944*

ТАЛАНТЛАР ВАТАНЫ*

Поэма

1

. . . .
. . . .
. . . .
. . . .

2

Мин утырам язып хисләремне,
Зур кыюлык килә башыма:
Кешелекнең бөтен шагыйрьләре
Тере булып баса каршыма.
Телгә килә шунда китапларым:
Гомер, Пушкин, Гёте томнары...
Ишеткәндәй булам коллар зарын,
Йөрәк өзгеч богау янгыравын.
Алга таба үтә Гейне, Хафиз...
Тагын Тукай үтә юл алып,
Давыл жырын жырлап Горький керә...
Минә Байрон үтә елмаеп.
Көрәш жырчысы Маяковский
Партбилетлы томнар күтәрә;
Хәйям, Данте, Шиллер, Руставели
Котлап аны алга үткәрә.
Озакламый өем шыгрым тула,
Бүлмәләрем китә зураеп,
Ә жырчылар һаман агыла тора.
Трибунага таба юл алып.

3

Иптәшләргә әйттем мин уемны
— Талантларга Ватан булды, дип...
Гүзәл бәхет илен котлар өчен
Шекспирлар безгә килде, дип.
Гасырларның бөек жырчылары:
— Ватан шул,— дип безгә килделәр,

* Кайбер кыскартулар белән бирелә.

Китапларын ачып шунда алар
Көрәш юлын сөйләп бирделәр.
— Әйдүк, дуслар!— дидек без аларга
Һәм сөйләдек дөнья хәлләрен...
Егерменче гасыр көрәшләрен
Һәм шат илнең матур көннәрен.
Без сөйләдек палач фашистларны,
Германиядә сәнгать бетүен,
Даһи җырчыларның томнарына
Фашистларның утлар төртүен.
Без сөйләдек кардәш Испанияне [1],
Пиратларның үлем сибүен...
Ятим калган нәни балаларның
Аналары ничек үлүен.
Без сөйләдек гүзәл бәхет илен,
Партиянең бөек законын,—
Даһиларның хыялында йөргән
Уйның
Бездә чәчәк атуын.
Иптәшләрем минем томнар тотып
Берәм-берәм алга чыктылар...
Дөнья шагыйрьләре булып алар
Кешелеккә речьләр тоттылар.

4

Трибунага чыкты яшь инженер,
Һәм ачты ул Эсхил китабын...
Күз алдына шунда тере кебек
Калкып чыкты халык титаны.
— Мин ерактан килдем,— диде Эсхил,—
Кайгы дәрьяларын кичтем мин,
Азат кешеләр илен күрер өчен,
Күп газаплар аша үттем мин.
Мин яшәгән чорда юк иде ямь,
Күз яше иде диңгез, елгалар...
Кулда гына түгел, йөрәктә дә,
Акылда да иде богаулар.
Күп михнәтләр аша киләчәккә
Җибәрдем мин шанлы эшемне.

[1] Сүз Франко режимына каршы көрәшүче Испания республикасы турында бара. *Ред.*

Мин җибәрдем сезгә Прометейны —
Дан казанган батыр кешемне.
Ул ут бирде мазлум халыкларга,
Ул фән бирде бәхет табарга,
Ә дошманым аны шуның өчен
Кадаклады кыя тауларга.
Зур көч итеп аны мин үземә,
Аллаларны бәреп төшердем...
Таш өстенә тамган каннарда мин
Язгы ал чәчәкләр үстердем.
Богауланган Прометейга карап,
Урманнар да сыкрап җылады...
Ходаларга каршы ул көрәште,
Ул иреккә җырлар җырлады.
Богауларын өзгән илгә миннән
Яңрап торсын кайнар сәламем..
Якты кояш кебек нурлар чәчсен
Титаннарның алсу әләме!

5

Речьләр дәвам итә. Трибунага
Күтәрелеп чыга Гомерлар...
Кешелекнең вәкилләре булган
Шекспирдай бөек шагыйрьләр.
«Шаһнамә»сен алып Фирдәүси дә
Сөйләп китте сугыш кырларын.
Ул сөйләде батыр тимерченең
Күтәрүен көрәш байрагын.
— Бар халыклар шуна омтылды,— дип
Руставели чыга сүз алып...
Без тыңлыйбыз аның дастаннарын
Борынгыга
Җиде гасыр аша күз салып.

6

Басып тора менә бөек Пушкин,
Сыйпап ала бөдрә чәчен ул.
Һәм күзләрен текәп халыкларга,
Сөйләп килә шигъри речен ул:
— Төрмәләргә очып бөркетсыман,
Тоткыннарга бирдем кулымны;
Тираннарга каршы ядрә иттем
Йөрәгемнән чыккан җырымны.

Авылларда йөреп дәһшәт күрдем,
Коллар тавышын анда тыңладым,
Коллык богауларын өзәр өчен,
Алсу таңнар җырын җырладым.
Ул чак илдә көчле көрәш уты
Пожарсыман торды яктырып,
Богауларны өзәр өчен халык
Вулкансыман торды атылып.
Без аз идек, ләкин барыбыз да
Ирек таңы өчен яндык без.
Без аз идек, ләкин актык көчне
Туар бәхет өчен салдык без.
Омтылышны безнең
Богау кысты,
Пестельләрне дарга астылар.
Каһәр суккан коллык заманында
Күпме җанны яшьли ваттылар.
Чаадаевны шашты диеп, көчләп
Сары йортка ябып куйдылар,
Сөргеннәргә мине озаттылар,
Ә соңыннан... тотып аттылар.
Ләкин мин үлмәдем...
Гәүдәм тапса тынлык,
Эшем яшәр сазым салганчы,
Даным калыр
Ай астында тик бер генә шагыйрь
Яшәп калганчы.
Мине сөйли бөек илдә һәркем,
Мине сөйли илнең һәр теле:
Рус, белорус, грузин, татар, башкорт,
Дала дусты — казах — һәрберсе.
Юк, мин үлмәм,
Шигырьләрем минем
Яшен уты булып яктырыр.
Кешелекне алар һәр таң саен
Яңа җиңүләргә чакырыр!

7

Трибунага чыга бер аспирант, —
Яңа томнар китә ачылып...
Фашизмны яңаклагансыман,
Гейне сөйли кебек ачынып:

— Коралланып, җырлар, кузгалыгыз,
Барабаннар сугып шаулагыз!
Дошманга мин әче нәфрәт әйтәм,
Нәфрәтемне, илләр, тыңлагыз.
Мин беләмен ике Германияне:
Берсе аның халык ягында,
Икенчесе — ялган империя ул —
Янып үләр сугыш явында.
Нәфрәт итеп ялган Германиягә,
Кышкы көндә кәфен тукыймын:
Илне төрмә иткән бандитларга
Кәфен тукып, нәләт укыймын.
Таш бандитлар анда приказ бирә
Көпә-көндез безне таларга,
Сарайларга каршы чыкканнарны
Хөкем ясамыйча атарга.
Урта гасыр вәхшиләре анда
Культураны утка ягалар.
Буйсынмаган галимнәрне анда
Этап белән ерак куалар.
Чикне кичкән чакта ач пиратлар
Кесәләргә тыгылып тентиләр,
Ә байлыкның мидә иканлеген
Ул еланнар күрә белмиләр.
Калалардан калаларга куылып,
Мин дә йөрдем элек бер заман:
Германиядә туып, читтә үлдем,
Инде монда яшим яңадан.
Мин Марксны күреп белә идем,
Сөйли иде көрәш законын.
Ул сөйләгән бәхет чорын теләп,
Мин көчәйттем шигырем ялкынын.
Коралланып, җырлар, кузгалыгыз,
Барабаннар сугып шаулагыз...
Дошманга мин әче нәфрәт әйтәм,
Нәфрәтемне, илләр, тыңлагыз!

8

Трибунада ютәл катыш
Яңрап китте яңа саз...
И мөкатдәс моңлы шагыйрь,
Җырладың син ник бик аз!

Сөйләп китте Тукай:
— Өй түрендә җил җылый иде,
Юк, ач үлемнең куркусыннан ил җылый иде.
Пушкин вә Лермонтов миңа якты үрнәкләр иде,
Соңгы тамчы канымны мин халкыма биргән идем.
Булды юлда киртәләр, эттән күп иде дошманым,
Чөнки залимнарны, өстеннәрне яклый алмадым.
Их, җырларым хәзер күрә чын бәхетле ямь илен,
Мәңге батыр, мәңге якты, мәңге данлы ямь илен.

9

— Минем илем — бәгырем Украина, дип
Шевченкобыз зарын җырлады:
— Эчке алпавытлар изде безне,
Безнең илне паннар талады.
Украинага таба поляк паннар
Зур тупларын корып аттылар...
Ә хуҗалар безне коллар итеп,
Хайваннар дип читкә саттылар.
Тамырыннан көйде ил кырлары...
Хохоллар дип бездән көлделәр...
Лазаретка алып өебезне,
Каберлеккә безне сөрделәр.
Минем җырлар инде Украинаның
Чәчәк ату вакытын күрәләр;
«Кобзар»емны укып, азат яшьләр
Үткән авырлыкны беләләр.

10

Трибунага чыгып карт профессор:
— Некрасов! — дип томга тотынды...
Тере Некрасовны күргәнсыман,
Бар күңелләр аңа омтылды.
Ул сөйләде шагыйрь исме белән,
Некрасовтай бераз йөткереп,
Ул сөйләде бөек шагыйрь булып,
Залыбызга шигъри нур түгеп.
— Үзе ярлы, — диде, — үзе бик бай,
Үзе көчсез иде Русь иле,

Көче аның богауланган иде,
Һәм богауда иде мул җире.
Рус халкына эчкече дип, алдап,
Обломов дип шелтә бирделәр;
Аның «ялкаулыгын» үлчәр өчен
Бер үлчәү дә юк дип йөрделәр.
Ә кайгыга үлчәү бар идеме?
Ә хезмәткә үлчәү тудымы?
Көн-төн эшләп хәлсез егылганны
Күрә торган закон булдымы?
Ялгыз эшли идең, мескен мужик,
Һәм күп,
Күп интектең анда син,
Тавышыңны чөнки булә иде
Алла, патша һәм дә господин.
Туган илем! — дидем, —күргәнем юк,
Күрсәт миңа шундый бер җирне...
Син күрсәткән җирдә
Ыңгырашмасын иде
Син илемнең мужигы!
— Әй, киң Идел! — дидем, — илебезне
Баскан кебек халык кайгысы,
Язгы суың белән син кырларны
Басалмыйсың, — дидем, — ахрысы.
Чын бәхетне күрдем тик көрәштә,
Корбан иттем аңа иркемне...
Үлсәм, — дидем, — шигырьләрем күрсен
Чәчәк аткан яңа илемне.

11

Шунда җиткәч бер комбайнер егет:
— Иптәшләр! — дип сүзгә кереште, —
Мин колхоздан... Авылыбызда, — диде, —
Некрасовны беләһәр кеше.
Бу зур шагыйрь бик еш уйлый булган,
Килерме дип, якты заманнар,
Крестьян халкы Гоголь китапларын
Сатып алырмы дип базардан.
Ахмак Милорд китаплары түгел,
Белинский кирәк халыкка...
Тусын иде шул заманнар, диеп
Ул уйлаган авыр вакытта.

Мин шатланып бүген җавап бирәм:
Белинский таныш колхозга...
Пушкин, Гогольләрне
Үз телендә
Укый инде татар халкы да.

12

Ап-ак ефәк чәчле карт бер артист
Алдыбызга чыкты җырларга.
Ул җырлады Беранжены,
Аны тере иткән
Яңа чорларга.
— Исәнмесез, шат, көр җырлар!
Бик сагындым сезне мин,
Чын бәхетне җырлар өчен
Нинди ямьле сезнең ил.
Корольләргә каршы җырлап,
Төрмәләргә кердек без;
Кыштан качкан кошлар кебек,
Яз иленә килдек без.
Мин ант иттем җырым белән
Халык бәхтен җырларга,
Мин омтылдым Потье белән
Җырдай матур чорларга.
Эшче шагыйрь Эжен Потье —
Көрәштәшем ул минем.
Ул тудырды мәңгелек җыр —
Халыкара гимнын.
Исәнмесез, шат, көр җырлар!
Бик сагындым сезне мин,
Чын бәхетне җырлар өчен
Нинди ямьле сезнең ил!

13

Беранжега кушылып Потье сүзе
Яңгырап китә төрле телләрдә...
— Без тудырган Гимн, — диде
Потье, —
Байрак булыр бөтен илләргә.

14

Талантларга Ватан булган җирдә
Без җырлыйбыз Потье сүзләрен.
Менә ул җыр...
Җырлый аны бүген
Җир йөзенең бөтен телләре:
— Кузгал, ләгънәт белән хурланган
Коллар һәм ачлар дөньясы!
Безнең йөрәк ярсып кузгалган
Сыйнфый дошманга каршы.
Без коллык, мескенлек дөньясын
Ватып ташларбыз нигезен,
Төзербез урнына яңасын,
Рәхәт итәрбез җир йөзен.

15

Маяковский шигырен алып мин,
Трибунага чыгам атлыгып;
Мин укыган ядрә шигырьләрдән
Яшен уты китә кабынып.
— Сезнең алда, — дим мин, — лачын шагыйрь,
Зур көрәшнең шигъри эшчесе.
Трибунада данлы чорыбызның
Иң талантлы бөек җырчысы:
— Мин җырымның
Бугазына басып,
Күзләремә алдым таң елын.
Көрәшләрдә күрдем миллионнарны,
Миллионнарга
җырлыйм дан җырын.
Без йөрәккә язып
Ленин исмен,
Көрәш утларына ташландык!..
Һәм аның исме белән җирдә
Бәхет илен төзи башладык.
Шигырьләрем минем —
көчле гаскәр,
Ил аларга парад уздыра,
Сугыш уртасына кереп шигырь
Дошман полкын вата,
туздыра.

Шигырьләрем минем дан күрәләр,
Солдат булып
утка керәләр...
Синең өчен алар, якты илем,
Кирәк булса,
постта үләләр.
Дошманнарның тамрын өзәр өчен,
Шигырем,
Динамитлы кәйлә бул!
Штурмда үлгән дуслар кебек,
Кирәк булса,
Шигырь,
әйдә, үл!
Кирәк түгел миңа мәрмәр һәйкәл,
Ал чәчәкләр сибә ана-җир.
Мәңгелеккә кергән
һәйкәл булып
Гөрләп үсә безнең яңа ил.
Иптәш тормыш!
Әйдә,
кызу атла,
Коммунада тавышың яңрасын...
Синдә яши
Минем кебек тиңтан кешеләр,
Шулар төзи бәхет дөньясын.
Лирик томнар аша,
Эре атлап,
Мин керермен бәхет иленә,
— Җиңдек бит, — дип,
Дөнья ЦКасына
Җырчылардан сәлам бирергә!
Тормыш шундый матур...
Ул искиткеч!
Яшьлек үсә Совет җирендә,
Йөзгә житкәч тә бит картаймыйбыз,
Дан җырлыйк
Яшьлек иленә!

16

Алдыбызга басты карт большевик,
Һич онытмам аның күзләрен,
Һич онытмам:

— Горький исән! — диеп
Һава ярып очкан сүзләрен.
— Тормыш төпләреннән чыгып Горький
Кинәт
Күтәрелде биеккә.
Лачын кошлар җырын җырлый-җырлый,
Халыкларны дәште ирекккә.
Давыл кошы булып ул кычкырды
Ирек алып давыл килүен;
Өйдән-өйгә кереп ул сөйләде
Ил йөрәге ничек тибүен.
Булычовлар дөньясына карап,
Әче нәфрәт уты чәчте ул...
Дошман киртәләрен тар-мар итеп,
Шигъри талантларны ачты ул.
Кеше рухы инженеры булып,
Иҗат бөеклеген бирде ул;
Күкрәү булып яңгырый аның сүзе,
Илдән илгә күчеп йөри ул.
Даһи Горький исән,
Исән аның иҗат юллары,
Исән аның данлы «Ана»лары,
Исән аның көрәш җырлары.
Ул чакыра фашизмга каршы,
Ул чакыра дөнья бәхетенә:
— Давыл... яңа давыл килә! — диеп
Кычкыра ул дөнья өстенә.

17

Речьләр дәвам итә.
Залыбызга
Нурлар төшә Ватан таңыннан.
Ә шагыйрьләр һаман агыла тора;
Трибунага чыга акыннар.
Ватанымның йөрәк тибешен алып,
Яңгырап керә радио дулкыны...
Миллионнарның күмәк җыры булып
Йөрәкләрдән чыга шатлык ялкыны:
— Талантларның чын Ватаны бу ил,
Кыя таудай тора яктырып...
Алсу нурлар сибә кешелеккә,
Иңбашында кояш яндырып.

Бай табигать хәзер шундый юмарт:
Көмеш яңгыр сибә кырларга,
Яңгыр аша кояш күзен кыса
Тракторчы егет, кызларга.
Диңгез буйларында, чәчәкләрдә,
Чагылып китеп нурлар уйныйлар...
Шат йөрәктән чыккан яз җырлары
Һаваларга очып яңгырыйлар.

. . . .
. . . .

Без хаклыбыз хәзер зур бәхеткә;
Без хаклыбыз ялга, хезмәткә;
Без хаклыбыз ирек һәм белемгә;
Без хаклыбыз олуг хөрмәткә.

18

Шул бәхетне җимерер өчен дошман
Сугыш кырларына атыла...
Шул бәхеткә каршы явыз варвар
Сатлык көчекләрен арттыра:
Шыңшып, шуышып йөри ул еланнар,
Төс үзгәртеп агу сибәләр...
Кыя тауга бәрелеп ул көчекләр
Нәләтләнеп тар-мар киләләр.
Соңгы каты көрәш алда әле,
Без беләбез кемнен җиңәсен...
Без беләбез алгы көрәшләрдә
Фашизмның тар-мар киләсен.
Һәм килер барлык палач этләргә
Иң соңгы һәлакәт еллары...
Халыклар тупланыр ул байракка
Күтәреп зур җиңү җырларын:
— Инде бу безнең сугышның
Соңгысы, канлысы...
Балкый җир йөзендә
Азатлык яктысы!

1937

ХИКӘЯЛӘР, НӘСЕРЛӘР

КАЙНАР КӨННӘР

Эскиз

Аһ, ул көннәр... кайнар көннәр!

— Я үлем, я тереклек! — дип хәтердә мәңгегә калган көннәр. Юк... юк... алар һич онытылмаслар. Алар гомер-гомергә шулай кайнар көннәр истәлеге булып сакланырлар.

Үткен, җылы җил өрә. Өрә дә—җилли, җилли дә—елый. Көн җылы. Кайдадыр, бик еракта, ишетелер-ишетелмәс кенә туп тавышлары яңгырый.

Менә Самара — Идел буена, тау башына салынган таш кала. Аның кайнап торган шау-шуына, Иделнең әллә кай җиреннән үк күренгән матурлыгына нәрсәдер җитми. Анда нәрсәдер юк. Ул кемнәрнедер көтә.

Самарада интервентлар.

Ә Самара янында кызыллар. Самара кызылларны көтә.

Туплар тавышы яңгырый. Туплар тавышына кушылып, җир елый. Җир белән бергә кешелек дөньясының кайгы-зарына колак салып килгән Идел дә елый.

Самараны талап өлгергән интервентлар, кызылларның якынлашуларын ишеткәч, куркуга төштеләр.

— Нишләргә? Мукшы Чапай килә...

— Каршы торып үләр хәл юк...

— Димәк китәргә...

— Әйе, Самараны ташлап китәргә...

— Ә куып җитсәләр?

— Күперне шартлатырга...

Киңәш озакка бармады. Европа пиратлары качарга җыендылар.

Товар төягән поездлар Самара тауларына таба шуалар. Ләкин тимер юлчылар пиратларга каршы баш күтәрделәр. Китәргә дип кузгалган поездлар кинәт туктадылар.

Чапай отряды Кряж станциясенә килеп җитте.

Ак бандитлар күперне шартлатырга приказ бирделәр. Шартлатылган күпер буйлап, Самарка суы кочагына тәгәрәп дүрт вагон спирт төште.

Җимерек күпер өстенә басып, Чапай үзенең кыю сугышчыларына эндәште:

— Иптәшләр! Эшче-крестьян массасының безгә баглаган ышанычын истән чыгармыйк. Менә монда, мин баскан җимерек күпер астында, качак акларның тупас хәйләләре ята. Алар безгә спирт калдырганнар. Аңык булыгыз, спиртка сузылмагыз. Тимер дисциплина йомшамасын. Тимер юлчылар качакларның юлларын кистеләр. Самарада каты сугыш булачак. Күрәсез, тимер күпер шартлатылган, агач күпер яндырылган. Ләкин утта янмыйбыз, суда батмыйбыз дигәндәй, без Самарага керергә тиешбез. Көймәләр ясап, йөзеп, җәяүләп... шартлатылган күпер аша — Самарага... Ленин өчен, туган ил өчен минем арттан!..

Чая командир алга атлады. Аның артыннан бөтен отряд кузгалды.

Шул.

Менә шул көннәр әле булса минем исемдә.

Чапай иптәшнең җимерек күпер аша, туп тавышлары астында: «Минем арттан!»—дип алга очуы, иң беренче булып Самарага аяк басуы әле булса күз алдымда тора.

Ах, ул көннәр... кайнар көннәр!

— Я үлем, я тереклек!—дип хәтердә мәңгегә калган көннәр. Алар һич онытылмаслар. Алар гомергә шулай кайнар көннәр истәлеге булып сакланырлар.

1924

СОЛТАННЫҢ БЕР КӨНЕ

I

Солтан бүген дә алтыда уянды. Уянуы белән ул сикереп урыныннан торды. Аның беренче эше: «Сәлам сиңа, яңа көн!» — дигәндәй, тәрәзәне ачып җибәрү булды.

Йөзгә яңа көннең хуш исе бәрелде. Солтан, тәрәзәгә килеп, бер-ике минут саф һава иснәп ләззәтләнде.

Һәр көн сәламәт уяну, һәр яңа көнне исән каршылау — никадәр бәхет! Кичә тоташтырып калдырылган радио котлау сәламен китерде. Бүлмәдә миллионнар гимны булып:

Ши-ро-ка страна моя род-на-я...

җыры яңгырады. Якты, көр тавыш белән Москвадан тапшырылган бу җыр Солтанга шәһәрләр, колхозлар, диңгезләр, урманнар аша очып йөреп, илгә иртәнге смотр ясый кебек тоелды.

Бу минутта ул нәрсәләр турында гына уйламады! Аның күз алдыннан ниләр генә үтмәде!

Бәхетле хисләр белән ул тәрәзә аша ишек алдына карады. Яз көне ул анда төрле-төрле чәчәкләр утырткан иде. Алар хәзер үскәннәр. Менә өч ай инде алар: «Яшь егетнең көне ямьле булсын!»—дигәнсыман, ал, зәңгәрсу башларын иеп, Солтанга котлау сөйлиләр. Солтан аларга су сибә, сына башлаганнарын агачка бәйләп ныгыта, чүп үләннәрне өзеп ташлый һәм арадан иң матур чәчәкне йөрәк дустына бүләк итәргә дип билгеләп куя. Сайланып куелган роза чәчәгенә сокланып карап тора. «Минем Розам розалар ярата. Саф, матур чәчәк! Бүген син аның күкрәгенә менеп утырырсың. Ул сине кочар, йөзенә сыйпар, синең хуш исең белән исерер. Ярату нинди рәхәт! Роза. Розам»,— ди ул авыз эченнән.

Бүген дә кич белән аның бүлмәсендә Розаның тавышы яңгырар, ачык тавыш бүлмәне гөрләтер. Алар бергә Мопассанны һәм Тукайны укыйлар. Яңадан бер кат Пушкин, Роллан, Горький китаплары да шулай укылдылар. Кичә Роза Солтанга Мопассанның мәхәббәт турындагы бер хикәясен укып чыкты. Бүген дә бәлки укыр. Розаның укуын тыңларга ярата ул.

Роза турында уйлый-уйлый, Солтан чәчәкләргә су сибә. Бүлмәгә кайтып иртәнге зарядка ясарга тотына. Аннан соң бакчага чыга. Ул анда үз кулы белән душ ясаган иде. Бу душта эссе көннәрне бер-ике тапкыр Роза да коенды. Шунда хәзер Солтан коена. Салкын су каннарны уята, тәнне яшәртә: ул үзендә көч артканны сизә, эшкә хәзерләнгән ми ачылып киткәндәй була, тәнгә тынычлык урнаша. Рәхәтлектән, бер җир дә авыртмаудан: «А-һ! И-и-и-х!» дип кычкырып җибәрәсе килә, ләкин түзә, кычкырмый. Шулай да, назсыз үткән балачагын искә төшереп, үз-үзенә сөйләнә: «Без егерме биш яшьтә балаларча шаяра беләбез»,— ди. Ул су тамчылары белән уйный; тамчыларны тотарга теләп, бөтен тәне буенча кулларын йөртә; күзләрен йома.

Розасы аның шундый матур, шундый матур... аның матурлыгын сурәтләрлек көч миндә дә, Солтанда да юк. Озын керфекләр астыннан карап торган сөйкемле зәңгәр күзләр. Алар бөтен нәрсәгә дә: «Мин моны аңладым. Мин моны үтә күрәм»,— дигән кебек, тирән карыйлар. Бу якты күзләргә карап утырган минутларны Солтан:

> Нинди көчләр, сөйлә, нинди көчләр
> Керфек очларыннан агалар? —

дип җырларга ярата. Һәрвакыт елмаюлы иреннәр. Күзләр яхшы әйбергә төшкәндә, бу елмаю — шатлыклы, начар әйбергә төшкәндә—ризасызлыкны күрсәтә. Нечкә бил, саргылт чәч, калку тере күкрәк. Тик утырганда да очарга хәзер торган җитез хәрәкәт.

Солтан икс-өч тапкыр Розаның рәсемен ясарга дип, тотынып караган иде, ләкин, рәсемне эшләп бетерәм дигәндә генә, ул: «Юк, Розам, булмый: синең матурлыгыңны буяу аша бирер өчен Рафаэль яки Репин кебек бөек художник булырга кирәк», дип зарланды.

Ул шуларны уйлады һәм, Розаның «Матур тормышта, сөеклем, ямьсез кеше дә чибәрләнә»,— диюен хәтерләп елмайды. Җәй көне велосипедта, кыш көне конькида кош шикелле очып йөргән Розасын тизрәк күрәсе килде. «Ул да хәзер мине уйлыймы икән?» дип, аның нәрсә уйлавын белергә тырышты; үзе турында, Солтаны турында, уйлавын теләде. Бергә үткәргән кадерле минутларны искә төшерде. Быел җәй алар Зәңгәр күлгә барганнар иде. Солтан аңа шунда йөрәктә кайнаган татлы хис-

ләрне, бер үк вакытта авыр да, рәхәт тә тоелган кичерешләрне сөйләргә теләгән иде, ләкин сөйли алмады, Розага карап тик утырды. Шунда ул Розаның бөдрә чәчен энҗе чәчәкләре белән бизәде һәм эчтән ярату сүзләрен әйтеп, тыштан: «Кешенең күз карашына сүзләр салып һәм аларны укып булса иде!» диде. Моңа җавап итеп, Роза сузынкы шаян тавыш белән: «Әй-е, ул чагында мин си-нең күз-лә-ре-ңә минем өчен генә язылган мә-хәб-бәт ки-та-бы итеп карар идем», диде...

Күзләр тәрәзә янындагы өстәлгә, андагы дәфтәрләргә, китапларга төшәләр. «Хәзер... хәзер... мин үзем дә сезне сагындым!» дип, ул өстәлдәге әйберләр белән сөйләшә. Хуҗа хатыны какао һәм бутерброд кертә. Радиода Москвадан тапшырылган иртәнге хәбәрләр яңгырый. Аларны тыңлый-тыңлый, ул туган иле белән, бөтен дөнья белән кушыла.

Бер генә хәбәр дә аны тыныч калдырмады.

Иртәнге хәбәрләрне тыңлаганнан соң, ул ике-өч минут Розаның рәсеменә карап уйланып утырды: «Бәхетле без, Роза, бәхетле! Без кол түгел. Аңлыйсыңмы, җаным, кол түгел. Безнең бәхетнең, безнең шатлыкның зурлыгын, киңлеген белер өчен чит илләрдәге фаҗигаләрне аңларга кирәк. Тормыш анда — ике катлы. Беренче катта — аз санлы хуҗалар һәм аларның приказчиклары — министрлар. Анда мәзәк уйнала, анда вакыйгаларның алмашынуына карап грим үзгәртелә. Ә икенче катта — илнең төп хуҗасы — халык. Ул фаҗига кичерә, төрмәләрдә газап чигә, ачка үлә. Ул богауда утыра. Ләкин ул көчле. Богаулар мәңге яшәмиләр. Богауларның өзелә торган гадәте бар».

II

Богаулар турында уйлана башлау Солтанны кара болытлы үткән тормышка алып китте. Аның атасы да богауда булган һәм богаулы килеш үтерелгән. Ләкин атасын ул бөтенләй күргәне юк.

Моннан бик күп еллар элек Солтаннар авылында зур кузгалыш булган. «Аны, бу кузгалышны, Солтанның атасы Харис абзый оештырган иде»,—дип авылда хәзер дә сөйлиләр. Бичара ана Солтанны табу газабында җәфаланып ятканда, баш күтәргән атаны богаулап авылдан алып киткәннәр. Сагынганда карар өчен

нәләт заман атаның рәсемен дә калдырмаган. Ләкин Солтан әнкәсеннән ишетеп алган җылы сүзләр буенча атасын батыр, кыю итеп күрергә тырыша. Әнкәсе исән чагында: «Әтиемнең тавышы нинди иде? Йөреше ничек иде?»—дип күп кенә сораулар биреп килде. «Атаң бик күп ягы белән сиңа охшаган иде», — дигәч, ул чиксез дәрәҗәдә куана һәм үзе дә батыр булырга омтыла иде.

Үткән ел Солтан авылга кайткач, картларны күреп, алардан атасы турында, кузгалышның ничек башланып, ничек бетүе турында озак сорашкан иде. Шунда җыелган материалларны җентекләп акка күчерде һәм атасының үлем алдында язылган бердәнбер хаты янына җыештырып куйды. Саргаеп, урыны-урыны белән ерткаланган һәм җилем белән икенче бер кәгазьгә ябыштырылган бу хатта түбәндәге сүзләр язылган иде:

«Кадерле хатыным һәм балаларым!

Мин бу хатны сезгә палачлар муеныма бау салырга җыенган вакытта язам. Соңгы хушыгыз сүзен дарга озатылыр алдыннан кычкырам. Хуш, улым Әхмәт. Хуш, беренче мәртәбә дә, соңгы мәртәбә дә мин үбә алмаган нәни балам. Кем син — белмим: кыз булсаң да, ул булсаң да батыр булып үс! Еламагыз.

Башларыгызны югары күтәрегез!

Харис».

Солтан хатның бер сүзен дә калдырмыйча яттан укып чыкты. «Дүрт кешелек семьядан бер ялгызым калдым» дип уйлап, ул абыйсын сагынды.

Империалистик сугышка алынып, хәбәрсез югалган Әхмәт турында Солтан бик аз нәрсә белә. Абыйсыннан хат килгән саен, әнкәсенең үксеп-үксеп елавын гына хәтерли ул. Ә 1915 нче елны Әхмәттән хатлар килү дә тукталды. Яраланып кайткан авылдашлары ул авыр елларны: «Без позициядә бер полкта идек. Әллә плен төште, әллә мескен бөтенләй харап булды, әйтүе кыен»,— дигәннәр иде. Ачы вакыйгалардан соң кайгылы ана Солтанны кочагына алып: «Әхмәт абзаң сине бик ярата иде, син бик шаян идең. Син аның чәчләрен йол-

кый идең, ә ул йокларга ятканда да сине кочагына алып ята иде», дип, күп кенә нәрсәләр сөйләде.

Солтан матур пыяла рамага куелып стенага урнаштырылган ана рәсеменә карады; эчкә баткан сагышлы күзләр, авыр хезмәт җыерчыклары, аз гына елмаю. Бүлмәнең кайсы почмагына гына китсә карамасын, рәсемдәге күзләр гел аңа, Солтанга, карыйлар кебек һәм: «Бәхетле тормышның кадерен бел, бәбкәм. Атаңа, миңа һәм абыеңа ул тормыш тимәде. Күз карашым ник кайгылы дисеңме? Шатлык күрмәгәнгә, улым, шатлык күрмәгәнгә. Минем чорда шатлык дигән нәрсә төшкә дә керми иде», диләрсыман.

Абыйсын Солтан гел истә тотарга, аны үлмәгән, бары каядыр ерак юлга китеп югалган җан дустыдай күз алдына бастырырга өйрәнгән. Менә хәзер дә ул аны күргәндәй булды һәм абыйсы, имеш, ишекне ачып керер дә: «Солтан монда торамы?» дип, энекәше белән килеп күрешер төсле.

Әнисе үлгәч, бөтенләй ятим калган Солтан күз күрмәгән якларга китеп, бәхет эзләп йөрде. Вагон асларына утырып, унар мең километр җирләрне гизде. Абыйсын һәм әнкәсен искә төшерми калган бер генә көн дә булмады. Ә хәзер... хәзер ул бәхетле. Кеше үтерүчеләргә кабынган нәфрәт һәм ватаныбызның балаларга булган кайнар мәхәббәте, җылы илтифаты аны аякка бастырдылар. Революциянең беренче елларында ук илнең яңа хуҗалары, аны урам кочагыннан тартып алып, приютка бирделәр. Анда Солтанны юдылар, киендерделәр, җылыттылар һәм ашаттылар, кулына китап тоттырдылар. Ул чакны урам шау-шуыннан аерылырга теләмәгән Солтан тартышты, коткарырга килгән иптәшләрнең кулларын чәйнәде, аларга карата байтак әшәке сүзләр әйтте.

Күп еллар буенча башыннан кичкән хәлләрне икеөч минут эчендә күз алдыннан үткәреп, «Кем иде алар? Күрсәм танып идем. Иң якын кешеләрем итеп үбәр идем үзләрен» дип, урам кочагыннан тартып алучы иптәшләр турында уйлады. Берсе арты берсе туган фикерләр аны Педагогия институтына алып керделәр. Институтны бетереп чыгу көнен хәтерләде. «Розам да бүген тәмам итеп чыга бит»,— дип, Розасы өчен дулкынланды. «Борчыла торгандыр, акыллым», дип, Розаның диплом алдындагы рухи халәтен белергә тырышты..

III

Солтан сәгатенә карады: вакыт җиде генә иде әле. «Кеше! Син никадәр катлаулы... биш минут эчендә күпме нәрсә уйланылган!» дип, ул укучыларның кичә каралып бетмәгән дәфтәрләрен төзәтергә кереште. Бу дәфтәрләр яңа уку елында беренче диктант дәфтәрләре иде.

Үткән ел Солтан укучыларның хаталарын теркәп барыр өчен бер журнал ясаган иде. Быел да шуны дәвам итәргә булды. Зәйнетдинов язган диктантны карап чыкканнан соң, ул әлеге хаталар журналына күз төшерде: йөзгә шатлык балыкты.

Бүтән диктантлар да Солтанны куандырдылар. Тик Хәбибуллин дәфтәре генә кәефне бозды. Гаҗәп хәйләкәр укучы бу — Хәбибуллин: дәрескә соңга калып килүче дә ул, иң җитди әйберләрне аңлатканда, көлке сораулар биреп, укучыларның игътибарын икенче якка юнәлдерүче дә ул. Пушкин турында сөйләгәндә, мәсәлән, «Что такое по-русски «камил акыл»?» — дип сүзне бүлде дә куйды. Бөтен класс, әлбәттә, шаркылдап көлеп җибәрде. Ләкин акыллы кыяфәт ясаган Хәбибуллин үзе көлмәде, баскан урында тора биреп җавап көтте. «Андый сорау нигә кирәк булды соң?» — диюгә: «Минем бабай бар иде, зерә кызык карт иде, үлеп харап итте, мескен, — дип аңлатырга тотынды, — менә шул бабай кешедә, улым, өч төрле акыл була, ди иде. Берсе, ди, аның ярты акыл. Ул, ди, ахмак кешеләрдә генә була, ягъни дуракларда. Икенчесе, ди, гади акыл. Гади акыллы кеше, ди, акчаны да дөрес санар, юлны да табар, ак белән караны да аерыр. Ә өченчесе, ди, камил акыл. Моның, ди, бөтен акылларга акыл, русча всем акылам акыл була торгандыр инде. Камил акыллы кеше, ди бабай, юлны табу гына түгел, аның кая алып барганын да белер, ди. Пушкинның акылы, мин әйтәм, камил акыл булырга тиеш. Шуны русча беләсем килгән иде».

Хәбибуллинның кешедән күчерелеп язылган диктантын төзәткәндә, Солтан әнә шул вакыйганы хәтерләде. Кечкенә буйлы укучының тырышыннан, өч төрле акылны Пушкинга бәйләп аңлатуыннан көлеп җибәрде. «Ә диктант белән нишләргә? Нигә күчереп язган? Юк, Хәбибуллинның үзен яхшырак өйрәнергә кирәк

булыр. Минемчә, ул ялкау һәм хәйләкәр. Кайчагында бит үткен сүзләр ялкаулыкны, эшсезлекне каплау өчен дә кулланыла. Хәбибуллинда да шул»,—дип, Солтан диктант дәфтәрләрен җыйнак итеп кенә шкафка куйды һәм кичә хәзерләнгән дәрес конспектын тагын бер кат күздән кичерергә кереште; тел дәресенә карата яңадан берничә мисал арттырды.

Вакыт тугызынчы ярты гына иде әле. Дәрескә хәтле сәгатьтән артык вакыт бар. Көндәлек гадәте буенча ул инглиз китабын алып өч-дүрт сүз ятларга булды. Яңа сүзләр кергән инглизчә биш җөмләне куен дәфтәренә күчереп алып ятларга тотынды. Шуларны кычкырып кабатлый-кабатлый идән буенча йөрде. Башта ят тоелган бу серле җөмләләрне, табигый рәвештә үзләштерү өчен, үзгәртте, алардан икенче төрле җөмләләр ясады. Шуннан соң Байронның дүрт юллык шигырен тикшереп чыкты һәм Шекспир, Байрон шикелле бөек талантларны тиздән үз ана телләрендә, инглиз телендә укый алачагына куанды.

Менә бер ел инде Солтан аспирантура өчен имтиханнар бирергә хәзерләнә. Шул максатка ирешү юлында ул бер генә көнен дә әрәм итәргә, эзсез калдырырга теләми.

— Кичә? Кичә нишләдем соң әле мин? Һич хәтерли алмыйм. Тик йөреп үттемени көнем?

— Их, шайтан алгыры! Бер ай вакытым әрәмгә үткән дә киткән...

— Минем белән бергә укыган фәлән иптәш инженер булган инде. Ә мин... мин бер урында туктап калганмын. Әйтергә дә куркыныч: ике-өч елым бушка узган...

Менә шулай сөйләүчеләрне Солтан чын күңеленнән кызгана. Эшләрен һәм ял сәгатьләрен тиешле тәртипкә салу аркасында, ул һәр көн диярлек үз өстендә эшләргә, үзенең белемен арттыра барырга, фән кандидатлыгына хәзерләнергә вакыт таба.

Уйлар шул тирәгә җиткәч, Солтан елмаеп куйды. Беркөн ул Таһиров дигән танышы белән биллиард уйнаган иде. Бер сәгать чамасы уйнаганнан соң чыгып китәргә җыенган Солтанга Таһиров чын-чынлап гаҗәпләнде, үз теле белән әйткәндә, шаккатты. Һәм:

— Уйныйк инде! Кая ашыгасың? Тагын бер партия! — дип инәлә башлады.

Икенче көнне очрашкач, Таһиров:

— Их, Солтан, юкка калмадың! Син киткәч, без «мусор»га уйнадык: мин берүзем дүрт кешене «мусор»га чыгардым. Шарлар хәзер уртага майлагансыман шоп-шома барып керәләр, — дип мактанды.

— Аяклар талганчы, күзләр тонганчы биллиард өстәле янында биш-алты сәгать буена шар тәгәрәтү — җинаять түгелме? — дип, Солтан Таһировны бераз тиргәп алды.

«Юк, Таһиров — шәп егет. Бу биллиард бизгәгеннән аны ничек тә коткарырга кирәк», — дип уйлый-уйлый ул дәрескә чыгып китте. Ләкин Таһировның: «Ике борт почмакка! Дуплет уртага!» — дип уйнавы колак төбендә яңгырагандай булды.

Күңелне рәнҗеткән бу ямьсез тойгылардан котылу өчен, Солтан авыз эченнән генә көйләргә тотынды. Көй Розаны хәтерләтте. Ул эчке ләззәт, эчке рәхәтлек белән Пушкинның:

Все в ней гармония, все диво,
Все выше мира и страстей:
Она покоится стыдливо
В красе торжественной своей,

дигән юлларны көйләп трамвайны каршылады.

IV

Трамвайда Солтан үзенең авылдашын, орденлы тракторчы Гайнетдиновны очратты.

— Исәнме, дускай! — дип, ул аның белән шатланып күреште һәм бер-бер артлы сораулар бирде: — Казанда күптәнме? Хәлләр ничек? Ярышта җиңелмәгәнсеңдер бит? Колхозда ниләр бар? Адресымны беләсең ич — ник кермәдең?

Гани Гайнетдинов Татарстанның бөтен Союзга атаклы булган яшь егете иде. Үткән ел ул бер ялгызы мең гектардан артык җир эшкәртеп, рапорт белән башкалага барды...

Шунда Гайнетдинов Ленин ордены белән бүләкләнде. Аның авылга кайтып төшүе зур тантанага әйләнде. Ул чакны Солтан да авылда иде...

Гайнетдинов белән трамвайда очрашкан минутларда аның күз алдына әнә шул вакыйгалар килеп басты.

Яшь, кыю Гайнетдиновка карап, ул халык белән шыгрым тулган колхоз клубын күргәндәй булды.

— Тукта әле, тукта... Соң нишләп син кызу эш вакытында Казанда? Тракторыңны кемгә калдырдың?— дип Солтан авылдашына эндәште.

Гайнетдинов аңа үзенең тарихын сөйләп алды.

Үткән кыш ул районда курсларда укыган, быел авыл хуҗалыгы институтына студент булып кабул ителгән.

— Тагын бер ел тракторымда эшлим дигән идем, булмады, — диде ул. — Укыйсы килә, малай. Сүз юк— сынауларны яхшы бирдем. Шулай да тирләтә: математика буенча бирелгән задачаларны чыгара-чыгара кичә таң атканны сизми дә калдым. Әерып чыккач, шатлыктан йокы алмады. Иптәшләремне уятып биисем килде. Укуның тәмен татыдым, парень!

— Котлыйм, котлыйм... Ә хәзер кая бару?

Бу сорауга Гайнетдинов елмайган да кебек, аптырап та киткән кебек булды:

— Иртәгә ял көне бит: колхозга кайтып килмәкче булдым. Бригадам сагындырды.

— Ма-һи-нур да-мы? — диде Солтан, сузып.

Бу сорау Гайнетдиновны рәхәтләндерде. Тирән бер җылылык белән:

— Ул да! — дип җавап бирде.

Солтан белән очрашканда, Гайнетдинов ялгыз гына түгел иде: аның янында танышы, студент Петр Власов та бар иде. Шуңа күрә сүз ярым русча, ярым татарча барды. Өч кешенең көлешә-көлешә шатланып сөйләшүен бөтен трамвай кызыксынып күзәтте. Егетләргә якын утырган бер карт, күршесенә борылып:

— Әнә тегесе дәү кеше булырга кирәк, — диде, — күкрәгенә карагыз: ордены бар. Минем Коленькамның да ордены нәкъ шундый. Ә Коленька кечкенә кеше түгел, полковник ул.

Шул вакыт вагонның икенче почмагында быелгы искиткеч урожай турында сөйләшә башладылар. Арадан берәү үзенең сүзен раслар өчен Гайнетдиновка эндәште.

Гайнетдиновлар башлап җибәргән сүз, алар вагоннан төшеп киткәч тә, бик озак дәвам итте, телдән телгә сөйләнеп, өйләргә күчте.

V

Мәктәп янында Солтан көндәлек күренешкә очрады. Дәресләр башланганнан бирле һәр көн аны бишун укучы урамга чыгып каршы ала. Бүген дә каршыладылар.

— Исәнмесез, Солтан абый! — дип сәламләргә, берәр җылы сүз әйтеп ихтирам күрсәтергә ашыктылар.

Үткән көннәрдәге кебек үк, бу юлы да Солтан мона куанды, үзе дә сәламләп җавап кайтарды: кайсының кулыннан тотып, кайсының башыннан сыйпап, кайсына сүз кушып иркәләде. Ләкин мәктәпкә кереп барганда, моннан соң алай каршыларга кирәкмәүне аңлатырга тырышты.

— Сезнең яхшы укуыгыз — безнең өчен шатлык, дәрестә яхшы утыруыгыз — куаныч. Ә урамга чыгып шау-шу ясау, каршы алу кирәк түгел. Сүземне тыңлагыз, моңа мин һич риза түгелмен,— диде.

Мәктәптә ул, балалар дулкынын ерып, озын коридор буйлап укытучылар бүлмәсенә узды. Элгеч янында туктап пальтосын, эшләпәсен салды, көзге янына басып чәчен тарады, галстугын төзәтте. Тик шуннан соң гына иптәшләре белән берәм-берәм күрешеп чыкты. Хәбибуллин укый торган класска җитәкче итеп беркетелгән ана теле укытучысы белән сөйләште. Хәбибуллин мәсьәләсенә башка укытучыларның да игътибарын җәлеп итте.

— Әйе, ул балага хәзердән үк тиешле чараларны күрергә кирәк! — диде арадан берсе.

— Математикадан «отлично»га бара ул.

— Бөтен бәла дә шунда: бер математиканы гына белә шул. Ә башка дәресләр буенча дәфтәрен дә ачып карамый, — диде класс җитәкчесе.

— Ялкау һәм хәйләкәр. Немец телен санга да санамый. «Дер, дие, дасларны ятлап утырырга минем вакытым юк. Башны авырттыра ул», — ди.

Шул рәвешчә сөйләшү звонокка хәтле дәвам итте. Ана теле укытучысы бүген үк Хәбибуллинның өенә барырга, аның ата-анасы белән сөйләшергә булды.

Карт педагог математик Һашим Шакирҗанов, бүлмәдән чыкканда, Солтанга карый-карый чыкты. Яшь укытучыга карата аның берәр җылы сүз әйтәсе килде.

Үткән ел Солтан укытучылар арасында политтүгәрәк алып барды. Беренче беседадан соң ук Һашим Шакирҗанов аның методына сокланды. Политик мәсьәләләрне

жиңел итеп, дөрес һәм тирән аңлатуын яратты. Шуннан соң ул бер генә утырышны да калдырмыйча йөрергә, Солтан тәкъдим иткән китапларны укырга, ул сөйләгән фикерләрне конспект рәвешендә язып барырга тотынды.

Солтан белән янәшә чыгып барганда, математик Һашим әнә шуларны хәтерләде. «Советлар илендә яңа тип халык укытучылары үсә», дип уйлады.

Солтан төрле рәсемнәр һәм схема-таблицалар белән бизәлгән рус теле һәм әдәбияты кабинетына керде. Укучылар аны аягүрә каршы алдылар.

— Исәнмесез, балалар! — диде ул елмаеп.

— Исәнмесез! — дип аңа җавап кайтардылар.

Ул күзләрен йөртеп кемнәр дәрестә юк икәнлекне белергә тырышты. Яхшы педагогларда гына була торган гадәт буенча ул инде нинди баланың кайда утыруына хәтле күнеккән иде. Бүген исә күзгә чагылырлык бер генә буш урындык та юк. Димәк, класс йөз проценты белән дәрестә. Шулай да куелган тәртипне бозмас өчен исемлек буенча: «Әпсәләмов, Әминова, Биктимиров»,— дип, балаларны тикшереп чыкты. Һәр фамилия саен Солтан күзе алдыннан бер китап язарлык төрле күренешләр, вакыйгалар, кешеләр үттеләр.

— Әпсәләмов!

Укучы «мин» дип җавап биргәнче, Солтан башына секунд тизлегендә, берсен-берсе каулап, төрле уйлар килделәр. «Тырыш укучы, әлбәттә, очучы булачак. Беркөн күрсәткән планер моделе бик һәйбәт иде. Үткән җәй Әпсәләмов бер моделен сатып, аэродромга самолетта очарга барган. Анда аны бушлай очыртканнар. Шуннан кайткан да, моделен баладан кире дауларга тотынган. «Бир, мин сиңа бүтәнне ясармын, моны мин пилотка бүләк итәм», — ди икән».

— Әминова!

— Мин! — диде алдагы партадагы укучы. Ә Солтан башыннан яңадан уйлар йөгерделәр. Әминова аңа кай җире беләндер әнкәсен хәтерләтте. Тургеневның «Муму»сын тикшергәндә, кинәт елап җибәргән бу йомшак күңелле укучы аңа бик нык тәэсир итте. Аның һәрбер чәчәкне, һәрбер үләнне кеше өчен шифалы итәргә теләве киләчәктә яхшы врач булачак кешенең теләге булып тоелды.

— Биктимиров!

— Мин!

«Шагыйрь, — дип уйлады Солтан. — Зиһене гаҗәп. Пушкинның «Чегәннәр»е турында кайчан сөйләрмен әле, ә ул аны ятлап та өлгергән инде».

— Батыршин!

— Мин!

Инженер булыр ахры. Оста математик. Һәр көн диярлек мәктәпкә үзе уйлап чыгарган уенчыклар яки башваткыч задачалар алып килә.

— Зиннуров!

Зиннуровның гаскәриләрчә ачык итеп, өзеп «мин» дип җавап бирүснә класс кына түгел, Солтан үзе дә көлеп җибәрде. Чирек секунд эчендә ул Зиннуровны кинода — «Чапаев» картинасында күрде. Аның картинаны бирелеп каравын хыял итте. Атаклы фильмны карап кайтканнан соң Зиннуровның кызып сөйли-сөйли онытылып китүен, өстәлләр өстенә урындыклар тезеп, бүлмәне крепостька әйләндерүен күргәндәй булды. Икенче чирек секундта Солтан: «Кемнәр генә үсми безнең балалар арасында! Зиннуров, һичшиксез, Советлар иленең полковнигы булыр», — дип уйлады.

Бөтен балаларны да шулай күздән кичергәннән соң, ул дәрескә кереште. Бүген ул Пушкинның «Авыл» исемле шигырен узарга тиеш иде.

Башта ул, Пушкинның тормышыннан һәм иҗатыннан мисаллар алып, классны даһи шагыйрьнең бөек уйлары, матур тойгылары белән сихерләде.

Бөтен дөнья шагыйрьләре арасында Пушкинны Солтан аеруча нык ярата. Һәр укуында ул бу бөек шагыйрьдән яңа тәм, яңа ямь таба. Менә хәзер дә, бөтен класс алдында «Авыл» шигырен укыганда да: «Никадәр көчле сүзләр, нинди кискен фикерләр», — дип уйлады ул.

Үзе укып чыкканнан соң, шигырьне укучыларның үзләреннән укытты. Хата укылган юлларны кат-кат әйттереп, дөрес укуны таләп итте. Шагыйрьнең фикерләренә, әсәрдәге образларга, сүзләрнең нинди мәгънәдә кулланылуларына игътибарны җәлеп итәр өчен, укучыларга төрле сораулар бирде. Солтан: Хәбибуллин бу класста укыса, «Пушкинның акылы, бабай әйтмешли, камил акыл булган шул», дияр иде, дип уйлады.

Шигырьне аңлау өчен ясалган тикшерү күңелле узганга күрә, дәреснең бетүен укытучы да, балалар да сизмичә калдылар. Солтан:

— Шигырьне дәфтәрләрегезгә күчерегез һәм беренә чаклы ятлагыз. Исән булыгыз! — дип тәнәфескә чыкты.

Беренче тәнәфесне ул балалар арасында уздырды.

Үткән ел Солтан балаларның русча сөйләү телләрен көчәйтер өчен рус драма түгәрәге оештырган иде. Яхшы үткән ике спектакль әдәби әсәрләрне аңлау эшендә генә яки күңел ачуда гына түгел, балаларның телләрен төзәтүдә дә сизелерлек җимешләр бирде. Яшь талантларның барлыгын ачты. Шул эшне яңартырга теләп, ул драма түгәрәгенең старостасын күрде һәм берсекөнгә дип репетиция сәгатен билгеләде. Мөмкин хәтле тизрәк профессиональ артист булырга теләгән һәм һәр спектакль саен иң зур рольне үзе башкарырга яраткан укучы Сәйфетдинов моңа бик куанды.

— Әй, драмтүгәрәк артистлары! Берсекөнгә русча спектакльгә ырпетиция! — дип кычкыра-кычкыра бүлмәдән бүлмәгә чабып китте.

Солтан аны кайтарып:

— Ырпетиция түгел, репетиция, ре-пе-ти-ция,— диде.

Укытучы янында басып калган унбиш яшьлек комик Моталлап, Сәйфетдинов киткән якка карап:

— Безнең Шөгерский барын да булдыра,— дип куйды һәм Сәйфетдиновның репетиция сүзен бозып әйтүеннән көләргә теләп, — Шөгерский тотынса, ырпитыйция гына түгел, әлләниләр булыр, әкәмәт, — дип өстәде.

— Алай ярамый, Моталлап. Без кушаматларга каршы көрәшәбез, — дип, Солтан комикны үгетләргә керешә.

Күрше бүлмәдән бер төркем укучыларның:

...Бәхетле булып тудык без
Бу якты илдә,
Хуҗалар булып калырбыз
Мәңге бу җирдә!
Мәңге бу җирдә! —

дип, «Шатлыклы яшьлек» җырын җырлаулары ишетелде.

— Әнә, ишетәсеңме, нәрсә җырлыйлар! — диде Солтан Моталлапка: — синеңчә, ничек, бәхетле илдә хуҗа булып калучы буын кушамат исемнәр белән шөгыльләнергә тиешме?

— Артык һич әйтмәм, — диде Моталлап.

Дәрескә керергә звонок булды. Җыр өзелде.

— Рәхмәт! — дип, Солтан Моталлапның аркасыннан сөйде.

Моталлапның сүз бирүе Солтан өчен кыйбат иде. Ул яхшы белә: Моталлап сүз бирдеме — бетте, үзе дә әйтмәс, башкалардан да әйттермәс.

Күңелдә рәхәт канәгатьләндерү тудырган уйлар белән Солтан дәрескә керде.

VI

Бу яңа класс иде.

Монда да ул иң элек исәнләште, исемлек буенча укучыларны тикшереп чыкты. Үткән дәреснең ни дәрәҗәдә үзләштерелүен белде. Тик шуннан соң гына яңа кагыйдәләргә, күнегүләргә күчте.

Бу юлы Солтан, алдан хәзерләнгән кызыклы мисалларны кулланып, рус телендәге алмашлыкларның дөрес язылышларын аңлатты. Балаларны тактага чыгарып, җырлардан, атаклы язучыларның әсәрләреннән алынган җөмләләр яздырды.

Кызыклы җөмләләр ярдәме белән Солтан балаларны программага кермәгән ике әсәр белән таныштырды һәм аларны укып чыгарга киңәш бирде.

Озын тәнәфестә ул укытучылар бүлмәсенә керде.

Бүгенге газеталарны карый-карый ул онытылып китте. Конституция проекты уңае белән басылган шатлыклы хәбәрләрне, яңа тәкъдимнәрне укып чыкты. Испания республикасына багышланган сәхифәгә күз төшерде.

— Мин әле карарга өлгермәдем: нинди яңалыклар бар, Испаниядә ни хәл? — дип берәү аңа сорау бирде.

Солтанга бирелгән бу сорауны ишетүгә, бөтенесе дә математик Һашим Шакирҗановка карады.

— Әйе, әйе, — диде Солтан, — Һашим абзый сөйләсен.

Укытучылар арасында атаклы радист-пропагандист булып танылган математикка шул җитә калды.

— Кичә, туганкайлар, Мадридны тыңладым мин, — дип ул башлап та китте.

Илле яшьләр чамасындагы Һашим Шакирҗановка утыздан артыкны берәү дә бирмәс. Нык, таза, яшь күренүе белән мактала ул. Мәктәпкә килеп чыккан һәрбер

яңа кешегә укытучылар, Һашим абзыйны күрсәтеп, «Менә бу батырга ничә яшь бирер идегез?» — дип сорыйлар. Һәм һәрвакыт ялгыш җавап алалар. Бит алмалары кызарып торган Һашим абзый киң итеп елмая да: «Минем даруым бар»,.— дип, үзенең илле биш яшьтә булуын әйтә. Аны ел буе бөрөзлексез һәр иртә-кич су керә дип сөйлиләр. Даруы да, бик ихтимал, шулдыр. Илнең матур һавасы, саф суы, җылы кояшы турында сөйләргә ярата ул.

Беренче караштa усал күренгән, озын буйлы, эре яңаклы, калын тавышлы бу укытучы гаҗәп яхшы иптәш һәм яхшы математик иде. Солтан аны иптәшләре арасында «Бала йөрәкле великан» дип атаган иде. Канатлы җөмлә яшен тизлеге белән бөтен мәктәпкә таралды. Бу нәрсә Һашим абзыйның дәрәҗәсен тагы да күтәрә төште. Озын буйлы укытучының кеп-кечкенә балалар арасында радиоаппаратлар ясап йөрүен күргәч, элек көләләр иде. Ә хәзер юк. «Бу шулай булырга тиеш. Башкача булуы мөмкин дә түгел», — дип яратып сөйлиләр. Һашим абзыйның исемен җылылык белән телгә алалар.

Һашим Шакирҗановны тыңлый-тыңлый, Солтан әнә шуларны уйлады. «Нинди шәп агитатор, сизми торганбыз, — диде ул эченнән, — бу эшне бит аңа берәү дә йөкләмәде. Испаниядәге хәлләр турында бер тапкыр дөрес аңлатма биргәннән соң үзеннән-үзе шулай китте».

VII

Укытучыларның хезмәт хаклары арту сәбәпле, Солтанга бүген узган айлары өчен өстәмә түләделәр. Мәктәптән ул бер кочак акча күтәреп чыкты. Дәреслек язуга катнашканы өчен әле шушы арада гына мең ярым сум гонорар да алган иде.

Бу чаклы акчаны кая куярга? Көннәр дә гаҗәп тиз үтә. Унбиш көн саен хезмәт хакы килеп тора. «Туй мәҗлесе мул булачак. Ләкин бүләксез калырга ярамый — хәзер үк барып алырга кирәк»,— дип уйлана-уйлана, ул иң яхшы магазиннарга китте. Розасын озак күрә алмауга пошынды, аның янында буласы, защита алдыннан җылы сүзләр әйтеп иркәлисе килде. Элек мәхәббәткә ышанмаган Солтан хәзер аның тирәнлегенә, йөрәк-

не кытыклап торуына шатланды. Ни бәхет! Аның сөйгән кызы, иптәше бүген инженер булып чыга.

Кара кашым, сандугачым...

дип, ул үзенең Розасы турында халыкның иң матур җырларын әйтеп барды. Бу минутта ул Розаны һәм үзен дөньяның иң бәхетле яшьләреннән хисаплады.

Әгәр берәр танышы очрап: «Солтан, син нәрсә көйлисең?» — дип сораса, бик ихтимал, нәрсә көйләгәнен ул әйтә дә алмас иде. Чөнки тормыш үзе җырлый. Ә Солтан аңа аерып ала алмаслык дәрәҗәдә бәйләнгән. Ул шул рәхәт тормыш кочагында тирбәлеп бара. Барысы да танышлар, барысы да аңа елмаялар төсле.

ТУМда ул балалар өчен пальтолар күрсәтергә сорады.

— Рәхим итегез! Балагыз ничә яшьтә? — дип, сатучы ханым Солтанга сорау бирде. Һәм: — Ир балагамы яки кыз балагамы? — дип өстәде.

Мондый сорауга хәзерләнмәгән яшь егет ничек итеп тә җавап бирергә белмәде, елмайды гына: «Кыяфәтем ата кешегә охшаган, ахры, ата булу, балалар үстерү, улым, кызым дип йөрү — күңелледер», — дип уйлады. Хыял күзләре яңадан Розаны күрделәр: «Ярый әле, сине алып килмәдем, балагыз ничә яшьтә дип оялтырлар иде үзеңне. Әллә син дә, минем кебек, шатланыр гына идеңме?»

— Ягез, иптәш, нинди размер пальтолар кирәк сезгә? — дип, сатучы ханым аның татлы уйларын бүлде.

Нинди размерлы пальтолар кирәген белмәгән Солтан:

— Ә... әйе... кызык сорау... Миңа әнә тегеләрне күрсәтегез, — диде.

— Кыз балагамы, ир балагамы?

— Карагыз әле, мөмкин булса, сораулар биреп йөдәтмәгез лә. Миңа ике-өч пальто кирәк булачак. Күзләрем кайсыларына төшсә — шуларны алачакмын.

— Ихтыярыгыз! Сайлагыз! — дип, сатучы ханым Солтан алдына бер өем пальто куйды.

— Шуннан да яхшыраклары юкмы? Миңа бик яхшылары кирәк...

— Болар начар түгел. Материясе — нык, төсләре — матур, тегелүләре — әйбәт.

— Ярый алайса, ике ир балага менә шуларны төрегез, кыз балага — әнә тегесен.

— Размерлары туры килерме соң?
— Тагын сорау...
— Бетте, бетте... Размерлары туры килмәсә, алмаштырырга мөмкин диюем генә. Тартынып тормагыз, кирәгез — алмаштырырбыз.
— Рәхмәт! — дип Солтан яңадан елмайды. — Шулай да...
— Нәрсә шулай да? — Бу юлы инде сатучы ханым елмайды. Солтан аның күзләренә карады. «Бу да, нәкъ минем Розам шикелле, матур елмая икән», — дип уйлады.
Сатучы ханым тагы да көлемсери төшеп:
— Сез нәрсәдер әйтергә теләгән идегез, бугай? — диде.
— Әйе, теләгән идем дә...
— Теләнкерәп калдырдыгызмыни?
— Ничә яшьтәге балаларга яраклы бу пальтолар? дип сорарга теләгән идем мин.
Сатучы ханым, пальтоларны төрә-төрә, пырхылдап көлеп җибәрде һәм шаян караш ташлап:
— Сорарга теләгән идегез дә, инде сорамаска булдыгызмы? — дип, Солтанны да көләргә мәҗбүр итте.— Менә болар — ун, унике яшьтәгеләргә, ә монысы — алты, сигез яшьтәгегә. Кызык ата икәнсез.
— Кызык шул. Ярый, хушыгыз. Ялгышмаганмын икән — чак булырлар, — дип, Солтан икенче бүлекләргә китте. Анда, пальтоларның размерына карап, баш һәм аяк киемнәре сайлады.
ТУМнан соң сәгать магазинына кереп Розасы өчен бик матур кул сәгате алды һәм тизрәк өйгә кайтырга ашыкты. Ләкин Куйбышев урамы чатына җиткәч, ашарга онытканын хәтерләде. Борынга тәмле аш исләре бәрелгәндәй булды. «Куелган тәртипне бозмыйм — ашап чыгарга кирәк»,— дип, кире борылды. Һәрвакыт йөри торган ашханәсенә керде. Солянка һәм ростбиф китерергә әйтте, бер шешә сыра сорады. Аш килеп җиткәнче, бүгенге газеталарны карады. Роза белән очрашачагын уйлады. «Правда» газетасында Советлар Союзы Герое исемен алган якын танышы Карезинның исемен күрде.
Абыйсын юксынды. «Хәзер герой булган Карезин белән Әхмәт абзый кайчандыр бергә, бер заводта эшләгән. Әхмәт абзый югалгач, Василий Карезин әнкәйгә

булышкан. Мине энем дип йөргән. Хәзер ул кырыкларда булыр инде. Бөек исем алуы белән котлыйсы иде үзен».

Шул уйлар Василий Карезинның беренче героик вакыйгасына алып киттеләр.

Гражданнар сугышы чоры. Совет халкы, зур корбаннар биреп, илне дошманнан әрчи. Егерме бер яшьлек Карезин тимер юл легионының кыю армеецы. Аның легионы дошман шартлаткан күперләрне, дошман җимереп киткән юлларны төзәтә. Мепә киң елга. Шартлатылган күпер кисәкләре бозлана башлаган суда батып яталар.

Күперне тизрәк торгызу өчен бердәнбер яраклы вариант итеп су астына, тирәнгә төшкән ферманы күтәрү варианты алына. Ләкин ферманы ничек күтәрергә? Бозлана башлаган тирән салкын су астына төшәр өчен бер генә дә водолаз костюмы юк бит.

Бөтен эш хәзерләнеп бетүгә, ике төн йокламаган начальникның карлыккан тавышы ишетелә: «Иптәшләр! Эшнең ни хәлдә торышы — барыгызга да мәгълүм. Су тирән һәм бозлы. Водолаз кисме юк. Арканнар хәзер. Революция эше өчен үзен аямаска, зур намуслы бурычларны башкарырга, су астына төшеп ферманы якорьларга эләктерергә кем риза?» «Мин! Мин!» — ди Василий Карезин.

Бозлы су астына бу көнне ул дүрт тапкыр төшә. Беренче төшүендә Карезин дошман тарафыннан суга ташлангап һәм фермага эләгеп терәлеп калган кеше гәүдәләренә сөрлегә. Икенче тапкыр төшкәч, заданиене үти, ләкин якорь ычкынып китеп, ферма кире төшә. Тик өченче, дүртенче төшүләрендә генә максатка ирешә.

Су астыннан ул дер-дер калтыранып, каз тиресе шикелле, бөрчекләнә башлаган күгәргән тәнле булып чыга. Кызу эш аркасында ике тәүлек йокламаганга, күз кабаклары шешенә башлаган начальник, Карезинның үлем хәлендә булуын башкаларга сиздермәс өчен: «Эшне туктатмаска! Ферманы пыгытырга!» — дип кычкыра, ә куллары белән Василий Карезинның башыннан сыйпый, аның колагына иелә: «Бу эшең өчен халык сине мәңге онытмас, бу эшең өчен легион сиңа рәхмәт белдерә...», — ди.

Батыр комсомолецны, шунда ук беренче ярдәм күр-

сотеп, шәһәр больницасына озаталар. Карезинның кыюлыгы аркасында күпер тиз торгызыла.

Егерме өч сәгать кырык биш минутта күпердән беренче сынау паровозы уза.

Егерме дүрт сәгать тулганда күпер янына беренче эшелон белән Фрунзе иптәш үзе килеп төшә. Ул, халыкны котлап, рәхмәт белдерә, бүләкләр өләшә, больницага барып Карезинның кулын кыса. Аның терелачәгенә ышангач, корыч полководецның күзләре шатлык белән тула.

Шуннан соң яңадан сугыш... яңадан фронт.

Комсомолец Василий Карезин, үзе торгызышкан күпер аша үтеп, дошманны кисә.

Бер елдан соң, Фрунзе иптәшнең үтенече буенча, Карезин Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнүе турында хәбәр ала.

Күпер вакыйгасы турында уйлана-уйлана үзенең ашханәдә утыруын оныткан Солтан алдына солянка китереп куйдылар. Салкын сыра аппетитны яхшы ук ачып җибәрде. Солянка артыннан китерелгән ростбиф та бик тәмләп ашалды. Өченчегә шикәр кебек тәмле карбыз килде.

— Яхшы сыйладыгыз, рәхмәт! — дип Солтан өенә кайтып китте.

Мул итеп ашаган ашларны сендерер өчен җәяү кайтты ул. Кичке кояш нурлары аның юлына яктылык сиптеләр. Яңа гына салынып беткән зур йорт Розаның бүген якланачак проектын искә төшерде.

Шул уйлар белән ул өенә килеп житте. Ишекне ачып керим дигәндә: «Розам бүлмәдә мине көтеп утыра торгандыр», — дип уйлады. Ләкин Роза юк иде.

— Ә, иртә икән. Сәгать дүрт кенә әле, — диде ул сәгатькә карап. — Аңа хәтле бүләкләрне әзерләп куйыйм.

Кәгазь алып өстәл янына утырды һәм түбәндәге хатны язды:

«Кадерле испан иптәшләр!

Без бу хатны сезгә тыныч илдән, гүзәл Советлар Союзыннан язабыз. Һәр көн без сезнең турыда түземсезлек белән хәбәрләр көтәбез. Фашистларга каршы көрәшүегезгә чиксез дәрәҗәдә шатланабыз!

Без, яңа семья тормышын башларга җыенган ике яшь йөрәк, кадерле аналарга һәм энеләребез,

сеңелләребез кебек күргән нәни балаларга бүләкләр җибәрәбез. Без үтенәбез: әгәр дә мөмкин тапсагыз, Бөек Советлар иленә күчеп килүче балаларыгызның берәрсен безнең семьяга атап озатыгыз.

Шанлы әшегезгә уңышлык теләп:
Комсомолка Роза Вахитова,
Комсомолец Солтан Харисов».

«Бу бүләкләр сезгә бездән җылылык илтсеннәр»,— дип уйлап, язуны кичә хәзерләнгән һәм бүген алынган бүләкләр өстенә куйды.

Бераз ял итеп алыйм дип, йомшак диванга утырып, мендәргә башын куйды. Ләкин бу сәгатьләрдә һәр көн ятып йокласа да, бүген йоклый алмады. Дүрт сәгатьлек дәрес, кызыклы очрашулар, төрле бизәктә үткән уйлар һәм, аеруча, алда булачак кадерле сәгатьләр аның көчен арттыралар гына иде. Тик яту җинаять һәм күңелсез кебек тоелды. Күзләр Маяковский томына төштеләр. Ул «Ленин» поэмасын ачты һәм, әсәрнең матур язылышына сокланып, укый-укый берничә урынны ятлап алды.

Алтынчы яртыларда, институтка барышлый, Роза керде. Аның ачык, яңгыравыклы тавышы бүлмәгә яңа матурлык бирде. Солтан диваннан сикереп торды. «Хуш киләсең, кадерлем», — дип, Розаны җылы итеп назлыйсы, иркәләп каршы аласы килде.

— Әйдүк, Розочка! «Халык әдип ул», дип, Тукай бик белеп әйткән. Моннан бик күп еллар элек, билетсыз пассажир булып йөргәндә, пароходта бер җыр ишетеп калган идем. Бүген шул искә төште. Гаҗәп матур җыр, — дип иркәли-иркәли Розаны диванга утыртты.

— Нинди җыр соң ул? — диде Роза.

Кояшта тудың микән,
Йолдызда тордың микән?
Өйдә ай балкый дисәм,
Син иркәм нуры икән, —

дип, Солтан җыр аркылы үзенең куануын белдерде.

Бу матур җырның Солтан тарафыннан нинди мәгънәдә әйтелүен Роза яхшы аңлады. Дүрт юллык шигырь аңа сөйләп бирергә оялган Солтанның зур мәхәббәте турында искиткеч серле нәрсәләр сөйли кебек. Җыр Розага ошады. Авыз эченнән ул аны бер-ике тапкыр кабатлады да. Ләкин, татлы эчке кичерешләрен

Солтанга сиздерүдән тартынып: «Мин җирдә туган, җир өстендә торган кыз. Кояшта тумагач, аңламыйм, күрәсең», — дип сүзне икенчегә борды.

Алар бүләкләр турында сөйләштеләр. Испаниягә язылган хатка Роза кул куйды. «Без яңа семья тормышын башларга җыенган ике яшь йөрәк» сүзләрен каткат укып Солтанга карады. «Розам нәрсә уйлый икән?» дип Солтан үз-үзенә сорау бирде. Ә Роза: «Акыллым син минем!» — дип аз гына кычкырып җибәрмәде.

Бергә кушылу, бергә тора башлау турында алар бер генә мәртәбә дә сөйләшкәннәре юк иде. «Кил, Розочка, бергә тора башлыйк»,— дию әллә ничек шыксыз, ятышсыз булып чыгар иде. Ә Испаниягә язылган хатта, совет халкының йөрәк тойгысын белдергән хатта ул сүзләр гади дә, табигый да һәм шул ук вакытта җитди, бөек тә булып яңгырыйлар иде.

VIII

Розаның проекты турында сөйләшә-сөйләшә институтка киттеләр. Юл кыскара төшкән саен, Розаның борчылуы арта барды. «Тагын ярты сәгатьтән соң ул, халык тулы зал алдына чыгып, дәүләт комиссиясе каршында, профессорлар, белгечләр, студентлар алдында үзенең дипломын яклар. Шунда ул биш ел буена җыйган белемен күрсәтер, иң яхшы инженер исемен даулар. Ләкин инженер исемен алам дигәндә генә, татлы хыяллар, айлар буенча онытылып эшләнгән проект чертёжлары җимерелеп төшмәсме? Төрле сораулар яудырып, «Бу кыз бернәрсә дә белми!» — димәсләрме? Солтан... Солтан ник дәшми бара? Ул да бит залда утырыр, Роза өчен борчылыр. Аның алдында сөйләве кыенрак булмасмы? Кайтарып җибәрәсе иде үзен. Шатлыкны соныннан уртаклашыр идек».

Каләмем минем Розаның уйларын куып җитә алмый.

Кеше! Син нинди катлаулы! Бер минут эчендә син нәрсәләр турында гына уйламыйсың! Бер минутка сузылган уйлануда син кайларда гына булмыйсың, нәрсәләр генә күрмисең!

23 яшьлек Роза тулы бәхеткә ирешер минутлар алдыннан үзенең балачагын хәтерләде. Ул үзенең алты яшьлек чагын күрде. Алты яшьлек Роза, әнкәсенең чабуына тагылып, тәрәзәдән тәрәзәгә күчеп: «Бер кисәк

икмәк бирсәгезче»,— дип соранып йөри, имеш. 23 яшьлек Розага алты яшьлек нәни Роза хәзер бик еракта калган кызганыч бер таныш булып тоела. Ул елларны алты яшьлек Розаның тизрәк үсәсе, зур буласы килде. Өй артында үскән ялгыз ак каенга барып, ул һәр көн диярлек үзенең буен үлчи иде, үзеннән ике-өч бармак югарырак үскән ботакка тизрәк җитәсе килә иде. Соңыннан ак каенны утынга турадылар. Ак каен тургалгач, нәни балаларның дөньясы тагы да ямьсезрәк, күңелсезрәк булып китте.

Әнисе үлгәч, Розаны Мәрдәнша исемле ерак бер кардәше үз янына Арчага алдырды.

Яхшы балта остасы Мәрдәнша абзый, төрле артельләргә кушылып, ел саен берничә яңа өй торгыза иде, ләкин үзе ул бик озак вакыт җир астында, землянкада, яшәвеннән котыла алмады. Тик революция генә аны җир өстенә яктыга, кояшка чыгарды. Эш сөюче Мәрдәнша абзый кечкенә Розаны үз баласыдай назлый, иркәли иде. Бәйрәм көннәрендә конфет, пряник, көнбагыш алып кайта иде.

Солтан белән култыклашып барган Розаның кашлары кинәт җыерылдылар. Аның төсе үзгәрде, йөрәк тибеше кызуланды. Өзек-өзек күренешләр белән бөтен тормышы күз алдына басты. Онытылмас якты бер бәхет булып комсомолга алынуы күренде; элек рабфакта, аннан соң вузда укуы яңа кичерешләр тудырып, секунд тизлегендә алдан үттеләр. Һәм шул вакыт аны, инженер исемен ала торган Розаны, бары тик хыял күзләре генә күрә алырлык ераклыктан алты яшьлек Роза бармак селкеп тирги төсле тоелды: «Мәрдәнша абзый сиңа үсәргә, дөньяга керергә булышты, ә син оныттың, хатлар да язмый башладың үзенә, җәй көне ул сине үз янына көтте, ә син кайтмадың», дисыман. «Юк, юк, онытмадым. Иртәгә үк мин аңа хат язам. Җәй көне Солтан белән кунакка барам», дип, зур Роза кечкенә Роза алдында акланырга тырышты. Шул ук секундта тиздән булачак диплом защитасы аны тагы да пошындырып, дулкынландырып җибәрде.

Ике-өч минут дәшми барган Солтан, Розаның кәефен күтәрергә теләп, матур сүзләр эзләде. Ул Розаның борчылуын сизеп, сулышын тыңлап барды. Бу җаваплы кичне дустының тыныч булуын теләде ул. Ләкин, гадәттә була торганча, фикерләр бер гөлдән икенче

гөлгә сикерделәр. Розаның булачак диплом проекты турында уйлый-уйлый, Солтан Советлар иленең никадәр алга киткәнен хис итте. Элек урта мәктәп күрмәгән, сөйгән егетләренә сәлам хаты да яза алмаган авыл кызлары бүген инженерлар! Нинди генә инженерлар әле! Яңа дөньяны тагы да матуррак, тагы да ямьлерәк итәр өчен проектлар күтәреп киләләр.

Матур сүзләр эзләвен оныткан Солтан:

— Яхшы хәтерлә, — диде Розага, — докладыңны тартынып сөйләмә. Таныш мәсьәләң буенча җавапларны кыю бир. Сүзләрең ачык, фикерең тирән булсын.

Бу сүзләрдән соң Роза тагы да якынрак итеп Солтанга сырышты. Ул үзендә Солтаннан күчкән җылылыкны һәм шул җылылыкка каршы йөрәктә туган тагын бер серле җылылыкны татыды. Сулыш алуы артты, адымнары җиңеләйде.

— Әгәр дә җавап бирә алмасам, анда ничек? — диде Роза, елмая төшеп.

Аның чәч бөртекләре Солтанның колак яфракларын кытыкладылар. Йөзгә ләззәтле хуш ис бәрде. Кочасы, үбәсе килү тойгысы туды. Ләкин бу рәхәт омтылыштан һәр икесе үзләрен тотып калдылар.

Ягымлы хәрәкәткә шундый ук ягымлылык белән җавап бирергә теләп, иреннәрен Розаның сокландыргыч бит алмаларына тигезер-тигезмәс, Солтан дәвам итте:

— Башта уйла, исәплә, — диде, — инде җавап бирә алмыйсың икән, мәгънәсез сүзләр ярдәме белән ерып чыгарга тырышма. «Бу сорауны хәзергә мин аңлап җитмим яки аз аңлыйм, шуңа күрә җавап бирмәвем дөресрәк булыр», — дип туп-туры әйт.

— Бер сүз әйтсәм, ачуланмассыңмы? — диде Роза назлы, ләкин борчылган тавыш белән.

— Нишләп ачуланыйм? Урынлы сүз булса, әйт тә бир...

Бу сүзләр Солтан тарафыннан бик тыныч әйтелсәләр дә, үзе ул тирән уйга чумды.— Нәрсә турында икән?

— Я, мин тыңлыйм, — диде ул.

— Ләкин начарга алма... Мин... мин... синең кайтып китүеңне теләр идем.

— Ни өчен?

— Бу юләрлектер бәлки, теләсәң ничек аңла. Мин синнән оялам. Трибунага чыгып сөйли башлау белән

сине күрсәм, саташырмын, фикерләремне чуалтырмын төсле.

— Бу сүзләрең белән син үзең минем фикерләремне чуалттың. Гомергә бер килә торган шатлыгыңны уртаклашудан аерасың.

— Юк, Солтанчик, аермыйм. Диплом защитасы беткәч тә, мин сиңа, синең бүлмәгә йөгерермен. Ә хәзер... үтенәм, кайт. Син юкта, мин үземне тынычрак тотармын.

Солтан белән Розаның таныш булуларына ике еллап вакыт үтсә дә, бер-берсен алар тәмам аңлап, өйрәнеп җиттек инде дип уйласалар да, менә хәзерге шикелле көтелмәгән яклар ике арада, сирәк булса да, чыга торды. Вакыт-вакыт бу аңлашылмаулар үпкәләшү белән башлана, мәхәббәтнең әйтеп бирә алмаслык иң нечкә назланулары белән бетә иде. Шулай да дөресен әйтергә кирәк: күбрәк Роза үпкәли иде, ә Солтан, үпкәләсә дә, сиздермәскә тырыша иде.

Розаның кайт дип куюына каршы Солтан мең төрле дәлилләр китереп карады. Ләкин ул Розаның җаваплы эшкә, биш ел буенча институтта алган белеменең соңгы нәтиҗәсен гыйльми бәхәс нигезендә дауларга барганын истә тотып, йомшак булырга тырышты. «Кайт, имеш, нинди юләр теләк, урынсыз каприз!» — дип уйласа да, каты сүз әйтмәде. Тик институтка җитәр алдыннан гына, үпкәләгәнсыман:

— Ярар алайса, бар... Мин сине кө-тәр-мен... — диде.

— Кара аны, ачуланма! — диде дә Роза, һич көтмәгән җирдән, Солтанны үбеп алды һәм, башы әйләнде булса кирәк, узган-барганнарга бәрелә-сугыла, йөгерә-йөгерә институтка кереп китте.

Бу хәлгә Солтан елмайды да, гаҗәпләнде дә.

— Бәхет... бәхет телим үзеңә! — диде ул Роза киткән якка.

IX

— Ә, Солтан Харисович... исәнмесез! Нишләп болай тирән уйга чумып урам чатында басып торасыз? Мировая проблеманың койрыгыннан тоттыгызмы әллә? — дип берәү Солтанга кул сузды.

Бу — шәһәр советының мәгариф секциясендә Солтан белән бергә эшләгән профессор Евгений Алексеевич Долгов иде.

Эшлекле тәкъдимнәре белән секциядә үзен яхшы белгеч методист-педагог итеп таныта алган профессор Долговка Солтан тиз ияләште. Аның җылы юморы, иң җитди әйберләрне дә гап-гади сүзләр белән җиңел аңлатуы, тыныч табигате Солтанга нык тәэсир иттеләр.

— Ә, бик шатмын!—диде Солтан, аның кулын кысып.

— Нәрсәгә бик шатсыз?

Бу сүзләрне Евгений Алексеевич елмаеп, күзлек астыннан күренгән хәйләле соргылт күзләрен уйнатып әйтте-һәм, аптырашта калган Солтанны култыклап, институтка таба алып та китте.

— Әйе, нәрсәгә бик шатсыз?

— Нәрсәгә булсын, сезнең белән очрашуга, әлбәттә,— диде Солтан. Ә үзе: «Розаның үбеп китүен күрмәгән булса ярар иде»,— дип уйлады.

— Алай бик шат булсагыз, мин сезне институтка алып керәм. Ярыймы?

— Мөмкин түгел, вакытым юк, Евгений Алексеевич.

— Мировая проблеманы тота алмадыгыз, ычкындырдыгыз; театрга барырга иртә; киногa дисәгез, ун сәгатьтәге сеанска да өлгерәсез. Димәк, кердек. Свиданиегез юктыр бит?

— Бар иде шул.

— Институт янындамы? Мәсьәләне институт дирекциясе алдына куярга туры килер: штрафсыз котыла алмассыз. Әйдәгез, Солтан Харисович, кердек.

— Ярамый, кушмады.

— Кем?

— Ул.

— Кара син аны, нинди «зур трагедия»: ул кушмады, имеш. Иртә командовать итә башлаган. Инде карт кешенең киңәшен тыңлагыз: кушмагач, бигрәк тә керергә кирәк. Беренче айларда кызлар киресен эшләгәнне яраталар. Сез тартынып тормагыз — мин бернәрсә дә күрмәдем.

Солтан уңайсызланып башын иде.

— Һе, бала,— диде Евгений Алексеевич,— мәхәббәттән оялалармыни!.. Акыллы кыз ул. Бүген аның защитасы. Әйдәгез, кердек.

— Сүзендә тормады, дияр.

— Сезне мин аңа күрсәтмәм. Читтән генә карап торырсыз. Күрә калса, шатланыр гына,— дип, профессор Долгов Солтанны институтка кертте.

Ишектән кергәндә, Солтан алтын хәрефләр белән русча-татарча язылып стенага беркетелгән пыяладагы язуны укыды:

М. Горький исемендәге
Казан Коммуналь төзелеш
инженерлары институты.

Солтанның монда килүе беренче тапкыр гына түгел. Роза белән бергә төрле кичәләргә килгәне бар. Ул үзе монда укымаса да, бу матур бинаның байтак кабинет, аудиторияләре, бай лабораторияләре белән яхшы таныш иде.

Ишекне ачуга, алар төрле сыннар, гөлләр һәм рәсемнәр белән ярапып бизәлгән зур, озын вестибюльгә керделәр. Ал, зәңгәр, күк, сары төстәге шакмаклы пыялалардан эшләнгән тәрәзәләрдән төшкән кичке яктылык күзләргә матурлык биреп тора.

Профессор хәрәкәтләренә буйсынып, Солтан, ыгы-зыгы килеп йөргән студентларга карый-карый, укытучылар элгеченә узды, пальтосын һәм эшләпәсен салды. Аннан деканат бүлмәсенә үттеләр.

Дәүләт комиссиясенең кайбер членнары килеп җитмәгәнгә күрә, защита башланмаган иде әле. Шунлыктан деканатның гөлләр белән бизәлгән, зур кәнәфиләр, йомшак креслолар белән җиһазланган бүлмәсе гыйльми эшчеләр белән тулы иде. Профессор Долгов аларның бөтенесе белән дә Солтанны таныштырып чыкты. Монда Солтан Роза мактап сөйләгән берничә атаклы профессорны күрде.

Солтаннар килеп кергәндә, сүз бүген бетереп чыгучы студентлар турында бара иде.

— Бүген өч-дүрт сәгатьтән дә артык утырырга туры килмәс,— диде профессор Полушин.

— Ник?—дип арадан берәү сорау бирде.

— Бүген биш дипломникның дүртесе — отличниклар: алар вакытны күп алмаслар.

— Беренче булып кем чыга, белмисезме?

Бу сорауны, беренче булып кем чыкканын үзе яхшы белсә дә, профессор Долгов бирде. Моның белән ул Солтан өчен якын тоелган исемнең профессорлар телендә яңгыравын, яратып әйтелүен теләде.

— Беренче булып Роза Вахитова чыга, — диде укыту бүлеге мөдире доктор Хәкимҗанов,— ә аның артыннан Дудуев. Икәве дә отличниклар.

Профессор Долгов сары сакалын сыпыра-сыпыра, ишетәсенме дигәндәй, Солтанга карады. Дусты, иптәше, йөрәк сердәше турында шундый җылы характеристика ишетүгә, Солтан куанды. Ләкин, аның үзен мактыйлар кебек хис иткәнгә, уңайсызланып кызарып утырды.

Инженерный конструкцияләр профессоры Васильев Роза Вахитованың әзер формулалар белән генә фикер итмичә, «Ник?», «Ни өчен?» сорауларына үзе җавап табарга тырышуына, мәсьәләнең нигезен, тамырын белергә көч куюына тукталды.

— Вахитовада хыял һәм кыюлык бай. Аның проектларын күргән иптәшләр бүген гаҗәпкә калачаклар,— диде яшь, ачык чырайлы архитектор Гыйльметдинов.

Солтан сокланып архитекторның йөзенә карады: киң маңгай, зур зәңгәр күзләр, ниндидер бер романтикалы, алга омтылышлы караш. Әле күптән түгел генә Солтан СССР Фәннәр академиясе конкурсында бу яшь архитекторның проектлары икенче урынны алганны ишеткән иде.

«Элек рәсем ясаудан курыккан татар халкы бүген үзенең рәссамнарын, архитекторларын үстерә».

Солтанның бу уйлары Гыйльметдиновның ике җөмлә арасында тын алу өчен бер секундка тукталган вакытында булды.

— Минемчә, — диде Гыйльметдинов дәвам итеп, — Вахитова иптәшне институтта аспирантурага калдырырга кирәк.

Бетереп чыгучы студентлар турында сөйләшкәннән соң, сүз ара сүз чыгып, иске мәктәпкә күчтеләр. Истәлекләр сөйләнде. Карт профессорлардан берәү, үзенең студент чагын хәтерләп, укырга керә алмыйча озак вакыт җәфаланып йөрүен телгә алды. Лекцияләр тыңлаган өчен акча түләргә кирәклекне, җәй көне пристаньда грузчик булып эшләвен, кыш көне үзе уку белән бергә, өйдән өйгә йөреп балалар укытуын аңлатты.

— Уйлана башласаң, хәйран каласың,—диде ул сүз ахырында,— нәфис бүлмәләр, зур-зур тораклар корып, йөзәр, йөз иллешәр, икешәр йөз сум стипендия түләп кайда, нинди илдә студентларны укыталар. СССР дан

башка андый ил юк ул. Элекке елларны, революциягә хәтле, күрше бинада — промышленное училищеда укыта идем мин... Ул елларны безгә халык улы — Киров та килеп укыды. Миңа анын, үзе яраткан укытучыларга килеп, оялчан кадерле кунак булуын күрергә туры килгәләде. Ә хәзер нәрсә? Чагыштыруы да урынсыз: Зәйнуллин дигән отличникны беләсездер, шул быел вестибюльдә үземне туктатты да, ояла-ояла гына: «Бер үтенечем бар, Павел Иванович, кире какмасагыз, әйтәм»,— ди. «Әйтегез, әйтегез, нәрсә?» — дим. «Кире какмассызмы соң?» — ди. «Мөмкин икән — юк, какмам»,— дим. «Тулай торакта бер бүлмәдә торучы иптәшләр исеменнән мин сезне иртәгә кич алтыда, үзебезгә студентлар чәенә, кунакка чакырам,— ди һәм бераз елмаеп,— студент чәе дигәч тә, курыкмагыз, ярлы булмас»,— ди. Күрдегезме ничек?— дип профессор сүзен бетерде һәм трубкасын алып тәмәке төя башлады.

Иске мәктәптәге тәртипкә бәйләп, профессор Долгов түбәндәге «ачкыч вакыйгасын» сөйләде.

— Безнең иң күралмаган профессорыбыз — Богоявленский иде. Ул үзе укыта торган фәне буенча бер генә дә яңа оригиналь фикер әйтә алмый иде. Лекцияләргә йөрү мәҗбүри булмаганга күрә, анын дәресләрен тыңлаудан без баш тарттык. Шуннан соң профессорыбызның борыны салынып төште. Революцион омтылышны кысучы кара йөрәк төрле чаралар күрә башлады. Гаризалар язып җәнжал чыгарды. Безнең курс студентларын, деканатка чакырып, берәм-берәм үгетләргә тотындылар. Безгә анда: «Профессор Богоявленский патша хәзрәтләренә жаны-тәне белән бирелгән кеше, министрның якын дусты, анын дәресләренә йөрмәү — бунт ясау була ул. Университетны яптырырга яки үзегез яраткан профессорларны һәм байтак кына студентларны университеттан чыгартырга теләмәсәгез, Богоявленский дәресләренә йөрегез»,— диделәр. Кара реакция еллары иде. Эшне тирәнгә жибәрергә курыктык. Үзара киңәшкәннән соң, без Богоявленский дәресләренә чиратлашып йөрергә булдык.

Ул елларны эчке тәртип буенча аудиториядә бер генә студент утырса да, профессор лекция укырга тиеш иде. Богоявленский дәресләре дә шулай, айга якын бер кешегә уку белән үтте. Мин дә үземнең чиратымны уздыр-

дым. Лəкин бервакытны көтелмəгəн хəл килеп чыкты. Чират буенча лекция тыңларга килергə тиеш булган студент сырхаулап килми калган. Ə шул көнне дүртенче курс студентларыннан гаҗəп кыю берəү, иртə белəн зачет хəзерлəргə бүлмə эзлəп йөри-йөри, Богоявленский аудиториясенə элəккəн. Швейцар Порфирий аңар ачкыч биреп, «Мə, киткəндə биклəрсең, ачкычны үземə тапшырырсың»,— дигəн. Бер-ике сəгать чамасы дəрес хəзерлəп утырганнан соң, əлеге студент янына Богоявленский килеп керə һəм «Милостивый господин, үткəн лекциядə без фəлəн җирдə туктаган идек», дип лекциясен укырга тотына. Студент аптырап кала. Нишлəргə? Бүлдерергə ярамый. Ташлап чыгып китү дə уңайсыз. «Бер туктар əле», дип, студент, профессорга игътибар итмичə, үз эше белəн шөгыльлəнергə керешə. Лəкин Богоявленскийның башта кызык тоелган чəрелдəвек эче тавышы озакламый эчне пошыра башлый. «Бу саташканны нигə тыңлыйм соң мин?» — ди дə студент урыныннан кузгала. Һəм Богоявленский аркасында университеттан чыгарылган иптəшлəре өчен нəфрəт белдерергə телəп: «Профессор əфəнде, сез озакмы тагын сөйлəрсез?» — ди. «Аңламыйм, мондый урынсыз сорауның нигə кирəге бар? — ди гаҗəплəнгəн Богоявленский.— Минем бик мөһим фикерлəр əйтəсем бар əле». «Ə минем китəсем бар. Менə ачкыч, мөһим фикерлəрегезне əйтеп бетергəч, аудиторияне биклəп чыгарсыз»,— ди дə студент демонстратив рəвештə чыгып китə.

Евгений Алексеевич сөйлəп бетерүгə, звонок шалтырады. Халык залга таба агылды.

— Ə теге кыю студентка бернəрсə дə булмадымы?

— Студентка гына түгел, швейцарга да элəккəндер əле. Шулай түгелме? — дип «ачкыч вакыйгасы» белəн кызыксынган кешелəр профессор Долговка сораулар биреп бардылар.

— Анысын икенче вакытта сөйлəрмен,— дип, Евгений Алексеевич залга кермичə, Солтанны җитəклəп, өченче катка менеп китте. Озын коридор һəм караңгы бүлмə аша үтеп, алар ложасыман ясалган балконга керделəр.

— Менə монда тыныч булыр. Монда «ул» сезне күрмəс, — диде Долгов Солтанның колагына.

X

Балконның алгы рәтенә утырган студентлар урыннарыннан торып профессорга һәм аның иптәшенә үзләренең урындыкларын тәкъдим иттеләр. Профессорның шаян телле кеше икәнен якынтын белеп алган карт чырайлы бер студент:

— Яшьлегегез искә төштеме әллә, Евгений Алексеевич, галеркага мендегез,— диде.— Сезгә бит түбәндә иң алгы креслолар хәзерләнгән.

— Сезгә дә анда урын бар. Мине карт дияргә сез үзегез дә бик яшьтән түгелсез. Чәчегезне энҗе бөртекләре каплаган: математика җимешеме әллә? — дип профессор көлеп җавап кайтарды һәм:— Сез теләсә нәрсә уйлагыз, ә мин бүген галеркага качкан студентлар белән элемтә тотарга булдым, — дип өстәде.

Солтанның күзләре залда иде. Беренче секундта ул зур, якты, биек залның төрле рәсемнәр, сыннар белән матур итеп бизәлүенә сокланды. Икенче секундта аның күзләре сәхнәдәге щитларга беркетелгән таныш чертежларга төштеләр. Бу чертежлар Роза тарафыннан ватман, калька кәгазьләренә эшләнгән проектлар һәм планнар иде.

Сәхнә алдында бераз һулдарак комач хәтфә җәймә җәелгән, чәчәкләр белән бизәлгән озын өстәл артында комиссия членнары утыралар. Күкрәгендә Кызыл Байрак ордены ялтыраган председатель звонок биреп тынлык сорый һәм:

— Дәүләт квалификация комиссиясенең сессиясе дәвам итә. Бүгенге утырышта беренче мәсьәлә итеп, М. Горький исемендәге Казан Коммуналь төзелеш инженерлары институтын бетереп чыгучы Роза Вахитова иптәшнең диплом эше карала, — ди.

Комиссия члены доктор Хәкимҗанов Розаның туган елын, чыгышын, комсомол члены булуын, институтка кайчан һәм нинди мәктәп бетереп керүен, институтта ничек укуын, нинди җәмәгать эшләренә катнашуын сөйли.

Солтан алдыннан тагын бер тапкыр Розаның бөтен тормышы уза.

Шуннан соң сүз диплом эшен яклау өчен Розаның үзенә бирелә. Солтан аның җиңелчә, матур адымнар белән чыгып трибунага басуын күрә.

— Иптәшләр! Минем проектымның темасы — «Казан шәһәре өчен Зур Идел янында су вокзалы салу», — дип Роза сөйли башлый.

Профессор Долгов шатлыклы елмаю белән Солтанга иелә һәм колакка:

— Карагыз, йөрәгегез сикереп чыкмасын! — ди.

Солтанның йөрәге, чынлап та, сикереп чыгарлык иде. Йөрәк тибеше кызуланган кебек, уйлар да куердылар. Әле күптән түгел генә Роза аның бүлмәсенә килеп:

— Син рус теле укытучысы: хаталары юкмы, кара әле,— дип проектка карата язылган аңлатма язуын — язма защитасын күрсәткән иде. Хаталар юклыгын Солтан да, Роза үзе дә яхшы белә иде. Бу — ике яшь дусның бер-берсенең эше белән таныш булырга теләү йөзеннән генә шулай әйтелгән иде.

Ул кичне алар бик озак серләштеләр.

Проекттагы терминнарны, формулаларны тиешенчә аңлап җиткермәгәнгә күрә, Солтан башта авырсынып утырды. Ләкин ярты сәгать вакыт үткәннән соң ул тәмам онытылды. Розаның никадәр зур эшне башкарып чыкканын күрде. Шунда ук ул проектның отличнога эшләнгәненә ышанды. Гигант пароход стилендә ясалган су вокзалын үз күзе белән Казанда күргәндәй булды.

Роза сөйли башлаган минутларны Солтан әнә шуларны уйлады. Роза белән беренче тапкыр танышуын хәтерләде. Бөтенесе дә күз алдында кебек.

Шатлыклы Беренче Май. Яз киемнәренә киенгән урамнар буйлап халык диңгезе агыла. Ал байраклар җилферди. Җырлар яңгырый.

Демонстрациядә алдан баруны даулап Галактионов урамында Педагогия институты белән Коммуналь төзелеш инженерлары институты колонналары очрашалар. Һәр ике якның студентлары беренчелекне үзләренә алырга телиләр. Мәсьәләне хәл кылыр өчен колонна башлыклары район башлыгы янына китәләр. Шул вакыт алдынгы сафлар кузгала. Педагогия институтының байрагын күтәргән Солтан:

— Байрак артыннан калмагыз! — дип үзенең колоннасына кычкыра һәм алга ыргыла.

Төзелеш инженерлары институты колоннасындагы иң алгы рәткә баскан отличниклар башлыгы Роза Солтанны туктата:

— Кая сикерәсез? Тәртипне бозмагыз! Сез безнең арттан,— ди һәм үзе алга чыгарга омтыла.

— Гафу итегез, иптәш «командир», алдан барып өчен сезнең институтка тырышлык күрсәтәсе бар әле. Чигенегез! — ди Солтан, көлеп.

Шуннан алар бераз әрләшеп алдылар.

— Күзләрегез матур булсалар да, мәгънәсез талашуыгыз белән Беренче Майның ямен бозасыз. Алдынгы колоннаның башында торуымнан файдаланып, мин сезгә кайтып китәргә кушам,— ди Солтан.

Розаның кәефе китә.

— Тагын нинди «акыллы» сүзләрегез бар икән. Яныгызда басып торып тыңлыйсым килә,— ди ул.

— Миңа гашыйк булуыгызны аңлавым өчен гафу үтенәм. Элекке эмеремне кире алам: кайтып китмәгез, янымда басып торыгыз,— ди Солтан, ул колонналар туктаган арада Розаны култыкларга тели.

— Нахал! — дип, Роза аны этеп җибәрә.

Ләкин этеп җибәрүе — җиңелчә шаяру, «нахал» дию — «исемең ничек?» дип сорау бирү шикелле генә чыга.

Татар театры янына җиткәч, колонналар яңадан бергә тукталдылар. Төзелеш, инженерлары институты сафларында оркестр янгырады. Тротуарларда һәм урам уртасында бөҗра-бөҗра биюләр башланды. Автомашиналарга куелган брусларда төрле физкультура үрнәкләрен күрсәтү, баш әйләндергеч фигуралар ясау, «Динамо» стадионы каршында һавага чөюләр китте. Солтан белән Роза шунда тагын бергә туры килделәр. Бер төркем студентлар, аларны урап алып:

— Егетләр, ике вуз арасында совет туганлыгының элемтәсе булсын! — дип аларны һавага чөйделәр.

Бу кичне Солтан өйгә ниндидер бик мөһим әйберне югалткан кеше кыяфәтендә кайтты. Икенче көнне ул Культура паркына маевкага барды. Анда Розаны күрде.

Шуннан көн саен киңәя, зурая барган тирән тойгы башланды.

Калын китапка кирәрлек вакыйгаларны ике-өч минут эчендә күз алдыннан кичергән Солтан яңадан сәхнәгә карады.

— Шәп, шәп! — диде бинокль тоткан профессор Долгов. Ул Роза проектындагы вокзалның фасадына сок-

ланды: — маяк булып күккә күтәрелгән Ленин фигурасы, факел тоткан сыннар, яшел зона, фонтаннар — бөтенесе дә оста эшләнгән.

Һичшиксез, бу гүзәл вокзал Роза проектында гына калмас, тормышка да ашырылыр. Матур залларда утырып пароход көткән пассажирлар ул вакыт Розаны җылы итеп искә алырлар.

Роза үзенең математик расчетларын сөйли башлаганда, Солтан үзен булачак вокзалның киң вестибюлендә, Иделгә карап торган хәлдә хис итте.

Покрытие, балка, тимер-бетон расчетларын аңлатканнан соң, Роза эшнең оештыру проектын сөйләүгә күчте. Күпме ком, ничә мең кирпеч кирәк булачак, ничә йөз эшче эшне башкарачак, яр буе ничек ныгытылачак, нинди растворлар алыначак — барысын да сөйләде.

— Инженер исеме бик җиңел генә алынмый икән: никадәр җитди эш, никадәр белем! — диде Солтан авыз эченнән.

Роза сөйләп бетерүгә, бер минутлык тынлык урнашты. Бу бер минут Солтанга сәгать булып тоелды. Бер-бер артлы бирелә башлаган сорауларга хәтле нәрсәләр генә уйламады ул! Профессорларның, белгечләрнең, комиссия председателенең йөзенә, залдагы хәрәкәткә карап защитаның ничек тәэсир итүен белергә тырышты. Янында утырган студентларның пышылдап сөйләшүләрен аңларга теләде.

— Ә кыш көне бу вокзал ни хәлдә булачак? — диде калын тавышлы берәү.

— Кыш көне су вокзалын спорт өчен файдаланырга мөмкин,— дип, Роза яңадан сөйләп китте.

Вентиляциягә, ягу системасына карата һәм тагын шуның шикелле берничә сорау бирелде.

Тулы җаваплар алынганнан соң, рецензентлар, кафедра җитәкчеләре торып сөйли башладылар. Роза проектына алар югары бәя бирделәр һәм «Вахитова иптәшкә беренче дәрәҗә инженер исемен бирергә мөмкин» дип нәтиҗә чыгардылар.

Солтан утырган урыныннан торып китәргә, Роза янына тизрәк очарга ашыкты. Ул инде Долговның: «Котлыйм, котлыйм»,— дип сөйләвен дә рәтләп ишетми. Залга йөгерә. Анда Дудуевның защитасы башлана.

XI

Солтан, Розаны эзли-эзли, зал янәшәсендәге бүлмәгә килеп керә. Студентлар тарафыннан камалып алынган Роза озак вакыт аны күрми тора, ә күреп алгач, йөгереп килеп:

— Бетте бит, Солтан, шундый рәхәт хәзер, юкка гына сине кайтарып җибәргәнмен,— дип йөрәккә үткән җылылык белән Солтанның кулларын кыса.

— Матур сөйләдең, Розочка, котлыйм. Бер генә сорауны да җавапсыз калдырмадың.

— Бу хәтле мәгълүматны сиңа кем сөйләде?

— Ачуланмасаң, әйтәм.

— Нинди ачу ди хәзер...

— Берәү дә сөйләмәде, балконга менеп үзем тыңлап утырдым.

Бу җавап Розага күптән күрмәгән ананың назлавы, йомшак сүзе булып тоелды.

— Бу эшең өчен нишләтергә белермен мин сине. Усал! — диде дә акрын тавыш белән: — Әп итәрмен,— дип өстәде.

Тагын бер-ике сәгатькә алар институтта калдылар. Башка студентларның да защиталарын тыңладылар. Роза да, Солтан да, залдагы халык та Дәүләт квалификация комиссиясенең карарын түземсезлек белән көттеләр. Розаның «защитам бетте» дип шатлануы — пошыну, борчылу белән алмашынды. Бөтенесе дә «отличнога» дип торганда, «уд» кына дип карар чыгарылса...

Роза белән беррәттән, комиссиянең карарын көтеп, Солтан да борчылды. Ләкин ул тыштан мөмкин кадәр тынычрак булырга тырышып:

— Юкка пошынасың, Розочка, комиссиядә тере кешеләр утыра бит... Защитаның ничек үткәнен бик яхшы беләләр алар.

— Мин әнә теге доцент Ибраһим Вафиннан куркам... Доктор Уфанов та бераз борчу сала. Икесе дә бик галимнәр. Вафинның соравына да канәгатьләнерлек җавап бирмәдем.

— Балка турындамы?

— Әйе.

— Җавабың бик шәп иде.

— Юк, Солтан, сиңа гына шулай тоела. Формуланы

бутадым мин. Ә Вафин «минем сорауларым бетте» дип елмайды да Уфановка карады.

— Шулаймыни... мин аңламый калганмын алайса.

Солтанның бу сүзләре борчылуны куәтләде генә. Ул үзенең хатасын төзәтергә теләп:

— Формулалар өчен справочниклар бар ич,— диде.

Кечкенә генә тәнәфестән соң Дәүләт квалификация комиссиясе үзенең карарын укыды. Биш студентның өчесенә (шулар арасында Розага да) беренче дәрәҗә инженер исеме бирелеп, диплом эшләре отличнога үтәлгән дип табылды.

Бу минутта ике яшь йөрәк бергә типте. Солтан Розаны беләгеннән кысып котлады. Чиксез шатлыкка бит алмалары уттай янган Роза комиссия председателенә, комиссия членнарына һәм шунда булган профессор-укытучыларга рәхмәтләр әйтте.

Институттан чыккач, туп-туры телеграфка киттеләр. Институтны тәмамлау турында Мәрдәнша абзыйга телеграмма суктылар. Кем белә, бу телеграмма Мәрдәнша абзыйның үз гомерендә алган беренче телеграммасы булгандыр бәлки.

Телеграфтан Солтан бүлмәсенә кайттылар.

XII

Туачак яңа семьяның таңын алар бүген бергә каршыларга теләделәр. Солтан: «Кал, кадерлем, кунарга кал!» — димәсә дә, Роза калырга хәзер иде. Ләкин үзара булган ихтирам һәм тирән мәхәббәт сүзсез иде. Үткән кичләрдәге кебек, бу кичне дә мәхәббәт үзенең сафлыгын саклады. Солтан: «Кал, иркәм!» — димәде, Роза «Калам, сөеклем»,— димәде. Ләкин һәр икесенең күңелендә шул калу теләге иде.

Мәхәббәт утында гөрләп янарга торган тәнне татлы ялкыннан коткарыр өчен Роза торып киенә башлады. «Ашыгасың, сөеклем, тагын бераз утырыр идең»,— диярга җыенган Солтан аеруча бер игътибар белән Розага киенергә булышты.

Чыгарга дип бүлмәдә утлар сүндерелде. Электрик утларын тәрәзә аша төшкән ай яктысы алмаштырды. Аның зәңгәрсу утлары ишек төбендә басып торган ике яшь йөрәкнең битләрен сыйпады.

...Мәхәббәт! Син нинди көчле. Син вакыт исәбен

белмисең. Менә ярты сәгать инде Солтан белән Роза чыгып китәргә хәзерләнүләрен онытып синең кочагыңда торалар.

...Син очсыз-кырыйсыз, син чиксез, мәхәббәт! Шекспир да сине җырлап бетерә алмады. Синең турыда меңләгән җырлар җырлаган Пушкин да синең соңгы чикләренә барып житә алмады. Толстойлар, Мопассаннар, Ролланнар сиңа том-том әсәрләр багышладылар— син анда да сыймадың. Бөек Горький сине үлемнән дә көчле, үлемне дә җиңә ала торган тойгы дип атады.

...Син хаксызлыкны, ялганны дошман күрәсең. Андый илләрдә син нәфрәткә әйләнәсең.

...Тик безнең илдә генә син кадерле. Тик безнең илдә генә йөрәкләр ачык.

...Әнә Солтанга кара. Кадерле Розасын гына түгел, ул сине дә, мәхәббәт, үзенең күкрәгендә илтә. Ул синнән аерылырга теләми. Ул сине үзенең йөрәгенә үзе үлгәнче чыгармаслык итеп урнаштырган.

...Ә Роза... матур Роза... менә бер сәгать инде ул, үзен озата килгән Солтаннан аерыла алмыйча, урам буйлап йөри. Син аны, мәхәббәт, сөю тойгылары белән исерткәнсең. Син аларның икәвен дә назлап шаяртасың.

...Солтан Розаны озата, Роза Солтанны озата... Берберсен озатып тик йөриләр алар...

— Яраткан кешең белән бергә булу — никадәр бәхет! — ди Роза һәм унынчымы, унберенчеме тапкыр почмакка чаклы Солтанны озата китә.

Алар яшел канат җәйгән юкә агачлары күләгәсеннән үтәләр. Кичке йомшак җил аяк астына гөлләр сибә. Югарыда, качыш уены уйнагандай, бер-бер артлы болытлар йөзәләр. Болытлар астыннан җем-җем итеп йолдызлар чыгалар.

— Үзең теләгән кешене сөяргә чиксез ирек ачкан илдә сөю һәм сөелү — зур бәхет! — ди Солтан һәм: — Ялгызыңны җибәрмим,—дип яңадан Розаны озата китә.

Ике яшь йөрәк бер-берсен озатышып озак йөрделәр. Хәер, саубуллашкач та алар бер-берсе турында татлы уйлар уйлап «бергә» булдылар.

XIII

Сәгать 11 ләр тирәсендә Солтан бүлмәсендә яңадан утлар кабынды. Бүлмәгә кереп чишенү белән, ул әрлебирле йөрергә керешге. «Менә шунда Роза утырып

торды. Менә биредә бүләкләрне карады. Әнә тегендә матур итеп елмайды»,—дип Роза турында уйлады.

Бу бәхетле тормышка, бу гүзәл шат тойгыларгаирешүен белергә теләп, ул өстәл янына утырды. Күзләре әнисе рәсеменә төштеләр.

— Әни!.. Үләр минутыңда син минем өчен газап чиктең. «Ялгыз нишләрсең, бәбкәм»,—дип актык күз яшеңне минем өчен түктең. Мин ялгыз түгел, әни. Мин бик бәхетле хәзер. Әгәр исән булсаң, күрер идең, әни... Без сине шундый кадерләр идек, син шундый рәхәттә яшәр идең, әни...

Бу вакыт өстәлдә әле күптән түгел генә Роза белән бергә укылган «Миңа егерме яшь» дигән китап ята иде. Ул кадерле бернәрсәгә тотынган хис белән китапны кулына алды. «Белланже» дип әсәрнең авторын укыды. Белланже аның өчен бер язучы гына түгел, ул чит илдә җәфа чигүче иптәш тә. Китапны укып чыккан көнне үк Солтан аңарга хат язарга булган иде. Әлегәчә язмый торуына үзен тирги-тирги, хәзер язарга кирәк дигән фикергә килде. Яңадан бер кат китапның эчтәлегән хәтерләде, һәм, кирәк булыр әле дип, русча-французча сүзлек алып, хат язарга тотынды.

Бу хат түбәндәгечә булып чыкты:

«Кадерле Белланже!

Бу хатны мин Сезгә Советлар Татарстаныннан язам. Миңа шушы арада сезнең французчадан русчага тәрҗемә ителгән «Миңа егерме яшь» дигән китабыгызны укып чыгарга туры килде. Берничә сәгатькә сез мине рәхәт тормышымнан аерып, Париж буйлап йөрттегез, капитализм тырнагы астында калган яшь егетнең уйлары, хисләре белән таныштырдыгыз. Мин сезнең эш тапмыйча газап чигүегезне, сезнең коточкыч караңгы тормышыгызны күрдем. Никадәр хаксызлык, Белланже дус!

«Миңа егерме яшь,—дисез сез,—ләкин миндә миңа бәхетсезлек китерә торган тормышка нәфрәт туды». Сез өметсезлекнең иң соңгы чигенә җиткәнсез. Газлы бомбалар күтәреп килгән дөнья сугышы һәм аны башлап җибәрергә теләүче министрлар сезне аптырашта калдырганнар.

«Миңа егерме яшь, ә мин тормыштан туйдым»,— дисез. Мин дә яшь. Ләкин минем тормышым бөтенләй

башка. Мин чын ирекнең нәрсә икәнен үзем татып беләм. Мин халкыбызның рәхәт яшәвен күрәм.

Мин югары белемле укытучы. Урта мәктәптә рус теле һәм әдәбият укытам. Хезмәтем миңа әйтеп бетергесез шатлык китерә. Эшсез калу уема да керми минем. Мин Казан шәһәр советы члены. Ну, шәһәрдә бөек Ленин, Киров иптәшләр укыганнар. Монда Толстой, Лобачевский, Горький яшәгән. Шул шәһәрдә татар шагыйре Тукай коточкыч заманда халыкның аһ-зарын җырлаган, караңгы тормышта яшәгән хезмәт ияләренә йөрәктән чыккан шигырь яктылыгын биргән.

Мин бик еш хөкүмәт утырышларында булам. Халкыбызның мөһим заданиеләрен үтим. Комсомолда агитатор булып эшлим. Ә үткәнем минем — фаҗигале әкият. Әтиемне минем патша строе асып үтергән. Абыемны минем шул ук строй сугышка озатып югалткан. Әнием ачлыктан үлгән.

Яңа кешелек дөньясын тудырган Бөек Октябрь мине, урам чатыннан алып, җылы өйгә, яңа тормыш кочагына кертте.

1917 нче елга хәтле татарлар арасында бер генә дә профессор, архитектор юк иде. Ленин партиясе татар халкына көч бирде. Шул халыкның яшьләре бүген сезнең илнең Ромэн Ролланы, Стендале, Барбюсы, Анатоль Франсы кебек язучылар белән таныша. Шул халыкның бер улы бүген сезгә француз телендә хат яза.

Буржуа илендә хурланмыйча, тәлинкә тотмыйча, уңышлык казанып булмый, ди Стендаль. Безнең Советлар илендә исә, һәрбер намуслы хезмәт кешегә дан китерә, казаныш бирә.

Сез: «Мин аллага ышанмыйм. Мин аңардан яхшылык көттем, ә ул миңа явызлык бирде. Мин семьяга ышанмыйм. Аннан минем янбашларым сызлый»,—дисез.

Мин дә аллага ышанмыйм. Ләкин мин ямьле Совет иленә, аның көчле халкына ышанам. Без, совет яшьләре, үзебезнең көчебезгә ышанабыз. Чөнки без бөек хокукларга ия булганыбызны беләбез. Шулай булгач, ничек яратмыйм ди мин үземнең ватанымны! Яратам, яшисе килеп яратам! СССР халкы кара көчне җиңде һәм җиңә. Шулай булгач, ничек ышанмыйм ди мин җир йөзенең хезмәт халкына! Ышанам, Белланже! Сез дә ышаныгыз.

«Вакыт-вакыт мин мәхәббәт турында уйлыйм. Моннан берничә ел элек минем яраткан кызым — брошюровщица Люсьенам бар иде. Һәр көн мин ул эшли торган җиргә — аның янына бара идем. Кинәт эшсезлек килде. Кечкенә Люсьенам янына артык бармадым», — дисез.

Минем дә сөйгән кызым, акыллы Розам бар. Бүген ул институтны бетереп инженер булды. Бер-беребезне бик яратабыз без. Театрларда, киноларда, концертларда булабыз. Бергә китаплар укыйбыз. Сезнең китапны да бергә укып чыктык. Ул да, минем кебек үк, комсомол члены. Киләчәк безне куркытмый. Бүгенге көнебез матур, ямьле. Ә киләчәк тагы да ямьлерәк булачак. Партиябез безне кыюлыкка, намуслы хезмәткә өйрәтә. Без вузда алган белем белән генә калырга теләмибез. Без һәр көн үз өстебездә эшлибез.

Белланже дус!

Сөекле башкалабызның Кремль сәгате уникене суга. Халыкларыбызның йөрәк тойгысын билгеләп, ирек һәм җиңү гимны — Интернационал яңгырый.

Сау булыгыз! Хатым Сезгә барып җитсә, иптәшләрегезгә бәхетле совет яшьләреннән сәлам җиткерегез».

Хатны язып бетереп, Солтан йокларга ятты.

— Көннең шундый тиз үтүе нинди кызганыч! — дип ул йокы алдындагы уйларга чумды.

1938

ВӨҖДАН ГАЗАБЫ

Төнге сәгать бер. Өйдә авыр тынлык. Кешеләр аяк очларына гына басып йөриләр. Бу тынлыкны үлем белән тартышып яткан алты яшьлек Рөстәмнең сузып-сузып ыңгырашуы гына боза. Авыру янында башын түбән салып утырган Хәдичә апа, нишләргә белмичә, күз яшен йотып елый. Аның ике-өч көн рәтләп йокы күрмәгән күзләре йомылып эчкә батканнар.

— Нишлим, нишлим, бәгырем? — ди ул авыз эченнән, — сине бу газаптан коткарыр өчен үзем авырырга хәзермен, җаным...

Ап-ак мендәрләр өстенә яткан баласына карап, ул йөрәк өзгеч уйларга чума, йомшак куллары белән Рөстәмнең чем-кара чәчләрен сыйпый. Авыруның эссе маңгае бармакларны яндыра.

— Эти... эти,—дип бала саташа башлый,—мине дә Москвага алып бар... Әни, мине Москвага жибәрәсеңме?..

Ни дип әйтергә белмәгән Хәдичә апа:

— Ярый, ярый, алтыным, жибәрәм,—ди һәм ишеккә чаба. Куркуыннан ул бөтенләй аптырашта кала: шундый авыр минутларны иренең өйдә булмавына эче поша, ирен чакыртып телеграмма сукмавына үзен үзе тирги. «Ул өйдә булса, жинелрәк булыр иде, Рөстәмне ул үлем кочагыннан тартып алыр иде. Хәзер үк, хәзер үк телеграмма сугарга кирәк»,—дип уйлый.

— Бу докторы нишләп озак килми тагын?—дип үз алдына сораулар биреп утыра. Ишек ачылган саен атаклы доктор доцент Рәжәповның килеп керүен көтә. Яхшы белгеч булуы белән исеме телдән телгә йөргән доктор турында уйлану Хәдичә апага жылы өмет бирә. Һичшиксез, Рәжәпов Рөстәмне коткарыр. Тик килсен генә иде... Әгәр дә килмәсә? Хәзер соң инде, дисә? Иртәгә керермен дисә? Иртәгә хәтле Рөстәм ү... Юк, юк, Рөстәм яшәргә тиеш.

Хәдичә апаның борчылуы үскән саен үсте. Аның телгәләнгән йөрәге атылып чыгардай булды. Аякларында бер адым атларлык та көч калмады. Ана карап, Рөстәмнең авыр ыңгырашуларын тыңлап, бүлмәдәге башка кешеләр дә тирән кайгыда иделәр.

Әле күптән түгел генә Рөстәм менә шунда, шушы бүлмәләрдә шау-гөр килеп, йөгерә-йөгерә уйнап йөри иде. Аның шат тавышы, балаларга хас матурлык белән жырлавы, һәрнәрсәнең серенә төшенергә теләгәндәй, зурларның башына да кермәгән кызыклы сораулар бирүе семьяда бәхет һәм куаныч тудыра иде. Ә этисен, этисен ничек ярата иде! Ата да, теләсә нинди генә ашыгыч эше булмасын, ничек кенә арып кайтмасын, барыбер улы белән шаярмыйча, Рөстәме белән уйнамыйча калмый иде. Рөстәм өчен ул балаларга язылган нәни шигырьләр һәм әкиятләр ятлый иде. Ә хәзер... Хәдичә апаның күзләре Рөстәмнең уенчыкларына төшәләр. Уенчыклар да моңайгансыман ятим күренәләр.

Доктор Рәжәпов төнге сәгать икедә генә килде. Бүгенге төнне Рөстәм икенче пациенты иде инде аның. Балага ул ашыгыч укол ясады, үзе белән алып килгән ниндидер бер порошок бирде. Хәлдән тайган Хәдичә апага:

— Иртәгә хәтле авыруга бернәрсә дә бирмәгез. Ана

тынычлык кирәк. Үзегез дә ял итеп алыгыз: аяктан егылуыгыз мөмкин,— диде.

— Соң ничек, өмет бармы? — дип ана китәргә җыенган Рәҗәповка сорау бирде. Бу сорау, дөресе, докторның туры бирелгән сорауга җавап бирмичә уйланып торуы, Хәдичә апаны коточкыч бизгәк утына ташлады. Ул актык көчен җыеп соравын ачыклады:

— Ирем командировкага Москвага киткән иде... Бәлки чакыртырга кирәктер... Дөресен әйтегез... Мин нишләргә дә белмим.

— Иregезне борчудан ни файда! — диде доктор.— Балагызның хәле, үзегез дә күрәсез, җиңел түгел, ләкин куркынычлы дип тә булмый. Иртәгә хәтле көтик. Иртә белән мин тагы кереп чыгармын.

Хәдичә апа докторга акча сузды. Ләкин Рәҗәпов акчаны алып та, ни өчендер, өстәлгә куеп калдырып китте.

— Азсынды ахрысы,— дип уйлады ана акчаны күргә.

Ятып ял итәргә киңәш бирелсә дә, Хәдичә апа бу төнне дә йокысыз уздырды. Аңа карап, семьядагы бүтән кешеләр дә күз йоммыйча, тирән тынлыкта утырып чыктылар.

Иртә белән доктор Рәҗәпов яңадан керде. Хәдичә апа аны үзе каршы алды һәм ишек ачылу белән үк шатлыгын уртаклашырга ашыкты:

— Температурасы 38 гә төште, 15 кашык шулпа ашады. Йоклавы да бик тыныч булды. Төнлә килеп ярдәм итүегез өчен бик, бик рәхмәт.

Рәҗәпов бала янына узды.

— Тереләсеңме, яшь егет!—дип авыруга кул бирде.— Тизрәк терел әйдә. Урамда яз. Иптәшләрең уйнарга көтәләр. Синнән башка күңелсез, диләр. Иптәшләреңне яратасыңдыр бит?

— Яратам, Нәҗипне генә яратмыйм мин.

— Ник?

— Елак ул.

— Елакларны мин үзем дә яратмыйм. Тизрәк терел әйдә, мин сине улым белән таныштырырмын. Вил исемле. Матур исемме?

— Матур.

— Минем Вилем елауның нәрсә икәнен дә белми. Танышырсыңмы? Бир кулыңны!

Танышырга ризалык биреп, Рөстәм докторның кулын кысты һәм ягымлы бер елмаю белән:

— Ярый,—диде.

Әле кичә генә үлем белән тартышып яткан баланың бүген елмаюы, күңелле итеп сөйләшүе ана йөрәгенә җылылык кертте. Авыруны көлдерә алган докторга аның күп-күп итеп рәхмәтләр укыйсы, кайнар сүзләр әйтәсе килде. Һәм ул иң якын кешеләргә генә мөрәҗәгать итеп торган тавыш белән:

— Рәхим итегез!—дип Рәҗәповка чәй тәкъдим итте.

Чәй алдында бераз сөйләшкәннән соң, доктор китәргә хәзерләнде. Хәдичә апа аңа визит өчен йөз сум акча сузды.

— Сез бик юмартсыз,—дип, Рәҗәпов йөз сумның утыз сумын гына алды, калган җитмеш сумны өстәлгә куеп, элгечкә таба кузгалды. Аның күзләре стенага эленгән бер рәсемгә төштеләр. Рәсемдә — егерменче елларны хәтерләткән гаскәри киемнәргә киенгән, биленә наган таккан командир иде. Рәсемне күрүгә ул, бизгәк тоткандай, калтыранып китте һәм: «Бу — ул, Таһир Каһәрманов — минем корбаным»,—дип үз алдына сөйләнде.

— Бу кем?—дип Рәҗәпов, үзе дә сизмичә, кинәт борылып, Хәдичә апага сорау бирде.

— Ирем... Нигә, әллә танышмы?

— Юк, таныш түгел,—дип доктор ялганлады. Дөрес җавап бирмәү аңарда үз-үзенә ачу тудырды, һәм оялудан бит алмалары кызарып киткәндәй булды. Уңайсыз хәлдән котылу өчен ул киенә-киенә тагын берничә сүз кушты.

— Рәсемдә бик батыр күренә. Чыннан да шулаймы?

— Белмим, сугыш елларындагы батырлыкларын искә төшергәндә, иптәшләре бүген дә бик мактап сөйлиләр.

Яшь баланың булуын һәм Хәдичә ханымның Каһәрманова фамилиясе белән йөрмәвен хәтерләп:

— Ә хәзерге ирегез ничек? Ул да шулай батырмы?— дип доктор тагын бер-ике сорау бирергә теләгән иде. Ләкин: «Урынсыз сораулар белән ханымны мин шиккә төшерәм, ахры. Кабердә яткан якын иптәшен искә төшерүе дә авырдыр үзенә»,—дип уйлап, тиз генә саубуллашты да ашыга-ашыга чыгып китте.

Ишектән чыгуга, аны борчу алды, һәм ул, нәрсә эшләвенә хисап бирмичә, кире кайтты. Хәдичә апа аның төсе китүен, йөзенә кайгы чыгуын, кинәт картаюын күрде һәм гаҗәпсенү белән:

— Сезгә ни булды, доктор?—диде.

— Чир аяк астында йөри диләр. Мин үземне ничектер начар хис итә башладым. Мин инде сезгә артык кереп йөри алмам. Балагызның хәле начарланып китсә генә, мине чакыртырсыз. Ярыймы? Ләкин, минем уемча, хәзер ул тиз терeләчәк. Хушыгыз!

— Хушыгыз, доктор. Төнлә белән борчуыбыз өчен зинһар гафу итегез... Авырый күрмәгез,—дип Хәдичә апа аны озатып калды.

Таһир Каһәрмановның рәсемен һәм хатынын күрү Рәҗәповны моннан 18 ел элек булган вакыйгаларга алып китте. Ул, кая барасын белмичә, башын түбән салып урам буенча атлады. Тәмам онытылган, онытылмаса да, бик сирәк искә төшкән һәм искә төшкән саен күңелне борчыган, вөҗданны газаплаган фаҗигале төн коточкыч күренеш булып яңадан күз алдына калыкты. Каһәрмановның рәсемен күрү доцент Рәҗәповта үз-үзенә нәфрәт тудырды, үткән тормышына ләгънәтләр укытты.

Атнага якын ул, кая барырга һәм нәрсәгә тотынырга белмичә, онытылып йөрде. Аның кинәт үзгәреп китүе хатынын да, балаларын да әрнүле пошынуга салды. Элек шаян сүзгә, уен-көлкегә бай булган Риза Рәҗәпов хәзер күңелсез, кайгылы бер кешегә әйләнде, хатыны Нәгыймә апаның:

— Сиңа ни булды, Риза?—дип соравына каршы ул:

— Берни дә юк, болай гына... Кәефем юк минем,— дип өзек-өзек җаваплар биреп, кабинетына китә һәм шунда бикләнеп кичен-төнен ялгызлыкта уздыра торган булды. «Кәефе юклык» икенче атнаны да, өченче атнаны да дәвам иткәч, бөтен семьяны тирән кайгы басты. Бүлмәләрне, анда үлек яткандай, авыр тынлык чорнап алды. Бу тынлыкка иялэнмәгән нәни Вил генә буран куптарып бүлмәдән бүлмәгә чабып йөрде, ләкин әтисенең кабинет ишеген берничә тапкыр дөбердәтеп тә, «Әти! Әти дим!» дип эндәшүенә җавап ала алмагач, гадәттәге «Ай, улым!» кебек йомшак сүзләрне ишетмәгәч, аның бураны да басылды.

Нәгыймә апа Ризаның ябыгуына борчылып сырхаулый башлады. Бер кичне ул иренең кабинетына кереп:

— Авырыйсыңмы әллә, Ризук? — дип сорау бирде. Ризаның «юк» диюен ишетүгә, кайнар яшь түгеп еларга тотынды.

— Соң ни булды? Нигә әйтмисең?—дип ул үзенең җыелып килгән күп сорауларын яудырды.—Хезмәтең буенча бер-бер хәл булдымы әллә? Әйт, бәгырем, яшермә. Сөйлә, нинди кайгың бар синең? Ник бу кадәр үзгәрдең? Сәбәп нәрсә? Кырынмавына да бер атна булды инде... Һәр кич музыка уйный идең — музыкаңны ташладың... Һәр иртә саен докторлык диссертацияң өстендә эшли идең — инде аңа да кул тидермисең... Һәр атна театр, кинога, концертка йөри идек — анда да хәзер чакырмыйсың... Иван Васильевичларга, Нургалиләргә кунакка барадыр идек... Үзебезгә чакыра идек... Бар да бетте... барысы да онытылды... Ни булды, ни булды сиңа, Ризук? Ник әйтмисең? Мин түгел, Вил дә, Вил дә бит синең үзгәрүеңне сизә. «Әти хәзер мине кабинетына кертми, әти усал булды»,—ди...

Шушындый йөрәк өзгеч үтенү, ялвару, күз яше түгү вакытларында Риза Рәҗәпов, бөтен фаҗигане сөйләп, нинди авыр минутлар кичерүен аңлатырга хәзер иде. Ләкин актык көчен җыеп булса да, бу теләген җиңде ул. Әмма сөйлисе, кемгә булса да җан газабын бушатып бирәсе килә иде. Әгәр сөйләсә иде, күкрәктә дулаган ут ялкынын тышка чыгарса иде, җиңелрәк булыр иде төсле. Ләкин Риза Рәҗәповның үзенә карата булган нәфрәте миен чүкечләп торган газаплы уйлардан үзенең дә качарга йөрүе йөрәк серләрен ачарга ирек бирмәделәр.

Ул уйга талып, җылы сүзләр әзли-әзли, хатынын юатты. Нәгыймә апа аның күзләренә карады. Сөекле иренең матур күзләре аңа пыялалана башлаган кебек күренделәр: җентекләбрәк карыйм дигәндә, Рәҗәпов күзләрен йомды һәм читкә борылды.

Гомерлек иптәш, иң якын дус булган Нәгыймәнең күзләренә туры карый алмау, аның сорауларына канәгатьләнерлек җавап бирмәү доктор Рәҗәпов өчен иң каты җәзалану иде. Ул киенеп тизрәк өйдән чыгып китәргә ашыкты.

Күрше бакчага кереп иң ерак бер скамьяга барып утырды.

Берөзлексез тәмәке тартты. Бакчадагы шатлыклы музыка, яшьләрнең шау-гөр килеп уйнап йөрүләре, култыклашкан парларның «Яшәү күңелле дә соң!» дигән сыман кочыша-кочыша үтүләре Риза Рәҗәпов өчен мәңге кайтмаслык, мәңге ирешә алмаслык зур бәхет кебек булып тоелды.

— Бөтенесе дә келә, бөтенесе дә шатлана... Тик мин генә шатлана алмыйм... Чөнки минем намусым керле, мин вөждансыз калдым... Мин кешелегемне югалттым,— дип ул, күзгә төн кебек, караңгы уйлар астында бакчадан чыгып китте.

Кайтышлый ул:

— Трамвай астына ташланырга да, вәссәлам!—дип мәгънәсез үлем белән үләргә дә хәзер иде. Хәтта чыңгылдап узган вагоннарга таба бер-ике адым хәрәкәт тә ясап карады. Ләкин шул минутта аның башына «кеше аз йөри торган берәр җиргә барып лаякыл исергәнче эчәсе иде», дигән уй килде. Ә аяклары аны өйгә тарттылар.

Өенә ул бу төнне бик соң кайтты. Аның озак кайтмый торуына кайгырган Нәгыймә апа, иренең кайда икәнлеген белергә тырышып, берничә урынга телефон шалтыратырга да өлгергән иде инде.

Икенче көнне Рәҗәпов хезмәткә китте һәм бүтән шәһәргә күчәргә җыенуы сәбәпле, үзен эштән азат итәргә сорады. Мондый гаризага дирекция дә, Рәҗәповның шәкертләре дә гаҗәпкә калдылар.

— Юк, Риза Валеевич, без сезне хезмәттән азат итә алмыйбыз,—диде директор,—сез арыгансыз, сезгә ял итәргә кирәк. Дирекция сезгә береннән, теләсәгез Кырымга, теләсәгез Кавказга путевка бирә. Ярыймы?

Үзен-үзе белмичә доктор «юк» та димәде, ризалык та бирмәде. Дирекция бүлмәсенә ничек кинәт килеп керсә, шулай ук кинәт чыгып та китте.

Аның мондый кыланышларын бик сирәк күргән директор уйга чумды. Һәм кич белән ул бер профессорны һәм партком секретарен алып Рәҗәповның өенә хәл белергә барды. Ләкин Рәҗәпов өйдә юк иде. Нәгыймә апа кунакларны чәй белән сыйлады. Кунаклар белән сөйләшеп утыру аның кайгысын беркадәр җиңеләйткән дә кебек булды. Ул алардан Рәҗәповның хезмәт итә торган урында яратылуын һәм элеккечә үк яхшы эшләвен белде. Ләкин сүз Риза Рәҗәповның, бу шәһәрдән китәргә җыенып, дирекциягә бирелгән гаризасына житкәч, Нәгыймә апа түзмәде — елап җибәрде. Аны иренең акылдан шашуы куркытты.

— Безгә әйтмичә, безнең белән сөйләшмичә, башка шәһәргә күчәргә!.. Ни булды, ни булды минем сөеклемә... Рәтләп ашаганы, рәтләп йокы күргәне юк... Кабинетында

төн буе ут сүнми... Төнен бер ялгызы утырып чыга... Чәче агарып бетте,— дип Нәгыймә апа үзенең кайгысын аңлатты.

Кунаклар аны мөмкин булганча тынычландырып һәм кулдан килгән бөтен булышлыкны күрсәтергә сүз биреп саубуллаштылар.

Бу төнне дә Риза Рәҗәпов соң кайтты.

— Борчылмагыз, акыллыларым, мин сәламәт. Вакытлы ахмаклыкларым өчен гафу сорыйм. Мин тук, Нәгыймә җаным, мәшәкатьләнмә. Диссертациям өчен гаҗәп матур, кыю фикерләр таптым. Онытмас борын шуларны язып алыйм әле... Хәерле төн! — дип, тул-туры кабинетына узды.

— Син ничек уйлыйсың?— дип Нәгыймә апа әле быел гына институт бетереп врач исеме алган олы кызына кинаяле сорау бирде. Яшь врач Гөлсем бу сорауны бер генә төрле: «Әткән акылдан шашмыймы?» — дип кенә аңлады. Һәм бугазга килеп терәлгән төенне йотарга теләп:

— Юкка пошынасың, әнкәй. Арыган ул. Аңа тынычлык кирәк,— диде.

Ә үзе, әнисенә сиздермичә, психиатрия китабын караштырырга керешге. Шунда ул әтисенең сәер тоелган сүзләрен, баш әйләндергеч хәрәкәтләрен акылдан шашу симптомнары итеп аңлады, һәм яшь врачның керфекләре кайнар күз яше белән чыландылар.

— Менә нәрсә, әнкәй, — диде ул, тыныч булырга тырышып,— юк сораулар белән әткәйне борчымыйк. Иртәгә син аңа үзе яраткан иң тәмле ашларын пешер. Йөзеңдәге кайгылы чыраеңны бетерергә тырыш. Иптәшләренә дә әйтик: «Сиңа ни булды? Ябыккансың. Авырыйсыңмы әллә?» — дип сагыз булмасыннар. «Үзгәргәнсең. Төсең киткән ич»,—дип атлаган саен быжылдап торсалар, сәламәт йөргән җиреңнән дә чирли башларсың. Кәефен ачыйк без аның. Кичә ясап, иптәшләрен чакырыйк... күр дә тор — терелер...

Нәгыймә апа моңа да күнде. Ләкин төнлә белән ул, тирән тынлык саклап, кабинет ишеге төбенә берничә тапкыр килеп китте. Кабинетта ут күреп, шырпы кабызган тавыш ишетеп: «Һаман йокламый... Ничек түзә мескенем»,—дип сыкрады. Ятса да, йоклый алмады. Иртәнге чәйгә кайнар пирожкилар өлгертер өчен торып камыр куйды.

Ә доктор Рәҗәповның вөждан газабы бу төнне тагы да көчәйде. Күз алдын караңгылаткан авыр уйлардан котылыр өчен ул диссертациясен дәвам итәргә утырды. Ләкин бер сәгать чамасы баш ватып утырса да, бишалты җөмлә язудан һәм аларны сызып ташлаудан башка, гыйльми хезмәтенә ул бер генә дә үзгәреш кертә алмады. Пушкин, Тукай китапларын ачты. Горкийның «Изергиль карчык» исемле легендасын укырга тотынды. Данконың кешеләргә булган чиксез мәхәббәте турында язылган урыннарга җиткәч, күптән, бик күптән еламаган докторның күзләренә энҗе бөртекләре чыкты. Кешеләрне сазлыктан, караңгылыктан коткару өчен Данко үзенең күкрәген ертып йөрәген чыгарган. Данлы егет Данко кояшсыман янган ялкынлы йөрәген күтәреп кешеләргә юл күрсәткән.

Рәҗәпов артык дәвам итә алмады, китапны өстәлгә куйды да кроватька барып егылды. Данко турында укыгач, ул үзенең ваклыгын, кечерәйгәнен аңлады. Бер үк вакытта анда, әлеге кичерешләрен тәмамларга теләгәндәй, яңа фикерләр белән яңа тойгылар да кузгалдылар. Горькийның легендасы тәэсире астында ул язарга утырды. Бу юлы инде Рәҗәпов яза торган әйберенең бер генә сүзен дә бозмады. Бер-бер артлы аккан җөмләләргә ул үзенең кайгы-сагышын салырга теләде.

Менә нәрсә язды ул бу төнне:

«НКВД га.

Доцент Риза Рәҗәповтан.

1920 нче елны мин Ч. шәһәренең хәрби госпиталендә врач булып эшләдем. Госпитальгә килеп керүем белән үк баш врач мине үз йогынтысына алырга тырышты һәм, җайлы минут чыккан саен политик мәсьәләләр кузгатып, Советлар властеның тиздән бетүе турында миңа төрле дәлилләр китерергә тотынды. Мин, иске карашлы интеллигент, аңа ышаныр-ышанмас, икеләнеп йөрдем.

Көзге төннәрнең берсендә минем палатама тиф белән авырган бер командирны китерделәр. Бу командирның батырлыгы, арсландай кыюлыгы турында күп язалар һәм күп сөйлиләр иде.

Шул төнне миңа баш врач үзенең беренче заданиесен

бирде. Авыр хәлдә яткан легендар командирга күрсәтеп, ул:

— Бу моннан тере чыкмаска тиешле: аны кабер көтә. Аңладыңмы?—диде.

Үз гомеремдә беренче тапкыр ишетелгән мондый әмергә каршы мин ни дип әйтергә дә аптырадым.

Ике-өч көннән соң авыруның хәле яхшырган кебек булды. Мин аның тизрәк терелүен һәм баш врач хәзерләгән үлем капкынынннан котылып чыгып китүен көттем.

— Озакка сузасыз, Риза Валеевич,—дип баш врач миңа ашыгырга кушты. Ләкин мин, иске карашлы вак интеллигент, аның явыз әмерен кире кагарга үземдә көч тапмадым.

Шунда мин үземнең куркак җан икәнлегемне белдем.

Госпитальгә керүенең дүртенче төнендә авыруым аңын югалтты. «Мин чыккан арада баш врач агу бирде, күрәсең», дип уйга калдым. Баш врач өстеннән берәр җиргә барып хәбәр итүдән мине командирның үз палатамда булуы туктатып торды, «Ышанмаслар, баш врач бөтен гаепне минем өстемә ташлар»,—дип уйланып йөргәндә, госпитальгә тагын авырулар китерделәр. Палатамда буш койка булмаса да, баш врач, әйбер өләшкән шикелле, бер авыруга төртеп:

— Риза Валеевич, монысы сезгә, теге командир урынына!—диде.

— Ә командир кая?

— Үлекләр камерасына! Кызурак әйләнегез, доктор... үлекләр турында кайгырткaнчы, тереләр турында, тереләргә ярдәм итү турында уйлар идегез,—дип ул минем палатама кереп китте.

Нинди хәлдә калуымны язмыйм. Врач булуыма үкендем мин — кичерешләремне шул аңлатса кирәк.

Командирны үлекләр камерасына алып чыктылар. Носилканың бер очыннан баш врач үзе тотып барды.

— Туктагыз! Нишлисез! Минем авыруымны кая алып барасыз?—дип мин сүземне әйтеп бетерергә дә өлгермәдем, ул:

— Мин сезгә яңа авыруларны кабул итәргә кушкан идем бугай. Барыгыз, бар... Ләкин, зинһар үлекләр белән тереләрне бутый күрмәгез,—дип кычкырып калды.

Батыр командирның кинәт үлүенә гаҗәпләнеп, мин баскан урынымда катып калдым. «Ул, ул үтерде аны!» дип, мине куркынычлы уйлар сырып алдылар.

Явыз дошманның бер генә заданиесен дә үтәмәдем мин. Ләкин сезнең алдыгызда, иптәш чекистлар, мин үземә сорау бирәм:

— Баш врачның корткычлыгын белеп тә, тиешле оешмаларга әйтмәвем, ниһаять, баш врач кулы белән кабергә озатылган командирны якламавым — дошманга ризалык күрсәтү түгел идеме?

Ризалык күрсәтү иде.

Озакламый командирның хәлен сорашып телефон шалтыраттылар.

— Тирән кайгы, иптәшләр: командир Каһарманов бүген төнлә белән вафат,—дип баш врач җавап бирде.

Аның бу хәбәрне әйткәндә кайгылы тавыш ясарга тырышуы һәм үзе белән бергә мине дә палаталарга обходка алып китүе — мине шиккә төшерделәр. Ләкин нәрсәдән шикләнүемне берәр кешегә барып әйтү түгел, шул турыда, шикләнүемнең дөрескә чыгуы мөмкинлеге турында уйлаудан да курыктым мин.

Ә соңыннан вакыйга болай булды. Үлекләр камерасына ташланган командир таң алдында аңына килгән. Башта ул, кайда ятканын белмичә, су сорап ыңгырашкан. Аннары туңа башлаганын сизеп, әйләнә-тирәсен капшарга керешкән. Куллары белән сап-салкын мәетләргә тигәч, үзенең холодильникта — үлекләр камерасында ятканын аңлаган. Үлемне җиңәргә өйрәнгән батыр, актык көчен җыеп, кычкырырга, ишеккә сөйрәлеп килеп ишек дөбердәтергә тотынган. Кычкыра-кычкыра тавышы карлыккан, дөбердәтә-дөбердәтә көче беткән. Ләкин яшисе килү, мондый хурлыклы җирдә, мәетләр арасында үләсе килмәү аңа көч биргән. Ул тагын... кычкырган һәм тагын дөбердәткән. Ниһаять:

— Кем бар?—дип аның тавышына каравылчы килгән.

— А...ч зин-һар... а...ч,—дип инәлүне ишетүгә, каравылчы холодильник ишеген ачып җибәргән.

Ярым ялангач кешенең үлекләр арасыннан күтәрелеп, чайкала-чайкала аякка басканын күргәч һәм: «Кулыңны бир»,—диюен ишеткәч, дини хорафатларга ышанган каравылчы:

— Үлекләр терелә... үлекләр!—дип разбой салган.

Тавышка бөтен госпиталь халкы җыелды, хәтта, режимны бозып, кайбер авырулар да чыктылар.

Командирны янадан палатага керттеләр. Шунда ул мине танып алып:

— Сез нишлисез, доктор әфәнде! Сезгә доктор исеме хәрам! Юк, без көрәшәчәкбез әле! — дип буыла-буыла бер-ике җөмлә ташлады.

Үз-үземә кул күтәрүдән мине нәрсә тоткандыр, белмим.

Нинди хәлдә булганмын — аңламыйм. Тик Ч... шәһәрен ташлап качып китүемне генә хәтерлим.

Икенче шәһәрдә мин газеталарның берсеннән командир Таһир Каһәрмановның госпитальдә үлгәнен белдем.

Иптәш чекистлар, сезнең алдыгызда мин үземә соңгы соравымны бирәм:

— Таһир Каһәрмановның үлүенә сәбәпче булган кешеләрнең иң беренчесе һәм иң гаеплесе — мин түгел идемме?

Мин идем.

Шушы вакыйгадан соң мин ике-өч ел буена кыргый кеше хәлендә яшәдем. Мине һәр адымда Таһир Каһәрмановның: «Сез нишлисез, доктор әфәнде? Сезгә доктор исеме хәрам!» дигән сүзләре сагалап йөрделәр. Эштә генә тик аз-маз онытыла ала идем мин. Намуслы хезмәтем белән мин үземнең пычрак җинаятемне юарга тырыштым. Төнен-көнен эшләсәм дә, аз эшлим, үземне аклый алмыйм, саф кеше исемен йөртергә хаклы түгелмен кебек тоелды.

Тырышып эшләвем өчен мине күп тапкыр бүләкләделәр, ләкин һәр бүләкне кабул итеп алганда минем күз алдымда: «Сез нишлисез, доктор әфәнде?» дип, каһкаһәле елмаю белән Таһир Каһәрманов басып торды.

Мин мактаулардан качтым. Бирелеп эшләсәм дә, актив булып күренмәскә тырыштым. Ләкин мине күрделәр һәм яктыга чыгардылар.

Госпитальдәге вакыйга аркасында булган борчылуым минем тора-бара кимегән кебек булды. Ләкин үткән айны мин, бер авыру бала янына баргач, командир Каһәрмановның 1920 нче елны төшкән рәсемен күрдем. Яңадан мине әлеге фаҗигале картиналар — палата, холодильник — чорнап алдылар. Еллар буе мин әйтеп бетергесез вөҗдан газабында йөрим. Ә бу соңгы айны акылдан шашу дәрәҗәсенә җиттем. «Кулга алынудан курка бу», — дип уйламагыз, иптәш чекистлар. Һич юк, кулга алыну мине куркытмый. Мине намусым борчый,

вөжданым газаплый. Кеше күзенә туры карарга, сөекле хатыным белән сөекле балаларыма сүз кушарга оялам мин.

Зинһар ярдәм итегез: мине кулга алып, миңа тиешле җәзаны бирегез. Шунсыз мин тынычлана алмыйм.

Адресымны да, эш буенча кирәк булган фамилияләрне дә язып тормыйм, чөнки бу хат белән бергә мин үзем килдем һәм җәза алмыйча китмәскә булдым.

Риза Рәҗәпов.»

Иртә белән Нәгыймә иң тәмле ашлардан өстәл хәзерләде. Үзе дә, балалары да, бәйрәмчә киенеп, кадерле кешенең чәйгә чыгуын көттеләр. Ләкин Риза Рәҗәпов кабинетыннан чыгуга ук:

— Сез утырыша торыгыз, мин хәзер кайтам,—дип күздән югалды.

Сәгать арты сәгать узды. Сүнмәсен дип самоварга күмер өстәлә торды. Озак-озак көтеп тә доктор кайтмагач, Нәгыймә апа, Гөлсемне алып, ирен эзләргә чыгып китте.

Риза Рәҗәпов туп-туры НКВД га барды һәм, комендатурага кереп, хатны хәзер үк начальникка тапшыруны сорады. 40—50 минут үтүгә, ана пропуск бирделәр һәм №нче бүлмәгә узарга үтенделәр. «Өйдә чәйгә көтә торганнардыр. Озак көтәргә туры килер мескеннәремә. Хат язып салырга кирәк булыр. Бәлки свидание дә бирерләр әле»,— дип уйлана-уйлана ул пропускта күрсәтелгән бүлмәгә барып житте.

— Рәхим итегез,—дип, аны урта яшьләрдәге ачык чырайлы бер иптәш каршы алды.

Докторга урындык тәкъдим ителде, өстәлгә ике стакан чәй һәм бутербродлар куелды. Бер стакан чәйне Рәҗәповка, икенчесен үзенә алып ачык чырайлы иптәш:

— Кунак булыгыз!—диде.

Ничек итеп сүз башларга белмәгән Рәҗәпов:

— Рәхмәт, мин бик озак көттергән кунак. «Лучше поздно, чем никогда», диләр. Укыдыгызмы?—диде.

— Сезнең хатыгызны бүлек начальнигы үзе укыды. Ләкин, ашыгыч эшләр булу сәбәпле, хәзергә ул сезне кабул итә алмый әле. Сезнең белән сөйләшә торуны миңа тапшырды. Менә нәрсә, иптәш Рәҗәпов, сез язган нәрсә безгә бөтенесе дә мәгълүм.

— Ничек мәгълүм!? Мин бит аны берәүгә дә сөйлә-

гәнем юк,—дип, доктор ачык чырайлы иптәшнең сүзен бүлде.

— Сез язган вакыйга 1921 нче елны ук тикшерелеп беткән.

— Бетмәгән!—диде Рәҗәпов, урыныннан торып.— Бетсә, ни өчен мине кулга алучы булмады?

— Беренчедән, сез качкансыз; икенчедән, сезнең җинаятегез үзегез язган дәрәҗәдә үк булмаган; өченчедән, сезне эзләп тапкач, сезнең үзгәрүегез беленгән. Менә нәрсә, иптәш Рәҗәпов, мин сезгә кайтырга да намуслы эшегезне дәвам итәргә киңәш бирер идем. Моннан 18 ел элек булган һәм бүген аңа үзегез дә нәфрәт белән караган вакыйга өчен җәза көтү кирәксез нәрсә.

Эшнең мондый төс алуына Рәҗәпов бөтенләй аптырашта калды. Бу минутларда ул үз гомерендә беренче тапкыр тирән шатлык кичерде. Шатлыктан аның елыйсы да, көләсе дә килде. Бу шатлык — йөрәк итен ашаган, җанны газаплаган нәфрәтле вакыйганы кешегә белдерү һәм шуны белдергәннән соң да ышаныч күрү, чын кешелек хисләрен тату шатлыгы иде.

Телефон шалтыравы Рәҗәповны татлы уйларыннан аерды.

— Сезне бүлек начальнигы көтә,—диде ачык чырайлы иптәш,—әйдәгез, кабинетын күрсәтим.

Озын коридор буйлап бераз баргач, Рәҗәпов бер кабинетның ишеген какты.

«Мөмкин!» дигән тавышны ишетүгә, тирән дулкынлану белән доктор ишекне ачты.

— Хуш киләсез! Рәхим итәсез!—дип, Риза Рәҗәпов алдына таза гәүдәле, ләкин гаҗәп җитез хәрәкәтле бер иптәш килеп басты.

— Исәнмесез! — дип, докторга ул кул сузды һәм алга, йомшак креслога таба җитәкләде.

Рәҗәпов башын күтәреп начальникка карады һәм гаҗәпкә калды: аның алдында Таһир Каһәрманов басып тора иде. Һич үзгәрмәгән диярлек. Әнә шрамы да күренә. Тик чәче генә агарган.

— Соң шулай ук мине, «доктор әфәнде»не, сез гафу иттегезмени?—дип, Риза Рәҗәпов Таһир Каһәрмановның күзләренә карады.

— Үткәннәрне искә төшермик — сонынтын, башка вакытны. Бу кадәр борчылуыгызны белгән булсам, өе-

гезгә барып тынычландырган булыр идем... Да, онытмас борын әйтим: балама ярдәм итүегез өчен зур рәхмәт. Иптәшем Хәдичә сезне мактап бетерә алмый. «Баламны алып, өенә рәхмәт әйтергә барам»,—ди, тик оялуы гына туктатып тора үзен.

Гомумән дә мактауны яратмаган Рәҗәпов мактау турындагы сүзләрне бу урында бөтенләй көтмәгән иде.

— Ә соң сезнең үлүегез? Сезне бит ул елларны газеталарда үлгән дип язганнар иде,—дип, доктор үзен борчыган вакыйгага күчте.

— Госпитальдән «үлгән» дип шалтыраткач, кайсыдыр шунда газетага хәбәр бирергә ашыккан. Теге баш врач кулга алынгач кына йомгак чишелде. Ул явыз нәрсә сезгә бик ачуланган дип сөйләделәр. «Бөтен нәрсә шул җебегәннең куркаклыгы аркасында гына ачылды», дигән. Я, ярый, боларны ташлыйк. Сезнең яңа җинаятегезгә күчик,—дип Каһәрманов урыныннан торды.

— Нинди җинаять ул тагын?—дип, Рәҗәпов Каһәрмановның сүзен бүлде.

— Сез минем Рөстәмемә: «Мин сине улым белән таныштырырмын»,—дигәнсез. Көтә бит, «Вил белән кайчан танышам?»—ди. Сүзегездә тормыйсыз, доктор. Киләсе ял көнне мин сезне үземә кунакка көтәм. Ризамы? Мөмкинме?

— Мөмкин, риза, рәхмәт!—дип, Рәҗәпов тирән җылылык белән Таһир Каһәрмановның кулын кысты.

1939

НИШЛӘРГӘ

Нишләргә?

Менә ике көн инде мин, шушы сорауга җавап таба алмыйча, баш ватам. Чынлап та, нишләргә: хатны Сылуга күрсәтергәме, юкмы? Куелган сорауга ялгышмыйча җавап бирер өчен мин тагы бер тапкыр бөтен вакыйганы күз алдымнан кичерергә булдым һәм язарга утырдым.

Кеше дигәнең гаять катлаулы нәрсә. Аны аңлавы кыен. Ә минем аңлыйсым килә. Кешенең күзгә күренгән тышкы кабыгын түгел, ә шул кабык астында яткан катлаулы кешенең үзен күрәсем, аңлыйсым һәм аның өчен җаваплы буласым килә.

Бу «язмалар»ны мин фәкать үзем өчен генә язам. Минe берәү дә ашыктырмый, минем «язмалар»ымны берәү дә көтми, сорамый. Авыр уйларымны, чуалчык фикерләремне бер тәртипкә китерер өчен генә язам мин аларны.

Өстәлемдә минем бер хат ята. Аны миңа Сылуның әтисе Төхфәт абзый яза. Әгәр дә мин шул хатны кадерле Сылуыма күрсәтсәм, әгәр дә мин күз яше тулган бу хатны бәхетле Сылуга укысам, һичшиксез, үзен ул бәхетсез сизәчәк. Уйнарга, көләргә яраткан, тормышның яхшы якларын гына күрергә өйрәнгән Сылуның юлдашы моңарчы гел шатлыктан гына тора иде. Беләм: хатны укыганнан соң аның юлдашы кайгы булачак... Бәлки ялгышамдыр... Бик ихтимал, Сылуны аңлап җиткермимдер...

Хәзер дә хәтеремдә...

Беренче сентябрь иде, беренче лекциягә соңга калмас өчен, мин ашыга-ашыга университетка киләм. Йөзләрчә бүлмәдән торган тарихи зур бина буйлап үземә кирәк аудиторияне эзлим, йөгерә-йөгерә икенче катка менәм. Ләкин соң инде: лекция башланган... Айлар буенча түземсезлек белән көтелгән, татлы хыяллар тудырган беренче лекция башланган! Ишеге ябык аудитория алдында мин башымны түбән иеп моңаеп калдым. Минем дигән кәеф кинәт юкка чыккандай булды.

Профессорның лекциясен бүлеп, аудиториягә керергәме, юкмы дип уйланып торганда, минем яныма ашыгыч адымнар белән бер кыз килеп басты. Янып торган кара күзле, озын кара чәчле, зифа буйлы бу кызның гүзәллеге искитәрлек иде.

— Әллә соңга калдыкмы?—дип, гүзәл кыз миңа русча сорау бирде.

— Әйе, соңга калдык шул,—дидем мин һәм, матурлыгыннан гаҗәпкә калуымны сиздермәскә тырышып, читкә борылырга теләдем. Ләкин булдыра алмадым. Нечкә материядән тегелгән һәм тәненә сыланып яткан җәйге пальтосының төймәләрен җибәрә-җибәрә ул минем яныма ук килеп басты һәм:

— Уф! Ә мин шундый чаптым!—диде.

Шунда мин, пальтосы ачылып китүгә, аның нәфис ефәк күлмәген күрдем. Гүзәл кыз «уф!» дип сулыш алганда ефәк күлмәк кешене һуштан яздырырлык һәм тел белән әйтеп бирә алмаслык матур бер хәрәкәт ясады.

Мин ишек ярыгына иелдем. Миңа карап кыз да иелде. Йөзгә җылы хуш ис бәрде. Үз гомеремдә беренче мәртәбә татыган бу хуш истән, татлы исерүдән мин лекция кайгысын да оныткан идем инде.

— Нәрсә басып торабыз, әйдәгез, кердек! — дип, кыз ишекне ачты һәм, эссе, йомшак кулы белән кулымнан тотып, мине аудиториягә тартты. Арткы сафларга узганда, әллә безнең кыюлыктан, әллә кызның гүзәллегеннән — бар да безгә игътибар иттеләр. Урынлымы, урынсызмы — белмим, хәтта профессор да берничә секундка сөйләвеннән туктады һәм, «Икенче болай итмәгез, соңга калып йөрмәгез» дигәнсыман, безгә карап, теләр-теләмәс кенә йөткереп куйды. Гүзәл кызны күрүгә, кайбер студент, студенткалар үзара нәрсәдер язышырга да тотындылар.

Без янәшә утырдык.

Бераз тынычлангач, кыз миңа сорау бирде:

— Исемегез ничек?

— Гариф.

— Татар икәнсез,—дип, ул җылы итеп елмайды һәм татарча сөйли башлады.—Ә минем — Сылу.

Тагын бераз торгач һәм минем язып утыруымны күргәч:

— Менә нәрсә, Гариф: хәзер минем тыңлап кына торасым килә. Сез генә языгыз инде, мин күчереп алырмын. Ә киләсе лекцияне мин язармын, сез тынларсыз, яме? Шулай алмашлап эшләргә сез ризамы?—дип сорады.

Куануымны сиздермәскә тырышып, мин:

— Риза, риза,—дидем.

Безнең дуслык әнә шулай башланды. Әмма бәхет бер килсә килә дә соң! Кеше гомерендә иң кайнар һәм иң зур дәрт — белү дәрте. Гүзәл кыз янында утыру, биш ел буена аның белән бергә булу миңа әнә шул дәртне бирде. Ләкин дәрт үзе генә җитми, көч тә кирәк. Сылу миңа көч бирде. Сылу мине яшәртеп җибәрде.

Без биш ел бергә укыдык. Биш ел эчендә азмы ямьле көннәр, азмы татлы үпкәләшүләр булды. Алар санап бетергесез, алар бер-берсеннән матурлар.

Гүзәл кызга кемнәр генә күз төшерми калыр икән! Сылу тирәсендә өйләнергә теләүче егетләр бик күп булды. Ләкин ул аларның берсенә дә җитди илтифат ит-

мәде. Без гел бергә йөрдек: бергә дәрес хәзерләдек, бергә җәмәгать эше үтәдек, бергә биедек, бергә катокта шудык.

Сылу аерылып, җәйге ялга киткәндә, янымда Сылу юклыктан эч пошканда, мин аны яратуымны аңладым.

Әйе, мин аны сөйдем. Сөйгәнемнең кәефен бозмас өчен мин лекциядә бер генә мөһим сүзне дә төшереп калдырмаска, төннәр буе рус теле өстендә утырып, бер генә сүзне дә ялгыш язмаска тырыштым. Сылу янында утырырга хаклы булу өчен, мин еш кырынырга, чиста йөрергә өйрәндем.

Ни генә эшләтми бу мәхәббәт!

Бәхетле биш ел үтеп тә китте.

Университетны тәмам итеп чыгучылар шәрәфенә банкет-мәҗлес ясалды. Анда кешеләр күңел ачтылар, шатлыклары турында сөйләделәр, берсен-берсе котлап тостлар күтәрделәр. Ә мин... мин кайгырдым. Дөрес, югары белемле булып чыгу минем өчен дә зур шатлык иде. Ләкин Сылудан аерылып калу кайгысы йөрәкне әрнетте.

Мәҗлес танга кадәр сузылды. Соңгы вальсны биер алдыннан, Сылу мине бакчага чакырып чыгарды.

— Бу шау-шудан минем башым авырта башлады. Бакчага чыгып кермибезме?—диде ул.

Беренче очрашудагы кебек үк, бакчага чыккач та, Сылу «Уф! Нинди рәхәт!» дип сулады. Аннары скамейкага барып утырды, нәрсәдер әйтергә хәзерләнгәнсыман, миңа карап торды һәм университет белән саубуллашты:

— Сау бул, безгә белем биргән әнкәбез! Бөтенесе өчен дә рәхмәт. Син дә сау бул, Гариф, сиңа да дуслыгың өчен рәхмәт. Син яхшы идең...

— Син дә, сиңа да,—дип, мин җавап кайтардым.

— Бүген кич Казаннан мин китәм. Бәлки күрешергә дә туры килмәс. Хәер, хатлар язышырга мөмкин. Мине исеңә төшерерсеңме соң?

— Төшерермен, Сылу,— дидем мин.

Их, бу кеше дигәнең! Мин аны чын-чынлап сөйдем, ә үзенә: «Сылу, мин бит сине сөям!» — дип әйтә алмадым. Шайтан белсен, нәрсә туктатып торгандыр мине. Бары тик: «Миңа карата берәр теләгең юкмы?»—дип кенә сорый алдым. «Мин дә бит сине сөям» дигәнсыман, ул минем күзләремә карады һәм җавап бирде:

— Пароход биш сәгатьтә кузгала. Мине озата бар-

саң, мин бик шат булыр идем. Әткәй киңәшмәгә китә. Бүтән озатыр кешем дә юк.

Билгеле, мин риза булдым. Озату нәрсә? Кадерлем өчен. Сылуым өчен мин утка-суга керергә дә әзер идем.

Сәгать дүрттә мин пристаньга төштем. Мин төшкәндә, Сылу юк иде әле. Касса алдына бардым. Җәйге ай булганга ахры, халык бик аз иде: әллә минем бәхеткә шундый җай килеп торды. Мин, нәрсә эшләвемә хисап бирмичә, Сылу китә торган пароходка, Козловкага хәтле билет алдым. Озакламый Сылу да килеп житте. Мине күрүгә ул бик шатланды.

— Рәхмәт. Сүзеңдә торгансың,—дип кулымны кысты. Пароходка кергәч, мин аны югарыга, палубага, менәргә чакырдым һәм курка-курка гына:

— Каршы килмәсәң, мин сине Козловка пристанена чаклы озата барыр идем,— дидем.

— Чынлап әйтәсеңме, Гариф!—дип, ул минем кулларымнан тотты.

— Чынлап, Сылу.

— Билет алыйк алайса...

Мин аңа билетымны гына түгел, хәтта каютамны да күрсәттем. Ләкин каютамны күрүгә, Сылу йөгереп чыгып китте. Ник? Кая? — Аңлавы читен иде. «Нишләдем мин! Нишләдем! Менә ахмак!» дип, мин үземне тирги-тирги пошынып утырдым.

Биш-ун минут та үтмәде, Сылу яңадан чабып керде.

— Булды!—диде ул, кулындагы билетын күрсәтеп.— Тугызынчы каюта! «Өченче класс билетымны икенче класска алмаштырыгыз һәм миңа тугызынчы каютага билет бирегез»,—дигәч, кассиршаның күзләре шар булды. «Анда ир кеше бар»,—дигән була. «Ә булса соң, сезгә ни? Ул ир кеше бәлки минем иремдер»,—дигән идем, шаркылдап көлеп җибәрде һәм менә шушы билетны сузды.

Сылуның чаялыгын мин яхшы белә идем. Шулай да бу кадәргә барып җитәр дип уйламаган идем. Мондый адымны фәкать яраткан кеше генә һәм яраткан кешесе өчен генә эшли ала. Нинди бәхетле идем мин шул минутта! «Сылу, син минеке!»—дип әйтергә, биш ел буена өмет итеп килгән гүзәлемне кочарга, үбәргә әзер идем мин. Ләкин начарга алуы мөмкин дип уңайсызландым.

Пароход ни өчендер бик соң кузгалды. Ул кузгалып киткәндә, төнге Идел өсте кызыл утлар белән бизәлгән

иде инде. Шул утларга карап, без йомшак җил иркәләве астында палубада утырдык. Үзеннән-үзе сүз чыгып, йолдызлар турында сөйләштек. Кайбер романнардагыча, йолдызларга исемнәр бирдек: «Монысы — Сылу йолдыз, әнә тегесе — Гариф йолдыз»,—дидек.

Сылу туңа башлагач, салонга кереп чәй эчтек һәм каютага киттек.

— Менә монда утыр,—дип, Сылу үз янында миңа урын күрсәтте.

Кинәт туган кыюлык белән мин тартынуымны оныттым һәм Сылуны кочагыма алдым. Кочакта ул эрегәндәй булды. Тик шунда гына мин аерылышу аның өчен дә никадәр газаплы икәнен аңладым. Ә вакыт уза бирде. Вакыт узган саен, безнең мәхәббәтебез үсте, киңәйде. Теләмәсәм дә пароходтан төшәр чак җитте. Көндезге сәгать уникедә миңа документлар алып хезмәткә барырга кирәк иде. Шуңа күрә Козловкада төшәргә туры килде.

— Казанга кайтырсыңмы?—дип, мин палубада басып калган Сылуга кычкырдым.

— Кайтыйммы соң? — диде ул.

— Кайт, Сылу...

— Бөтенләйгәме?

— Бөтенләйгә, Сылу,— дидем һәм аның янына, пароходка мендем.

— Кайтырмын, Гариф. Әткәйгә дә миннән башка күңелсез. Мин ышанам: без бик яхшы тормыш корырбыз. — Кулларын ул минем җилкәмә салды һәм иреннәремнән үпте.— Инде бар, төш, юкса пароход кузгала.

Бәхеттән, аерылу кайгысыннан һәм ышандырылган шатлыклы семья тормышыннан мин үз-үземне аңларлык хәлдә түгел идем.

Пароход кузгалып китте. Пароход белән бергә минем Сылу да китте. Мин бик озак, баскан урынымнан кузгала алмыйча, пароход киткән якка карап тордым.

Сылуның Казанга кайтуы миңа сөйләп бетергесез шатлык бирде. Ике-өч ай үтүгә, без бергә тора башладык.

Күңелле дә соң безнең тормыш! Сылуда яшәү уты дөрли. Ул көн саен берәр нәрсә уйлап чыгара, юк, уйлап чыгармый, аның яңадан-яңа күңелле яклары үзләреннән-үзләре туалар. Сылуның һәрбер кыланышы табигый. Аның үпкәләве дә сөйкемле бала үпкәләвесыман йөрәккә ягымлы. Ул үпкәләгәндә, мин, балаларча тавыш белән:

Үзе акыллы, үзе сөйкемле,
Үзе усал,
Үзе болай бер дә
Усал түгел кебек шикелле,—

дип, Такташның шигырен укыйм. Сылу түзми — кычкырып көлеп җибәрә.

Вакыт-вакыт ул әнкәсен сагына. «Әнкәй тифтан үлмәгән булса, безгә тагы да күңеллерәк булыр иде»,— ди.

Ләкин безнең кушылуыбыз, ачыграк әйткәндә, Сылуның минем квартирага күчүе Төхфәт абзыйның кәефен бозды. Дөрес, ул бер генә сүз белән дә безгә каршылык күрсәтмәде. Әмма үзен тотуыннан, күңелсез йөрүеннән безнең кушылуыбызга каршы килүен белеп була иде. Туйда да ул үзен әллә ничек бик сәер тотты. Башта — гадәттән тыш күп эчте, хәтта биеп тә алды, ә соңыннан — «Белмисез! Белмисез бит!» — дип үксеп-үксеп еларга кереште. «Нәрсәне белмибез?» — дип сорауга каршы, ул бер сүз дә эндәшмәде. Бу хәл, әлбәттә, Сылуда да, миндә дә авыр яра калдырды.

Төхфәт абзыйның мине чит күргәнсыман йөрүе без Казаннан киткәндә аеруча нык сизелде. Иң элек ул ни өчендер (хәзер аңлыйм ни өчен икәнен) икәвебезнең дә Казанда калуыбызны теләде. Бу хәл мөмкин булмагач, Сылуның гына калуын үтенде. Хәзер аңлыйм, Сылу аңа бик каты әйтте:

— Син бала түгел, әткәй, аңларга тиеш: гомер буе бергә торып булмый лабаса. Синң күнелсез дип, иремнән аерылыйммыни? Яшең әллә ни зур түгел — тот та өйлән. Туеңа безне дә чакырырсың.

Бу сүзләрне ишетүгә, Төхфәт абзый чыгып ук китте. «Әллә чынлап та каласыңмы», — дип, мин дә Сылу белән сөйләшеп карадым. Ләкин һичнәрсә ярдәм итмәде: без Казаннан күчеп киттек.

Менә ярты ел инде без С. шәһәрендә торабыз. Сылу да, мин дә Н. институтында лабораториядә эшлибез. Безнең күңелле тормышыбызны Төхфәт абзыйдан хатлар килмәү генә боза иде. Сылуның борчылып йөргәнен күргәч: «Гаҗәп үзсүзле ата булып чыкты бу»,—дип, Төхфәт абзый турында ни генә уйламадым мин. Ялгышканмын икән. Безнең хатларга каршы аның: «Исән. Минем турыда кайгырмагыз. Сәлам»,—дип кыска телеграммалары гына килде.

Инде менә минем исемемә язылган озын хаты алынды. Бу хат минем күзләремне ачты. Төхфәт абзый янына тизрәк кайтасы килә башлады. Күз яше белән язылган хатны мин кат-кат укып чыктым һәм укыган саен: «Юк, Сылуга моны күрсәтергә ярамый»,— дигән фикергә киләм.

Менә нәрсә яза Сылуның этисе:

«Гариф!

Бу хатны син иң элек үзең генә укып чык. Тик шуннан соң гына аны Сылуга күрсәтү-күрсәтмәү мәсьәләсен хәл кыл. Анысы синең үз ихтыярыңда. Ә минемчә, күрсәтмәү яхшы. Белмәсен.

Сиңа язарга керешер алдыннан мин бик озак уйладым. Хатымны мин мең башлап, мең ерттым. Җилгән хатларыгызга җавап язмавымның да сәбәбе шул. Сезнең хатларда сораулар күп була. Ә сорауларга җавап бирү өчен — я ялганларга кирәк, я дөресен язарга. Ялганларга — намусым кушмады, ә чынын язарга — булдыра алмадым. Сылуны газаплыйсым килмәде.

Мин авыру. Курыкма, Гариф, минем авыруым я үлем, я савыгу белән хәл кылына торган авыру түгел. Мин йөрим, эшлим, укыйм. Ләкин нервларым бернәрсәгә дә ярамыйлар. Юк кына әйбер дә миңа бик тиз тәэсир итә. Кинокартина яки театр караганда күз керфекләрем чылананалар, бугазга төен тыгыла. Салкын канлылык кирәк урында калтырана башлыйм һәм бик еш бөтенләй гаепсез кешене каты сүз әйтеп рәнҗетәм.

Ни өчен бу болай диярсең.

Кеше гомерендә үлгәнче онытылмый торган вакыйгалар була. Кайчагында алар, сине бөтенләй үз тәэсирләренә алып, газап утына ташлыйлар.

Үткәнне онытуы кыен.

Аңлашылсын өчен, мин сиңа башымнан үткән бер хәлне язарга телим. Мин бер ярлы крестьян баласы. Әби-бабайлар һәм әти-әниләр миңа тау кадәр өметләр баглаганнар. Мине зирәк, акыллы бала дип йөргәннәр. «Безнең семьядан гыйлем кешесе чыкмасмы»,—дип, әткәй мине мәктәпкә йөрткән. Ләкин мохтаҗлык миңа, авыл мәктәбен бетергәннән соң, калага китеп укырга мөмкинлек бирмәде. Мин авылда калдым. Шулай да, китапка булган мәхәббәтемне ташламадым: җае чыккан саен укыштыргалый тордым.

Октябрьның беренче көннәрендә үк, кызыл гвардиягә

язылып, дошман кыйнарга киттем. Яраланып госпитальгә кердем. Аннары гаскәри хезмәткә яраксыз табылып, авылга кайттым. Көрәшчеләр сафыннан чыгасым килмәде, җаным-тәнем белән дигәндәй, укырга ябыштым. Яшьтән яратып йөргән Җамал исемле бер кызым бар иде — шуңа өйләнү бәхетенә ирештем.

Безне икебезне дә Бөгелмәгә укытучылар курсына җибәрделәр. Төрле китаплар укуым, бала чакта ук белемгә омтылуым юкка гына булмаган. Курсларда укуы җиңел иде. Үзем белгәнне Җамалга да бирергә тырыштым. Курсларны тәмам итүгә, без җиң сызганып авылга эшләргә кайттык.

Ниләр генә эшләмәдек без! Менә дигән итеп яңа мәктәп ачтык. Культура кертәбез дип, качак бай йортыннан пианино китердек. Театр уйнадык. Газета чыгардык. Митинглар уздырдык. Авылда без — Октябрь кабызып җибәргән йолдызлар идек.

Менә шулай онытылып эшләп торганда «сәнәкчеләр» кузгалышы башланды. Иң элек алар Карабаш авылыннан килеп чыктылар. Аларга безнең авылныкылар кушылдылар.

Сәнәкләр, балталар, көрәкләр күтәргән бер төркем халык мине дә, Җамалны да, кулга алып, кыйнарга тотындылар. Салкын кыш булуга карамастан, безне, күлмәкчән генә калдырып, кыйный-кыйный урам буенча йөрттеләр. Җамалга шунда колак түзмәслек әшәке сүзләр әйттеләр. Без каршы торган саен, «сәнәкчеләр»нең котыруы арта гына барды.

— Атарга үзләрен!

— Пуля әрәм итәләрмени! Ат койрыгына бәйләп йөртәбез — яшьләргә гыйбрәт булсын!—дип кычкыра-кычкыра, безне мәчет янына алып килделәр.

Кайсыларыдыр шунда ике ат та булдырырга өлгерделәр.

Озакламый мулла өеннән өч кеше чыкты. Аларны күрүгә, котырган төркем беразга тынды. Арадан берсе кычкырды:

— Туктагыз, койрыкка бәйләми торыгыз! Начальникның әмерен көтик.

«Сәнәкчеләр» янына мулланың дәү улы Фатих килеп басты һәм, «начальник» кыяфәтен алып, әмер бирде:

— Вакыт әрәм итеп тормагыз! Бәкегә илтеп ташлагыз үзләрен! Хәзер мин дә барып житәрмен.

«Начальник» Фатихның энесе Сөләйман безнең белән бергә курсларда укыды. Ул да намуслы совет укытучысы. Минем урында хәзер Сөләйман булса, аны да Фатих бәкегә ташларга кушар идеме икән дип уйладым мин һәм Җамалга карадым: ул, бизгәк тоткан шикелле, дер-дер калтырана, бит алмалары күгәргән, маңгае буйлап кан тасмасы сузылган. Аңа ярдәм итә алмавыма мин ачына-ачына тешләремне кыстым.

Безне су буена, бәкегә таба алып киттеләр. Юлда булган өзлексез кыйнауларга Җамал түзмәде:

— Балам ятим кала!—дип кычкырып җибәрде.

Котырган этләрнең берсе, шуны гына көткәнсыман, сәнәк белән Җамалга кизәнде:

— Балаңны без, менә шушы сәнәккә кадап, ата-анасы янына, бәкегә китерербез, яме...

Бу бала — безнең бердәнбер кызыбыз — ике яшьлек Сылу иде.

Җамалга кизәнгән ерткыч хайванны мин, эченә тибеп, этеп җибәрдем — ул акыра-акыра тәгәрәп китте. Бу хәл мәктәп янында иде. Үлемнән котылу өчен иң җайлы урын шул дип, мин сөйләргә керештем. Беләм, мондый вакытта сүздән бигрәк корал кирәк, көч кирәк иде. Ләкин булмагач, нишлисең! «Бәлки Җамал котылыр», дип уйладым мин.

— Туктагыз! Нәрсә эшләвегезне беләсезме? Соң уйлап карагыз: сәнәкләр күтәреп озакмы сугыша алырсыз? — дип, башта мин сораулар бирдем. Шуннан соң кызып дәвам иттем:—Ике-өч көн дә үтмәс, кызыл гаскәр килер, һәм сез кая качарга белмәссез. Соң булмас борын, өйләрегезгә кайтып, сәнәкләрегезне яшерегез. Ә сез нишлисез, Вилдан абзый, Сәйфулла бабай? Сиңа, Мәхмүт, һәм сиңа, Әхмүш, сәнәк күтәреп чыгарга нигә кирәк булды? Кемне яклыйсыз? Кемгә каршы көрәшәсез? Кулаклар коткысына бирелдегезме? Безне үтерәмсез... Үтерегез... Ләкин белегез: Коммунистлар партиясен сәнәкләр күтәреп түгел, туплар алып килсәгез дә үтерә алмассыз. Сезнең вакытлы котыруыгызда без корбан булабыз икән... әйдә... без үлемнән курыкмыйбыз. Үзегез җәл... Корбан булган һәрбер җан өчен сезгә җавап бирергә туры килер. Я әйтегез, ни гаебебез бар безнең? Угрылыкта тоттыгызмы безне? Юк. Әшәке сүз әйтеп, кайсыгызны булса хурладыкмы? Юк. Семьягызга бозыклык керттекме? Юк. Яман атыбыз чыктымы әллә?

Юк. Соң нишләдек без? Без сезнең балаларыгызны укыттык. Сезгә без яктылык алып килдек...

Минем сүзләр халыкка яхшы тәэсир итте булса кирә, кайберәүләр инде, безгә туры карарга оялып, читкә борыла башладылар. Шул чак кулак Рәхим миңа таш ыргытты һәм төркемгә акырды:

— Җәмәгать, нәрсәгә без шуны тыңлап торабыз. Аның авызына иблис төкергән ләбаса. Сөйләргә алар бөтенесе мачтер. Клуб дигән булып, мәчеткә йөрүдән яшьләрне кем биздерде? Алар. Кара ящиклы шайтан уенын китереп, фәрештәләрне кем качырды? Алар. Гыйшык хатлары язарга кызларны кем өйрәтте? Алар. Хәзрәтне кем сүгә? Алар. Барысы да — алар. Шулай булгач, нәрсә карап торырга... тамыз берне үзенә...

Кыйный-кыйный безне бәке янына алып килделәр. Ялгыз булсам, бу кадәр кыйналуга инде мин күптән егылган булыр идем. Һушсыз калудан мине бичара Җамалның әрнеп елавы туктатып торды. Сәнәк белән чәнчүгә дә, таяклар белән кыйнауга да түздем. Әмма ерткычлар төркеменә карап акылдан шашуга житкән Җамалның вакыт-вакыт илереп җибәрүе түзәрлек түгел иде.

Ярдәм итүчеләр килеп чыкмасмы дип, без соңгы минутка кадәр түзәргә тырыштык.

Хәзер язуы да кыен. Бик авыр картиналарны кузгаттым мин, Гариф. Кыйный-кыйный мине карга батырдылар. «Соң шулай ук үләрбезмени?» дип, кардан башымны чыгардым һәм коточкыч нәрсә күрдем: Җамалны бәкегә ташлап яталар. Бу кыргыйлыкны туктатырга теләп, мин нәрсәдер кычкырам... Кемдер минем башыма тибә... Мин йөзем белән салкын карга бәреләм... тагын күтәреләм, тагын карыйм: бозлы суга чыланган Җамал бәкедән калкып чыга... куллары белән бәке кырына тотына. Вәхшиләрнең берсе:

— Ә, туңдыңмыни! Чәчеңә боз ката башладымы! — дип көлеп җибәрә һәм Җамалның бозга ябышкан бармакларын балта белән чаба.

Җамал суга төшеп китә. Минем күз алдымда аның бозга каткан бармаклары гына калалар.

Шуннан соң нәрсә булганын мин белмим. Колакта: «Монысы — этләргә, тегесе — балыкларга», дигән сүзләр генә чыңлады.

Үлемнән котылуыма мин үзем дә гаҗәпләнәм. Мине

коткарган Сәйфулла бабай болай дип аңлатты. Җамалны бәкегә ташлагач, мине үлгән инде яки барыбер үлә инде дип уйлаганнар. «Сәнәкчеләр»нең игътибары да икенче якка юнәлгән. Күрше авылдан качып барганда, безнең авылда тагын бер укытучыны тота язганнар, ләкин ул ындырларга таба йөгергән... Шул шау-шуга бәке янындагы «сәнәкчеләр» дә ашыкканнар. Минем янымда Сәйфулла бабай калган, туңа башлаган тәнемне ул кар белән ышкыган һәм якындагы бер карчыкка алып кергән.

Кулаклар кузгалышы тиз җимерелде. «Сәнәкчеләр»нең башлыклары халык суды алдына бастылар. Ләкин мин бик нык чирләдем һәм Җамалның ничек үтерелүе турында судка барып сөйли алмадым. Минем өчен Сәйфулла бабай сөйләгән диделәр.

Минем сызламаган җирем калмады. Савыккач та, Сылуны һәм әни карчыкны алып, мин Казанга киттем. Карабаш тирәсенә мәңге кайтмаска сүз бирдем. Бары тик бер генә тапкыр кайттым мин анда. Җамалның гәүдәсен эзләргә кайттым. Ике атна буена авыл суын аркылы-торкылы чыктым. Таңнан алып караңгыга кадәр һәр көн шунда булдым. Минем белән бергә бүтәннәр дә эзләштеләр. Ләкин юк, тапмадык.

Авылдан кайтып киткәндә, яныма «сәнәкчеләр»гә катнашып йөргән Мәхмүт килде.

— Кыйна син мине, Төхфәт, үтер... Бәкегә илтеп ташла... мин гаепле,—дип ялварып йөрде.

Ләкин мин Шолоховның «Күтәрелгән чирәм»ендәге Давыдов шикелле була алмадым: Мәхмүтне мин гафу итмәдем.

— Бар, йөрмә минем янымда,—дидем мин аңа.— Һәм бел, этәч батыр: ярдәм итәргә кулларыннан килеп тә, ярдәм итмәүчеләр минем караштa иң явыз кешеләр.

Еллар мине урман техникумына китерделәр. Аны тәмам иткәннән соң, мин урманга эшләргә киттем. Анда мин үземә кечкенә генә бер өй салдым. Өй тирәсенә чәчәкләр утырттым.

Шунда, саф һавада, чәчәкләр арасында Сылу үсте. Җамал һәлак булганнан соң, шәхси тормышның бердәнбер куанычы булып Сылу калганын аңлыйсыңдыр.

Миңа авыр тәэсир иткән нәрсә — Сылуның әнкәсен юксынуы булды. «Әниең үтерелде», дип балага ничек әйтәсең! Башта без аңа: «Кунакта ул, озакламый кайтыр»,—дидек. Бала көтә башлады. Йокыдан торуга

ук кайчагында: «Тизме инде әнием кайта?» — дип сорый иде. Я тәрәзә төбенә утырып, аның кайтуын көтә иде.

Газаплы булса да, бу хыялдан мин баланы котылдырырга тырыштым: «Әниең, кызым, тифтан үлде»,—дидем. Нинди сораулар яудыруын язмыйм. Бөтен игътибарымны мин Сылуны кәефле итәргә бирдем. Ничек кенә тәрбияләмәдем мин аны.

Җәй көне төрле-төрле җиләкләр җыеп ашаттым. Кышка дип көздән үк чикләвек әзерләп куя идем. Аның өчен мин мең төрле әкият уйлап чыгардым. Укырга-язарга өйрәттем. Мәктәп яшенә җиткәч, күрше авылга укырга йөрттем. Урта мәктәпне тәмам иткәч, аның өчен калага күчтем.

Сылуга мин әнкәсенең ничек үтерелүен соңыннан да сөйләмәдем: миңа охшамасын, авыр тойгылар астында үсмәсен дидем.

Җамал нәкъ Сылу иде. Хәтерлисеңдер, син үзең дә Җамалның бер рәсемен караган чагында, Сылу рәсеме дип ялгышкан идең. Сылуга мин Җамалның төсе итеп карый идем. Аның белән сөйләшкәндә, Җамалның тавышын ишеткәндәй була идем.

Инде үзең аңла: син мине кызымнан гына аермадың, Җамалның тере истәлегеннән дә аердың.

Бәке күренешләреннән соң, йөрәгем минем төзәлә алмаслык булып калды. Шулай да мин тормышны һәм хезмәтне яратам. Ләкин семья тормышыма Җамалны алмаштырырлык кеше кертә алмыйм. Сылу: «Өйлән», дигәч, минем күз алдыма нинди әйберләр килеп басканны хәзер аңлыйсыңдыр. Җамал әйтеп калдырган васыятькә дә хыянәт итәсем килми. Бервакыт ул бик нык чирләгән иде. Шунда ул миңа:

— Үлеп китсәм, Сылуны ташлама. Күз алдыңда яшәсен,—дигән иде.

Мин сине, Гариф, ят күрмим. Синең яхшы кеше икәнеңне беләм. Сылуның да синең янда бәхетле булуын аңлыйм. Ләкин минем шикелле авыру кешегә хезмәттән хезмәткә күчеп йөрүе кыен. Шуңа күрә дә үтенечемне кире какма: мине яратсаң, аз гына булса да мине бәхетле итәргә теләсәң, минем янга, Казанга кайтыгыз...»

Хатны укып чыккач та, Казанга күчерүне сорап, мин парткомга гариза бирдем. «Юкны сорама, күрәсең ич, эш муеннан, җибәрә алмыйбыз», — диделәр. Кич белән мин яңадан парткомга киттем. «Сәбәп нәрсә? Сөйләп

бир»,—дигәч, әлеге хатны укып чыктым. Хатны тыңлап бетергәннән соң, партком секретаре сузып кына: «Әй-е», — диде һәм: «Мин риза. Каршы кешеләр юкмы?» — дип сорады. Каршы чыгучы булмады.

Димәк, Казанга, Төхфәт абзый янына. Сылу да күчәргә риза. Ләкин хатны нишләтергә? Сылу белән минем арада һичкайчан ялган булганы юк. Без гел дөресен генә сөйләргә сүз куешкан идек. Ә шулай да хатны күрсәтәсе килми. Нишләргә: күрсәтимме, юкмы?

1940

ИЛҺАМ

X. иптәшкә багышлана.

Хәят Мансурова бүген уйнаячак образы турында уйланып утырганда, театр директоры килеп керде. Ул элгеч янында галошларын, бүреген, пальтосын салды һәм кулларын уа-уа залга узды. Мансурованы күрүгә:

— Киттекме, сөеклем? Мин сезне алырга дип килдем. Урамда машина көтеп тора,— диде.

— Рәхмәт илтифатыгызга!—дип, Мансурова директорга урын тәкъдим итте.— Ләкин юкка мәшәкатьләнгәнсез, иптәш Вәлиев. Хәзер чыгарга тора идем һәм ялгызым гына да бара алыр идем.

— Бара алмас идегез, Хәят ханым!—Директор, утырган урыныннан торып, идән буенча йөрергә керeште.— Әйе, бара алмас идегез!

— Ник, иптәш Вәлиев?

— Чөнки сез театр бинасы алдындагы мәхшәрне күрмәдегез әле. Халык... халык... анда — бихисап! Бүгенге спектакльгә билетлар кичә үк сатылып бетте. Ә халык кассага һаман агыла. «Ни булса, шул булыр» дип, үзем дә, администраторым да качтык.

— Нишләп алай?

— Йөдәтәләр, билет сорап йөдәтәләр. Кабинетка керсәң, әле берсе, әле икенчесе: «Дуслык хакына, зинһар, бер генә урын»,—дип телефонда шалтыраталар. Кассага чыксаң, янә шул ук хәл. Сәхнә артына керсәң: «Абыем

килгән. Сеңелем көтә»,—дип, артистлар контрамарка сорап ялваралар. Ышанмассыз: театрда мин 15 ел хезмәт итәм, әмма мондый хәлне үз гомеремдә беренче тапкыр күрәм. Әйе, сезне бүген зур уңыш көтә. Ялганлый димәгез, үз колагым белән ишеткәнне сөйлим мин. Кешеләрнең телендә бүген бары тик ике генә сүз: премьераның авторы — композитор Моратов һәм шул операда баш рольне башкаручы — артистка Мансурова.

Директор, йөрүеннән туктап, диванга утырды. «Сүзләрем ничек тәэсир итте икән?» дигәнсыман, Хәятка карады һәм тын калып җавап көтте. Ләкин Мансурова бер сүз дә эндәшмәде. Ул уйга чумган иде. Вәлиев күреп тора: әнә ул, тәрәзә алдына басып, зәңгәр күзләрен нindидер ерак бер ноктага текәгән дә уйга талган. Ни уйлый ул: сәхнәгә бүген ничек чыгуынмы? Операда җырланачак җырларның моңынмы? Әллә бүтән нәрсә борчыймы аны? Шул сорауларга җавап алырлык сүз көтте директор. Ләкин Хәят Мансурова, коеп куйган һәйкәлсыман, хәрәкәтсез иде.

Вәлиев сәгатькә карады һәм яңадан сөйләргә кереште:

— Әмма кызык та соң сәнгать эшчеләренең тормышы! Хәер, сәнгать эшчеләренең генә түгел, гомумән атаклы кешеләрнең тормышлары кызык. Әйтик, менә сезгә шаулап-гөрләп дан килә. Кешеләр үзара очрашканда: «Мансурованы бүген тыңлыйсыңмы? Билет алып куйдыңмы?»— дип, бер-берсенә сораулар бирәләр. Сезне тыңлауны кешеләр бәхеткә саныйлар. Сезне күрер өчен районнардан киләләр. Менә шундый дан килгәндә, сезгә алдынгы ишектән, парадный ишектән йөрергә кирәк иде, ә мин сезне бүген, халыктан качырып, икенче ишеккә алып барачакмын, «ялгыз да бара алыр идем» дисез. Бара алмас идегез!.. Чөнки сезне дә камап алырлар иде.

Хәятның дәшми торуына борчылган Вәлиев, диваннан торып, тәрәзә янына килде һәм акрын гына әйтте:

— Мин сезнең кәефегезне боздым, күрәсең... Сез дәшмисез...

— Һич юк, сүзегезне бүләсем килмәде. Юк, юк, ялганлыйм мин. Зинһар, гафу итегез. Сез сөйләгәндә, мин үземне сәхнәдә уйнагандай хис иттем. Шундый рәхәт иде. Киттек. Сез чыга торыгыз, мин хәзер, — дип, Хәят күрше бүлмәгә керде.

Монда ул, кулына «Әлифба» тотып утырган кызына, ерактан караганда курчактай күренгән 8 яшьлек Ләйләгә эндәште:

— Мин киттем, акыллым. Әбиеңнең сүзен яхшы тыңла. Дәресләреңә тәмам булгач та, сине ул ашатыр, эчертер һәм йокларга яткырыр. Ярыймы, кызым?

— Ярый, әнием,— дип, Ләйлә урындыкка басты, кулларын әнкәсенә таба сузды.

Хәят Ләйләне күкрәгенә кысты һәм кабат-кабат үпте. Баланың йомшак нәни куллары анның муенына сарылдылар. Ана кочагыннан аерылырга теләмәгән Ләйлә:

— Әнием, мине дә үзең белән алып бар! — диде.

— Алып бара алмыйм, кызым. Сиңа озакламый йокларга ятарга кирәк. Тиздән менә әтиең кайтыр. Сез өчәүләп залдагы диванга утырырсыз: бер якта — әтиең, икенче якта — әбекәй, ә урталарында — син, шунда мин сезгә иң яхшы җырларымны җырлармын. Сезнең өчен генә җырлармын.

— Әтием кайчан кайтыр соң? Иртәгә кайтырмы? Мин аны бик сагындым...

— Иртәгә үк түгел, ләкин тиз кайтыр, кызым. Я, сау бул. Әбекәй!—Хәят няняга таба борылды.—Ләйләне тугыз сәгатьтән дә калдырмыйча яткырырсың инде.

«Кичке почта килмәдеме» дип, коридорда Хәят ишеккә кадакланган хатлар ящигын ачты һәм:

— Хат, хат бар, Шакирымнан хат! — дип шатланып кычкыра-кычкыра машинага йөгерде.

Караңгы булганга күрә, хатны машинада укырга туры килмәде. Шулай да, Хәят түзмәде, конвертны ачып, карандаш белән язылган хатның әле бер урынын, әле икенче урынын күздән кичерде.

Театрга җитәр алдыннан, директор Хәятның уйларын бүлде.

— Әнә күрәсезме! — дип, ул театр бинасы алдында басып торган йөзләрчә халыкны күрсәтте.— Күбесе билетсыз. Ләкин премьераның беренче көнендә үк сезне тыңлыйсы килүе шулкадәр көчле ки, алар әле кимендә тагын бер сәгать шунда басып торачаклар. Бер билет өчен: «Миңа да миңа!» дип шау-шу күтәрәчәкләр. Спектакль башлангач кына кайтып китәрләр алар.

Машина театр ишеге алдына борылды. Ләкин бу юлны да кайбер тамашачылар белергә өлгергәннәр иде

инде: монда да өч-дүрт кеше басып тора иде. Арадан берсе, машинадан төшеп килгән Мансурованы күрүгә:

— Исәнмесез! Мин сезне көтә идем,— дип Хәятка эндәште.

— Ә, Мифтахов... исәнмесез! Шакирдан хат бар,— диде Хәят апа һәм директорга борылып:— иптәш Вәлиев, таныш булыгыз: Шакирның иң якын дусларыннан берсе. Үтенечен кире какмассыз шәт,— дип өстәде.

Алар сөйләшә-сөйләшә театрга керделәр.

— Гафу итегез, сөеклебез, мин киттем,— диде директор театрга кергәч.— Депутатларны каршы аласым бар. Күрәсез, Мифтахов театрда. Тыныч булыгыз: буш урын табылмаса, бер урындыкка икәү утырырбыз. Әйдәгез, иптәш!

Хәят, үз бүлмәсенә узарга дип, сәхнә артына керде.

Оркестрдан опера башлану алдындагы төрле тавышлар ишетелә. Кемдер, колакка ягымлы булган авазлар чыгарып, скрипканы көйгә сала, кемдер флейтада операның аерым урыннарын тәкрарлый. «Хәзер булам. Хәзер булам» дигәндәй, виолончель тавышы яңгырый. «Шулай, шу-лай» дигәнсыман, кемдер труба кычкырта.

Элгеч тирәсеннән һәм фойедан тамашачыларның сөйләшкән тавышлары ишетелә.

— Нәкъ җәйге урман шаулавы,— дип үзалдына сөйләнә-сөйләнә, Хәят Мансурова бүлмәгә керде.

Чишенеп тә тормыйча, хат укырга утырды ул.

«Кадерле Хәятым!

Үзеңә һәм Ләйләгә фронттан сәлам. Бу хатны мин сугышка керер алдыннан язам. Бүген сигезе. Өчендә язылган хатыңны алдым. Язуыңа караганда, тагын 5—6 көннән сезнең премьерагыз булачак. Һәм син, сандугачым, еллар буенча хыял итеп йөргән ролеңдә чыгачаксың. Янында була алмавыма, залда утырып тавышыңны тыңлый алмавыма бик борчылам. Радио аркылы операны тапшырмаслармы дип, мөмкинлек табып булса, тыңларга әзерләнәм. Уңыш казаначагыңны алдан ук сизәм һәм чын күңелдән котлыйм. Моратовның да кулын минем өчен кыс. Талантлы егет ул. Монда яман суыклар. Бүген 45 градус. Ләкин мин туңмыйм. Синең белән, балам белән татлы очрашу өмете миңа җылылык бирә. Син минем өчен кайгырма. Үзеңне сакла. Теге мин бүләк иткән мамык шәлне антракт

вакытларында арканә салырга онытма, юкса, җырлап чыгып, салкын тидерүең мөмкин.

Ләйләне бик каты итеп минем өчен кочакла һәм үп. Няняга һәм дус-ишләргә сәлам әйт.

Үбеп: Шакирың".

Хат берничә тапкыр укылды. Гримда утырганда да, өс-башын алмаштырганда да, Хәятның күзләре гел хатта иделәр. Кабат-кабат укыганнан соң, хатны ул, иң кадерле әйбер итеп, куенына салды. Ләкин хат куенда ятса да, карандаш белән язылган аерым хәрефләр һәм сүзләр күз алдында йөрүдә дәвам иттеләр.

Грим салынып беткәч, өс-башы сәхнәгә чыгарга әзер булгач, Хәят гардеробтан мамык шәлне алды һәм аны бөркәнеп, Шакиры белән шулай бергә утыруларны хәтерләде.

Колакта яңгыраган, ләкин хатны укый башлау белән һәм хатны укыганнан соң йөрәктә туган җылылык белән яңадан роль турында уйлану аркасында онытылган шаушу кинәт өзелде. Әйләнә-тирәне көчле давыл алдында була торган авыр тынлык басты. Озак та үтмәде, таң атуын хәбәр иткән быргыны хәтерләтеп, флейта тавышы ишетелде. Бу тавыш әллә кайдан, ерактан, таулар артыннан килгәндәй тоелды,'ягымлы көй, таң нурысыман сызыла-сызыла, һаман көчәя барды. «Ишеттек, ишеттек» дигән кебек, ялгыз флейта тавышына скрипкалар кушылдылар.

Бу — увертюраның башлануы иде.

Хәятның колагы музыкада, ә күңеле сугыш утына кергән Шакирында иде. Увертюрада ул үзе уйнаячак образның моңын ишетә һәм сәхнәгә кереп киткәндәй була. Авыз эченнән ул шул моңны көйли һәм Шакиры турында уйлана. Әгәр дә мөмкин булса, Хәят хәзер үк, менә шушы секундта ук Шакиры янына очып барыр иде. Аның колагына әлеге моңны көйләр иде. Шакирның исәнлеген күргәннән соң, залдагы халык алдына чыгып һичкайчан һәм һичкем тарафыннан җырланмаган җырларны җырлар иде.

Увертюраны тыңлаган минутларда Хәят Шакирны нинди генә хәлдә күз алдына китермәде. Менә ул, иптәшләре белән бергә, ял итеп утыра, Хәятның хатын укый, Хәятка җавап яза... Менә ул дошман белән йөзгә-йөз очрашу минутларын кичерә...

Оркестрдан ишетелгән барабан тавышы Хәятка туп атылуны, бомба шартлауны хәтерләтә, һәм ул, бизгәк тоткандай, калтыранып китә. Сумкасыннан ул Шакирның рәсемен чыгара һәм рәсемгә йотылып карый башлый.

Ике-өч минут эчендә аның күз алдыннан бөтен тормышы узып киткәндәй булды. Менә аның бала чагы: тугыз яшьлек ятимә Хәят әбисе янында капчыклар ямап утыра. Әнә унике яшьлек Хәят су буена йон юарга йөри. Шуннан соң язмыш аны кыргыз далаларына, җәйләүләргә алып китә. Анда ул кыргыз акыннарының моңнарын тыңлый һәм үзе дә җырлый башлый. Очы-кырые күренмәгән иркен далада җырлап үсү аның тавышына көч бирә. Кояшта янган карасу йөзле, зәңгәр күзле Хәятны чегән кызына охшаталар. Мәҗлесләр булганда акыннар Хәятның сайравын сорыйлар, аның җырларын сөеп тыңлыйлар, Хәятны мактап кымыз эчәләр.

Революция елларында Хәят Сембергә — хәзерге Ульяновскига күчә. Кичләрнең берендә Хәят урнашкан семьяга ике гаскәри килеп керә. Гаскәриләрнең берсе, яшьрәге, Шакир була. Уналты яшьлек Хәятны ул фронтка китүче кызылармеецлар өчен ясала торган концертта җыр белән чыгарга сорый. Хәят моңа риза була. Концертта аны Идел буеның яшь артисткасы Хәят Мансурова дип игълан кылалар. Фронтка китәр алдыннан, Шакир, саубуллашырга дип, яңадан Хәят янына килә. «Мин сезне мәңге онытачак түгелмен,—ди ул Хәятка.— Исән булсак, бер очрашырбыз әле. Хушыгыз!» Ләкин үзе, «хушыгыз» дисә дә, баскан урыныннан кузгалмый. «Хушыгыз, бәхетле юл сезгә!» дип, Хәят аңа кул суза.

Айлар, еллар узалар. Хәятның кайдалыгын белергә теләп, Шакир төрле җирләргә хатлар яза һәм аны ул Казанда, музыка техникумында эзләп таба. Шуннан бирле алар берсен-берсе кайгыртышып бергә яши башладылар. Хәят консерваторияне тәмам итте. Шакир шикелле яхшы иптәш, яхшы ата турында Хәятның ишеткәне дә, укыганы да юк иде. Хәят өчен ул ниләр генә эшләмәде! Шакирның вакыт-вакыт үпкәләүләре дә, дәшмичә утырулары да Хәятка хәзер ничектер бик кирәксыман тоелалар.

Залда яңгыраган көчле алкыш Хәятны сискәндереп җибәрде. Увертюра тәмам. Тагын биш минуттан соң Хәят сәхнәгә чыгачак. Алкыш һаман үсә, көчәя бара. Димәк,

халык операны яхшы кабул итә. Хәят сәхнә янына килде һәм чыгарга әзерләнде. Башта аны курку алды. Шушындый тантана белән башланган спектакльне бозмаммы, җырым халыкка житәрме дип уйлады ул. Аның күзләре сәхнә алдына куелган микрофонга төштеләр. «Шакирымның да тыңлавы мөмкин»,— диде Хәят авыз эченнән. Җанга тынычлык килде, йөрәктә җылылык урнашты. Хәят оркестрдан килгән көйләр арасыннан үз партиясенең моңын ишетте һәм, режиссер ярдәмчесенең әйтүен дә көтмичә, сихерле музыка чакыруы буенча, җилдәй атылып, җырлый-җырлый сәхнәгә керде.

Халык аны тиз таныды: сандугач сайравын хәтерләткән беренче авазлар ишетелү белән үк, бинаны яңгыратып алкыш ява башлады.

Үзенең арияләрен Хәят микрофонга якынрак торып җырларга тырышты.

Син кайда-а-а, бәгы-рем,
Мин көтә-ә-әм, беләсеңме? —

шикелле җырларны йөрәгендә булган бөтен җылылыгын, тавышында булган барлык моңын салып җырлады.

Хәятны һәр картина саен кабат-кабат сәхнәгә чакырып чыгардылар. Ул җырлаган арияләрне берничә мәртәбә тәкрарлаттылар. Тагын бер картина, соңгы картина калды. Ләкин Хәятның моңы, көче һәм дәрте һаман үсә генә барды. Тагын биш картина булса да, ул барыбер арымас иде, шул ук дәрт, шул ук хис белән, ә бәлки аннан да зуррак осталык белән тагын, тагын җырлар иде.

Сәхнәдән чыгуга, аны директор, композитор, җырчылар, сәхнә эшчеләре күтәреп алдылар.

— Котлыйбыз, Хәят ханым!

— Тамашачыларны гына түгел, сез безне дә сихерләдегез...

— Сездән алган ләззәтне аңлатырга сүз җитми,— дип, тойгыларын белдерергә ашыктылар.

Шатлыктан, җырының халыкка барып җитү куанычыннан һәм шушындый минутта үз янында Шакирын күрә алмау кайгысыннан Хәят бер сүз дә әйтә алмады. Күз яшенә чыланган керфекләрен кулъяулыгы белән сөртә-сөртә, җавап итеп, ул елмаюлы караш кына ташлый алды. Котлаучыларның кулларын кысты. Рәхмәт әйтергә теләп, иреннәрен кыймылдатты.

Ял итсен дип, аны бүлмәдә ялгызын гына калдырдылар. Бүлмәгә кемнәрдер бәйләм-бәйләм тере чәчәкләр керткәннәр. Алардан хуш ис килә.

Хәят як-якка кулларын җәеп диванга ятты. Антракт вакытларында ял итәргә өйрәнгән иде ул шулай. Аның бу гадәтен театрда барысы да белә, һәм шуңа күрә аңа берәү дә комачауламый иде. Ләкин бу юлы Хәят озак ята алмады. Ишек шакып, аңа телеграмма керттеләр.

— Берәр котлау телеграммасыдыр... өстәлгә куегыз,— диде Хәят яткан килеш.

Бер-ике минут ул: «Кайдан һәм кемнән булыр икән бу?» дип уйланып ятты. Соңгы картинада ничек уйнаячагын күз алдына китерде. Күңелгә микрофон килде. Уйлар яңадан Шакирга күчтеләр.

Хәят бер-бер артлы бирелгән ике звонокны ишетте һәм сикереп торды да, телеграмманы алып, сәхнәгә дип бүлмәдән чыгып китте.

Коридорда җырчылардан берәү: «Хәят апа, менә шулай шәпме?» — дип, аңа үзенең гримын күрсәтте һәм нәрсә турындадыр сөйләргә кереште.

Өченче звонок бирелде. Хәят, сәхнә янындагы ут яктысына килеп, телеграмманы ачты. Аның күз алды караңгыланды. Ул баскан урынында катып калды. Телеграммада: «...лейтенант Шакир Гайнетдинов дошманга каршы көрәштә батырлар үлеме белән һәлак булды...» сүзләре язылган иде.

— Хәят апа, чыгарга хәзерләнегез,— дигәндә, режиссер ярдәмчесе Мансурованың кыяфәтенә аптырады.

Хәят танымаслык хәлдә иде, мөлдерәп аккан күз яшьләре грим буявын юып бит алмаларында борылмалы сызыклар ясаганнар. Күм-күк иреннәр бизгәк тоткандагыча калтырыйлар. Матур гәүдә хәзер авам дип тора.

Спектакльне дәвам итү турында уйларга да мөмкин түгел иде. Борчылган һәм нишләргә белмәгән режиссер ярдәмчесе: «Хәят апа, сезгә ни булды?» дияргә дә өлгермәде, Хәят Мансурова чайкала-чайкала сәхнәгә кереп китте.

Бу соңгы картинада Хәят аклар тарафыннан сөекле балалары үтерелгән ананың кайгысын бирергә тиеш иде. Менә ул сәхнәдәге су буена килде. Ялгыз агачка сөялде һәм җырлый башлады. Бу җыр иге-чиге булмаган далаларны хәтерләтте, кара урманнарны күз алдына ките-

реп бастырды, кара болытлы күзге күннәрне, давыллы дингезләрне искә төшерде.

Хәят микрофонга таба берничә адым ясады. Аның көчсез адымнарына карап, дирижерны дулкынлану алды. Хәзер инде сәхнә уртасына баскан Хәят кына түгел, оркестр да елый һәм сыкрый иде.

Олуг кайгы турында сөйләгән моңлы авазлар арасында Хәят колагына каядыр чакырган быргы тавышы чагылып китте. Ул башын күтәрде, гәүдәсен турайтты, күз яшьләрен сөртә-сөртә батыр адымнар белән таучыкка менде һәм тагы да көчлерәк илһам белән, далаларга, урманнарга, дингезләргә ишеттерергә теләгәндәй, чакыру җырын башлап җибәрде. Аның дәртле тавышын ишетеп, сәхнәгә берсе артыннан берсе кешеләр җыелдылар. Хәят җырына хор кушылды. Хәят Мансурова илһамына буйсынгандай, залдагы халык аягүрә басты.

Уен тәмам булуга, атаклы артистканы котлар өчен, сәхнә артына театр җитәкчеләре һәм кунаклар керделәр. Ишек янында басып торган режиссер ярдәмчесе директор колагына нәрсәдер әйтте. Вәлиев Хәят янына керде. Ләкин озакламыйча кире чыкты һәм:

— Хәят ханым хәзер берәүне дә кабул итә алмый,— диде.— Сезгә, илтифат итеп килүегез өчен, рәхмәт белдерергә кушты һәм үз исеменнән гафу үтенүемне сорады.

1941

РӘССАМ

Юлбасарлар кулына эләккән шәһәрдә кеше бик аз калды. Халык кичә үк, дошман ыргыткан бомбалардан өйләргә ут капкач ук, ашыгыч рәвештә шәһәрдән чыгып китте.

Даны дөньяга таралган рәссам Макс Латис та китәргә хәзерләнгән иде. Аңа махсус автомобиль бирелде. Хатыны һәм баласы, кул астына эләккән төеннәрне алып, машинага кереп утырдылар. Ләкин рәссам үзенең иң кыйммәтле картиналарыннан берсен күтәреп өйдән чыкканда, каршыдагы йорт өстенә бер-бер артлы берничә бомба төште, һәм көчле янгын күтәрелде. Шәһәр өстендә дошман самолетлары ешайды. Рәссамга ашыгырга кирәк иде. Ул: «Каһәрләр!» дип күккә карады һәм китәргә кирәклекне онытты. Аның йодрыклары үзләреннән-үзлә-

ре йомарландылар, күзләрендә яшендәй ут очкыннары күренделәр. Бу минутта ул, хатынының: «Әйдә инде, утыр!» дип кабат-кабат әйтеп торуын да, баласының «Әткәй, киттек!» диюен дә ишетмәде. Күзләре яңадан ялкын эчендә калган йортка төштеләр. Шушындый минутта, бүтәннәргә ярдәм күрсәтергә кирәк чакта, шәһәрдән ашыгыч чыгып китүне ул җинаятькә санады һәм калырга булды.

Латис кулындагы картинаны машинага куйды, хатынын,-баласын үпте һәм янган йортка ишарә ясап:

— Безнең йортны да, безнең картиналарны да әнә шундый язмыш көтә. Беразын коткара алмаммы... Мин сезне куып җитәрмен. Сез ашыгыгыз! — диде.

Латис ханым иренең әкәмәтрәк табигатьле кеше булуын һәм, ялгыз калганда, аның ярдәмгә мохтаҗлыгын яхшы белә иде. Ул бит, исенә төшерүче булмаса, ашарга-эчәргә кирәклекне дә оныта, әнә хәзергедәй үзе дә сизмичә, бер аягына галош, икенче аягына ботинка киеп йөри. Ләкин Латис ханым иренең ижатка, сәнгатькә бирелгән булуын да бик яхшы белә. Аның ире иң куркынычлы минутта да сәнгатьне ташлаячак түгел иде. Шулай да, хатын аңа:

— Әйдә инде, Макс, бергә китик, — дип ялварып карады.

— Ярый, ярый. Мин озакламам, хушыгыз,—диде рәссам, һәм моннан бер генә минут элек бизгәк тоткандай калтыранган кеше хәзер, ни өчендер, елмаеп куйды. Ләкин елмаю шул ук минутта югалды да. Рәссам тагын бер тапкыр «хушыгыз» диде.

Машина кузгалып китте һәм озакламый күздән югалды.

Макс Латис янган йорт янына барып аны сүндерешүгә катнашты. Өенә кайтып керүгә, тәрәзәдән бик озак урамга карап торды. Өйдә аңардан башка бер кеше дә юк иде, ләкин ул, кемнәргәдер мөрәҗәгать иткәнсыман:

— Әнә карагыз, нәрсә калды. Кил, кызым, кара — бала табу йорты иде бу. Син дә шул йортта тудың. Гөнаһсыз бала күкрәгеннән атылып чыккан иң беренче яшәү авазыннан да кыйммәтлерәк аваз дөньяда юк, кызым. Әгәр дә мин композитор булсам, шул авазны кушып симфония язар идем. Ә фашистлар шушындый изге йортларны бомбага тоталар. Әнә тагын, тагын яна башлады.

Рәссам: «Күрәсеңме, ничек яна»,— дип артына әйләнеп карады. Янында кеше юклыкны аңлагач: «Ә... әйе, киттеләр... Ә мин ник калдым соң?» — диде һәм: «Әйе, хәтерләдем!», дип үзалдына сөйләнә-сөйләнә, буяулар алып рәсем ясарга кереште.

Аның хезмәте өчен иң кыйммәтле вакыт иртәнге һәм көндезге сәгатьләр иде. Ләкин бу турыда ул бөтенләй уйламады, чөнки дөрләп янган йортлардан төшкән яктылык аңа җитәрлек иде.

Ул төн буе һәм икенче көннең төшлегенә кадәр эшләде. Рәсем ясалып беткәнче, арыганлык аның уена да кермәде, ә иң соңгы буяу салынуга, ул үзен көчсез хис итте, хәтта басып торырлык та хәле калмады. Куе чәй булсын иде хәзер аңа! Макс, гадәтенчә, хатынын чакырды, аның озак җавап бирми торуына гаҗәпләнде. Бары тик кичәге вакыйгаларны хәтерләгәч кенә, чәйне үзенә хәзерләргә кирәклекне аңлады. Ләкин чәй эчеп тормады, урамга чыгып китте.

Төнлә белән шәһәргә фашистлар керделәр. Өзлексез талаулар башланды. Ату, кычкырып елау тавышлары ишетелде. Рәссам, тәрәзә янында торып, тавыш килгән якка карады. Кул фонарьлары яктысында карачкыл шәүләләр — фашистлар күренде. Әлеге бала табу йорты да күзгә чагылды: йорт янган, кара күмергә әйләнгән, ләкин ни гаҗәп: шул кара күмерләр уртасында — багана һәм баганада йортның вывескасы калган.

Макс Латис яңа картина янына килде һәм аны иң кадерле әйбер итеп, кая яшерергә белмичә озак вакыт аптырап йөрде. Ахыр чиктә, рәсемне ул, иске бер материя белән каплап, ишек алдына чыгарып куйды; күренмәсен өчен аны такталар һәм буш ящиклар белән каплады.

Таңда аның өенә бер офицер килеп керде.

— Кем монда хуҗа? — диде ул офицер.

— Рәссам Латис.

— Ишеткәнем бар, кая соң ул үзе? Качтымы әллә?

— Юк, качмады, семьясын озата китте, — диде Макс, гомерендә беренче тапкыр ялганлады.

— Ә син аның картиналарын сакларга калдыңмы?

Офицер, биргән соравына җавап көтмичә, түргә узды һәм стеналарга эленгән, идәндә сөялеп яткан картиналарны карарга кереште. Чит кеше өендә үзен хуҗаларча тоткан бу көтелмәгән офицерга Макс чирканып карады

һәм аңа каршы бернәрсә дә эшли алмавына үз-үзен тиргәде. Офицерның билендә хәнҗәр бар иде. Ул шул хәнҗәрен алып:

— Монсы кирәкми!

— Монсы начар!

— Монсы рюссиш!—дип, берничә картинаны буйдан-буйга кисеп чыкты һәм катып калган Латиска әмер бирде: — Калганнарын сакла. Бераздан генерал үзе кереп карар!

Офицер чыгып китте, ә Макс: «Күрдеңме, рәссам, кыргый бандит безне нишләтте!» дигәндәй, аңа күз текәгән яралы картиналарга карап алды. Туралган рәсемнәр телгә килгәндәй тоелдылар. Ул алар янына килде: «Әткәй... әнкәй... кызым... сөеклем!..» дип, рәсемнәрдә ясалган кешеләрнең йөзләреннән сыйпады. Ә рәсемнәрдәге яраланган кешеләр: «Безнең йөрәкләребез сызлый», дип кычкыралар, «Кач, рәссам, кач, сине дә алар чәнчеп үтерерләр», дип әйтәләр кебек.

Макс яраланган картиналарны нәүрәпкә чыгарды. Аннары әллә кайдан күп-күп итеп керосин табып керде, керосинны идәнгә, стеналарга һәм офицер сакларга кушкан картиналарга сибеп чыкты. Калтыранган кулларына шырпы алды, «Тукта, мин нишлим? Акылдан яздыммы әллә?» дип, нәрсә эшләвенә хисап бирергә теләде. Ләкин озак уйлап торырга вакыт юк, ашыгырга кирәк иде...

Ул шырпы кабызды һәм өйгә ут төртте...

Икенче көннең таңында күзәтче партизаннар урман авызында ярым үлек хәлдә бер гәүдә таптылар. Беренче күрүдә аны кем дияргә дә белмәделәр. Бер аягында — ботинка, икенчесендә ботинка түгел, оек та юк. Бу кеше ерак һәм куркынычлы юл узган булырга кирәк. Аның яланаягы бик нык яраланган, чиләнеп беткән, өстенә кигән күлмәге дә әллә ничә урыннан ертылган. Башында — яхшы шляпа, бер кулында — шырпы, икенче кулында — күкрәгенә кысылган хәлдә картина, искиткеч картина. Аны күрүгә, күзәтчеләр хәйран калдылар: ике этажлы җыйнак йорт ут эчендә, үрелә-үрелә җәелгән ялкын уртасында: «Укыгыз, күрегез!» дигәндәй, кычкырып торган сүзләр — «Бала табу йорты». Алтын хәрефләр белән язылган бу сүзләр йөрәккә үк барып керәләр. Алар ялкыннан да көчлеләр. Юк, алай түгел, ялкын үзе «бала» сүзеннән курыккан, оялгансыман читкә үрелә.

Югарыда — шул дәһшәтнең хуҗасы — кара свастикалы бомбардировщик очып йөри. Түбәндә ишелеп төшкән стеналар һәм алар астына кысылган ак күлмәкле хатын. Аның кулында яңа туган бала. Шәфкатьле ана, янгыннан һәм җәрәхәтләнүдән саклар өчен, баланы алга сузган. Бала илереп елый. Күлмәгенә ут капкан, гәүдәсе кысылган ана әрнеп-әрнеп нәрсәдер кычкыра. Картина астында өч сүз — ана кычкырган сүзләр булырга кирәк:

— Гитлерга мең нәләт!

Күзәтчеләр картинадан күзләрен ала алмыйча бик озак карап тордылар. Ярым үлек хәлдә яткан юл кешесен алар үзләренең штабларына алып киттеләр. Гаҗәп кешене анда бик тиз таныдылар.

Өч-дүрт партизан берьюлы:

— Латис, атаклы Макс Латис бу! — дип кычкырдылар һәм аңа ашыгыч ярдәм күрсәтергә керештеләр.

Рәссам аякка тиз басты. Отрядта врач белән шәфкать туташлары да бар иде — алар аның яраларын дәваладылар.

Латисның отрядта калырга теләве партизаннарда горурлык тудырды. Үткен күзле рәссам атарга өйрәнде һәм озакламый яхшы пулеметчы булып шөһрәт казанды. Төннәрнең берсендә ул, отряд белән бергә, шәһәргә налет ясады. Көтелмәгән бу һөҗүмнән дошман бик нык киселде. Урамнар немец солдатларының җыеп бетергесез санда үле гәүдәләре белән капланды. Хурланган кызлар, җәзаланган балалар, кабергә тереләй күмелгән картлар өчен үч алуга Латис шат иде.

Бөек иҗат һичкайчан югалмый. «Гитлерга мең нәләт» картинасы турында газета-журналларда мәкаләләр чыкты. Картина Мәскәүгә җиткәч, аны карар өчен меңнәрчә халык күргәзмәгә агылды.

Рәссамның, партизаннар белән бер сафта торып, дошманга каршы көрәш алып баруы бөтен дөньяга таралды. Аның исеменә газеталарда котлау телеграммалары басылды, радио аша сәлам хатлары укылды. Соңгы хатта түбәндәге сүзләр бар иде:

«Сөеклебез Макс!

Синең исән-сау булуың һәм сугыш кырында батырларча көрәш алып баруың безне чиксез дәрәҗәдә шатландырды. Без Н. шәһәрендә урнаштык. Өйдән алып чыккан картиналарыңны хөкүмәткә тапшырдык. Ха-

лык аларны бик ярата. «Гитлерга мең нәләт» исемле картинаңны безнең дә, мондагы халыкның да бик күрәсе килә. Изге эшеңә уңышлык телибез. Көннәрең бәхетле узсыннар. Сәламебез сиңа бетмәс көч бирсен. Дошман җиңелер, һәм без яңадан туган калабызга кайтырбыз.

Үбеп: хатының һәм балаң»

1941

ЯШЕН

— Кояшлы ял көне иде. Без, бертугандай яшәгән өч дус, таңда тордык та Идел буена балыкка киттек. Россия җәйләренең иртәнге саф һавасын татый белегез, сөеклеләрем. Йокы кая да качмас, таң белән торып, бакчага чыгыгыз, су буйларына барыгыз, кояш чыгуын котлагыз, кошлар сайравын тыңлагыз, үпкәләрегезгә таң һавасын алыгыз. Менә шунда, сөеклеләрем, яшәүнең никадәр татлы, никадәр кыйммәт икәнлеген белерсез...

— Кара әле, Давыт абый, син бит безгә Ватан сугышы һәм Яшен турында сөйләргә булган идең...

Сөйләгән чагында бүлдергәнне яратмаса да, Давыт абый бу юлы ачуланмады. «Һәр эштә, энем, түземлек кирәк. Сүзне сандугачлардан башлаганда, чыпчыктай чыркылдап утырма! Яме?» дип көлеп кенә куйды. Ул яңадан сөйләргә кереште:

— Тулып яткан Иделгә җиттек һәм кармакларыбызны салдык. Дөресен әйтергә кирәк, балык тоту сылтау гына иде. Куләгәдә ятып, зәңгәр күккә һәм Иделгә карап, дусларча гәпләшәсе килгән иде. Башта бик шәп чирткән балык та бер-ике сәгатьтән соң кабудан туктады. Без, уха пешереп, мәҗлес кордык. Банкетларың, туйларың бер читтә торсын! Бу мәҗлес шундый мәҗлес иде ки, андый кадерле сәгатьләр турында бабайлар «бер утыру— бер гомер» дигәннәр.Нәрсәләр турында гына сөйләшмәдек без! Баштан кичкән хәлләр дисезме, якты киләчәк дисезме, татлы уйлар, хыяллар дисезме — бөтенесе дә булды. Безнең арада фәлсәфә ярата торган Хафиз да бар иде. Яхшы кеше иде. Ватан сугышында корбан булды. Менә шул дускай Хафиз, сүз ара сүз чыгып, үлем

турында сөйли башлады. Без яхшы ук тирәнгә кереп киткәнбез, ахры, Мостафаның кинәт сүзне бүлүе безне айнытып җибәргәндәй булды. «Туктагыз әле, туктагыз,— диде ул,— ни дип соң без үлем турында сөйләшеп, борыннарыбызны салып утырабыз. Яшәү, яшәү турында сөйләргә кирәк, дускайларым!»

Җылы яңгыр сибәләп узган иде. Яңгыр туктагач, яңадан кояш чыкты. Әйләнә-тирәдә ямь-яшел ашлыклар, үсемлекләр иркен сулыш алдылар һәм «Эх!» дигәндәй селкенеп куйдылар; алар энҗедәй яңгыр бөртекләрен ялтыратып кояшка елмайдылар. Иделдән салкынча җил исте. Борынга хуш ис бәрелде. Чынлап та, шушындый матурлык кочагында ятканда үлем турында сөйләшү — мәгънәсез генә түгел, әллә ничек ясалма да чыга кебек тоелды.

Мостафа янында үзеңне тыныч хис итәсең. Ул бервакытта да кәефсезләнә белми иде. Әллә инде кәефсезләнсә дә, чирем кешегә йокмасын дигәндәй, безгә сиздермичә йөри иде. Яшәү турында сөйләп, ул безнен рухыбызны күтәрде. Теле яки күр тавышы гына түгел, аның имәндәй нык таза гәүдәсе дә, янып торган зур күзләре дә, эчке сәламәтлеген күрсәткән бит алмаларының сафлыгы да бер генә нәрсә турында — яшәү турында гына сөйлиләр иде.

— Эх! — дип, ул чалкан яткан урыныннан кузгалды.—Һәр көнең дөньяда җуелмас эз калдырып барса иде, гомереннең һәр сәгатен үлмәс сәгать итеп булса иде! — Ул кулларын күтәрде һәм, бернәрсәгә дә тотынмыйча, ләкин тотынгансыман оста хәрәкәт ясап, аягүрә калыкты.— Кайттык! — дип өстәде.

Шәһәргә без караңгы төшкәч кенә кайттык. Урамнарга житди төс кергән. Кая карама — халык, халык. Карты да, яше дә бер үк сүзне тәкрарлыйлар:

— Безнең эшебез хаклы. Дошман тар-мар ителер. Җиңү безнең якта булыр!

Тыныч илебезгә юлбасарларча һөҗүм ясаган кыргый фашистларга каршы Ватаныбызның күтәрелүен оныту кыен, сөеклеләрем.

Без, өч дус, үзара туганнарча саубуллаштык та, өчебез өч якка юл алдык. Хафиз заводка китте, ә без, Мостафа белән икәү, райвоенкоматка: ул — үз районына, мин — үз районыма.

Икенче көнне Мостафаны мин яңадан очраттым.

— Я, нихәл, киттекме?—дип сорау бирде ул.

— Киттек, — дидем мин.

Озак сөйләшеп торырга вакыт юк иде. Мин саубуллашырга дип кенә кергән идем. Мостафа йоклап яткан балаларына күрсәтте:

— Менә болар кызганыч. Кара үләт аларның татлы йокыларын бүлә, шат тормышларын, күңелле уеннарын боза. Анда, сугыш барган туфрагыбызда, балаларны ата-анасыз, ата-аналарны баласыз итә. Шундый кисәрбез, шундый кисәрбез ул каһәрләрне без — жирдә тузаны да калмас! Яшен тизлегедәй бәреп кереп, Москвада иртәнге ашны ашарга теләгән ул адәм ашаучы Гитлерга мин, Берлинга очып, төнге ашны ашатырмын! Яшеннең ни төсле икәнен шунда күрер ул...

Дошман шәфкатьсез һәм рәхимсез иде, сөеклеләрем. Корбан аз булмады. Мостафа миңа исәнлек теләде, мин — Мостафага. Без бер фронтка, бер отрядка туры килдек...

Ватан сугышы батырлар тудыра. Без барыбыз да— очучылар һәм танкистлар, флотчылар һәм артиллеристлар, атлылар һәм жәяүлеләр, кораллы һәм коралсыз партизаннар, элемтәчеләр һәм шәфкать туташлары —барыбыз да каһарманнарча көрәштек. Ләкин, сөеклеләрем, батырлардан да батыррак кешеләр була икән. Безнең фронтта сукса тимер өзәрлек Тарас Крепов дигән бер баһадир бар иде. Атака булдымы—бетте: беренче булып алга ул ташлана. Әй, турый да иде соң дошманны! Менә шулай итеп баса иде дә, немец солдатларын штыкка эләктереп, көлтә төягән шикелле, өзлексез ыргытып тора иде. Аны сафтан чыгарыр өчен дошман күп тырышты, ләкин килгән берсе егыла барды. Сугышта куркырга ярамый: кыюны пуля да алмый, кылыч та кисми. Менә нинди баһадирларны тудырды безнең Ватан сугышыбыз.

Мостафа да нәкъ шундый иде. Сугышка кергәннең беренче көнендә үк аңа «Яшен» исеме бирелде һәм бөтен фронтка аның турында легендалар таралды. Ниләр генә эшләми иде ул! Биш-алты бомбардировщикка каршы бер ялгызы сугышка чыга иде һәм кайсын куып, кайсын бәреп төшереп жиңеп кайта иде. Аның үзенең очу ысулы бар иде. Бу ысулдан аны дошман очучылары да бик

тиз белергә өлгерделәр. Яшен сугудан куркып, алар Мостафа самолетыннан качарга өйрәнделәр. Ләкин совет яшене үзенекен итә иде: көтмәгән җирдән килеп чыга да дошман самолетларының койрыкларына баса, өсләренә менеп атлана һәм бирелергә мәҗбүр итә, бирелмәсәләр — яндырып үтерә.

Кайчан йоклагандыр ул — һич хәтерләмим: көндез дә оча, төнлә дә оча. Приказ булуга һавага күтәрелер өчен, ул һәрвакыт самолеты янында гына тора иде. Хатынын, бала-чагасын сагынып, авыз эченнән гел бер көйне көйли иде.

Бервакытны безнең отрядны кайгы басты: Яшен киткән җиреннән кайтмады. Үлүенә ышанмасак та, йөрәктә әрнүле төен калды. Сугыштан базага кайткан иптәшләре командирга рапорт биргәннән соң иң беренче итеп:

— Яшен ничек? Кайтмадымы? — дип сорыйлар иде.

— Юк шул...— диюгә, барыбыз да кайгырышабыз һәм дошманны Яшен өчен дә аяусыз кыйнарга эчтән ант итәбез.

Яшен өч көннән соң сау-сәламәт кайтып төште. Сугышта аның ягулыгы беткән. Базага кайтып җитәргә мөмкинлек булмагач, ул дошман тылына «кунакка» төшкән, самолетын үлән йолкып яшергән. Партизаннар отрядына очрап, төнлә белән дошман аэродромына һөҗүм ясаган, алар анда байтак самолетларны шартлатканнар, кулга яшерен документлар төшергәннәр, һәм кыю Яшен, ягулык алып, яңадан фашистлар өере өстенә ташланган...

Карт сугышчы Давыт абый сөйләвеннән туктады. Тирәли утырган халык аның дәвам итүен көтте.

— Сугыш каты булды, сөекләләрем, байтак шәһәрләр көлгә әйләнде, кырлар, урманнар яндырылды, елгалардан кан акты. Латвия, Литва җирләрендә, Украина далаларында, Белоруссия кырларында дошман үләксәләре яттылар. Ул җирләр хәзер яңадан чәчәк аттылар. Сез генә, сезнең ата-аналарыгыз гына түгел, Көнбатыш Европа халыклары да кара үләттән азат ителделәр.

— Ул дәһшәтле дошманны ничек җиңдегез? — дип сорамыйсыз сез, чөнки нинди җавап бирүемне үзегез дә беләсез. Ә ул айларны, фашизм тар-мар ителгән айларны, мондый сорауларны күп ишетергә туры килде. Бөтен дөнья газеталары шул сораулар белән чыктылар.

Җавап бер иде: без җиндек, чөнки хаклык бездә иде; дошман юкка чыгарга тиеш иде, чөнки фашизмга каршы бөтен кешелек дөньясы күтәрелде...

Давыт абыйның бераз дәшми торуыннан файдаланып, арадан бердәү:

— Ә Яшен, батыр Яшен хәзер исәнме соң? — дип сорады.

— Минем өчен исән, — диде карт сугышчы, — мин аны үлгән дип һич тә уйлый алмыйм. Була бит ул шундый хәл: беләсең,ә ышанмыйсың; акылың ышана, ә йөрәгең — юк... Көннәрдән беркөнне безнең аэродром өстендә немец самолетлары күренделәр. Күп иде алар. Яшен, мин һәм тагын бер Хитров дигән иптәш минут эчендә һавага күтәрелдек. Маневр ясап, дошманны без 15—20 километрга читкә алып киттек. Самолетларның күбесе Яшенгә ташландылар. Ә ул, үлем элмәкләре шикелле баш әйләндергеч хәрәкәтләр ясап, дошманны әле астан, әле өстән бәрә, алдан да килеп суга, арттан да төмпәчли. Берничә самолет шунда ук янып җиргә мәтәлде, калганнары, Яшен утына түзә алмыйча, сызарга тотындылар. Без, куып җитеп, тагын берсен бәреп төшердек. Сугыш ахырына инде безнең ягулыгыбыз да, патроннарыбыз да беткән иде... Кайтырга юнәлдек. Өлкән иптәшебез буларак, Яшен безне алдан җибәрде. Хитров та, мин дә машиналарыбызны җайлап кына үз җиребезгә төшердек. Ләкин Яшен төшәргә өлгермәде, безгә, безнең өстебезгә таба очып килгән тагын бер дошман бомбардировщигы күренде.

Бу минутта базада бездән башка көч юк иде. Кыю Яшен дә шулай уйлады булса кирәк. Ул яңадан биеклеккә күтәрелде һәм туп-туры дошманга каршы китте. «Ягулыгы юк, патроннары беткән, аэродромга төшәргә мөмкин түгел, төшсә — үзе дә, без дә һәлак булачакбыз,— нишләргә уйлый соң безнең Яшенебез?» — дип, мин үземә үзем сораулар бирдем һәм, ягулык алып, дустымны коткарырга ашыктым. Немец очучысы Яшенне куругә курыкты булса кирәк: кинәт борылып, юнәлешен үзгәртте. Озакламый алар күздән югалдылар.

Вакыт кичкә таба иде. Хитров һәм мин ягулык алуны тәмамладык та кызу тизлек белән иптәшебезгә ярдәмгә күтәрелдек. Дошман аэродромына хәтле очтык без. Оста очучы Яшен — әле дә аңлый алмыйм — нинди көч, нинди ягулык белән шунда кадәр оча алган. Ләкин аны

коткарырга соң иде инде. Аның самолеты яшен тизлеге белән түбәнгә ташланды һәм, каты шартлау чыгарып, немец машиналары өстенә барып төште. Яшен суккандай, күк күкрәгәндәй булды. Әйләнә-тирәне ялтыратып ялкын күтәрелде.

Шулай, сөеклеләрем, бүтән мөмкинлек калмагач, чая Яшен безгә үлем шартлавы алып килгән немец машиналарын, үз җанын аямыйча, юкка чыгарды.

Күз алдымда булган хәл бу. Ә шулай да мин аны үлгән дип хис итә алмыйм: кайтыр төсле. Очарга өйрәнгән улы янына килеп: «Оч, улым, оч, яшендәй кыю оч»! — дияр кебек.

1941

САГЫНУ

Нәсер

Мин чит илдә матур гөлләр, хуш исле чәчәкләр исним. Ләкин күпме генә иснәмим, барыбер һава җитми, сулыш кысыла. Гүя үз илемнең энже чәчәкләре түгел, аның әреме дә бүген миңа шифа булыр иде.

Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!

Мин шаулап аккан елгалардан, тирән коелардан алып сап-салкын су эчәм. Әмма күпме эчсәм дә, сусавымны баса алмам. Мин үз илемнең борынгы Иделен, тын Донын, якты Арагвасын, шигъри Дим буйларын сагынам. Гүя бу мөкатдәс елгаларның суларын түгел, хәтфә болынлыктагы чишмәләребезнең бер йотым суын да бүген мин ширбәт итеп эчәр идем.

Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!

Мин Карпат тауларына мендем, Финляндия күлләре янында ял иттем. Ләкин Эльбрус шикелле мәһабәт, Казбек шикелле гүзәл тауларны, үз илемдәге Аккош күледәй сихри күлләрне очратмадым.

Синдәгедәй илаһи матурлык, синдәгедәй шагыйранә мәһабәтлек бер җирдә дә юк, туган ил!

Мин чит авыллар һәм чит шәһәрләр аша узам. Җиңү мине Берлинга алып бара. Чит ил балалары миңа бәйләм-бәйләм чәчәкләр сузалар, чит ил картлары миңа хәмер тәкъдим итәләр, чит ил кызлары миңа җимешләр сузып елмаялар һәм ялваралар:

— Син безне үлемнән коткардың, инде кил, чибәр егет, кунак бул, бездә кал! — диләр.

Әмма мин елмая алмыйм, чөнки хәмерләре исертми, елмаюлары җылытмый. Мин юлымда дәвам итәм. Мин газиз илемне, аның ямьле бәйрәмнәрен, аның талган аякларны да биетә торган хәмерләрен, йөрәккә җылы ергән нечкә билләрен сагынам, гөнаһсыз балаларын күргәндәй булам.

Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!

Мин горур атлыйм. Чөнки мин чит илдә әсир булып түгел, җиңүче булып йөрим. Миңа һәр йортның капкасы, һәр өйнең ишеге ачык. Ләкин берсенә дә керәсем килми минем. Мин ата-баба корган илемдәге изге йорт турында уйлыйм һәм шунда тизрәк кайтып керер өчен Берлинга ашыгам. Берлинга мин, илем белән аерылу кайгысын моннан соң һичкайчан татымас өчен чиксез ачу белән барам. Ачуым шулкадәр көчле, сагынуым шундый татлы ки, мин түзмим, җырлап җибәрәм.

Иле ямьсез, суы тәмсез,
Өйгә кайтасым килә! —

дип җырлыйм мин.

Без мәйданга керәбез. Поляк яшьләре, безне котлап, үзләренең иң матур җырларын җырлыйлар. Әмма минем күңел еракта. Мин үзебезнең Кызыл мәйданыбызны сагынам һәм туган илдән килгән хатларны укыйм. Дусларым, кардәшләрем миннән, сагынасыңмы, дип сорыйлар. Минем бугазыма төен тыгыла. Мин төенне йота-йота җавап язам:

Телеграм баганасы — олы юлга маяк ул,
Сагынасыңмы дип сорыйсыз — сагынмаган кая ул!

Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!

Сине сагынган саен, миндә көч-дәрт арта, рухым канатлана. Чит илдә йөреп, мин ачык аңладым: совет кешесе өчен үз иленнән дә изгерәк, үз иленнән дә кадерлерәк, үз иленнән дә гүзәлрәк ил дөньяда юк ул.

Сагынган саен сагынасы килә. Сагынуым шундый көчле булганга, кайтуым да ышанычлы. Кайтыр булмасам, бу кадәр сагынмас идем.

Сагындым, бик сагындым сине, изге туган ил!

1944.

ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР

БЕРЕНЧЕ ХАТ

Искәндәр!

Дусларча язылган җылы хатың өчен рәхмәт. Мин аны кат-кат укып чыктым. Бу сагыну хатыңны укыган чакта, минем күз алдымда аерылышкан көннәрдәге тар холыклы, бозык күңелле Искәндәр түгел, бәлки моннан 8 ел элек: «Сезнең чәчегез нинди йомшак, нәфис», дип килеп танышкан Искәндәр иде.

Нинди матур истәлек. Әйе, минем беренче мәхәббәтем дә, кешеләр белән аралаша башлаудан туган беренче шатлыгым да сиңа, синең белән танышу вакытына барып бәйләнә. Миндә яңа хисләр тудырган, күңел күзләремә матурлык буяулары биргән бу кадерле минутларны мин бик еш искә төшерәм. Тормышның тискәре, усал, шакшы яклары белән көрәшкәндә туңсам, арысам әгәр — шул рәхәт минутларны хәтерләп җылынам һәм көч җыям.

Исеңдәме беренче танышуыбыз?

Мин, матурлыкның нәрсә икәнен бары хыялда гына күреп, әкиятләрдән генә ишетеп килгән ятимә бер кыз, кинәт өнемдә чын матурлык диңгезенә чумдым, шатлык дулкыннарында йөзә башладым. Чынлап та, корып, саргаеп беткән яз чәчәген иң тәмле хуш исләр чыгарып торган чәчәккә әйләндерү — охшашы булмаган матурлык бит. Үземне, гомумән кешеләрне чәчәккә тиңләштерү дөрес үк булмаса да, минем хәл ул чагында шуңа бик якын иде.

Мин элекке Кузнецк өязендә, караңгы мишәр авылында — Ялгашта тудым. Минем атамның гомер-гомергә

күргәне бары биш-алты авыл булган. Ә мин — аның кызы — Мәскәүдә тордым, Ленинградта булдым, Харьков, Ташкент, Бакуларны күрдем... Мин дингездә йөздем, Кавказ тауларына мендем. Минем атам үз телен дә кирәгенчә белмәгән. Ә мин — аның кызы — татарча гына түгел, рус, немец телләрендә дә сөйләшәм. Минем атам бөтен гомерен көтүчелектә, газап-михнәт эчендә уздырган, үлгәндә дә сарыклар арасында үлгән. Ул бик еш сырхаулаган, ләкин бер генә тапкыр да докторны күрмәгән. Ә мин — Чулак Фәхри кызы — хәзер үзем доктор.

Зур тормышны чын-чынлап белү һәм шуны белгәннән соң киң сулыш алып эшләү шатлыгын, яшисе килү матурлыгын аңлату кыен. Миңа әле күптән түгел бер яна роман укырга туры килде. Бу китап миңа әйтеп бетергесез сөенеч, ләззәт бирде. Чөнки хәзер доктор булган татар кызының нәселе дә, тормыш төбеннән югарыга, язучылык дәрәҗәсенә күтәрелгән язучының нәселе кебек үк, иске заман бизгәгендә, җәфа чигү утында яшәгән нәсел.

Әйе, беренче танышуыбыз! Тәртипсез язуым өчен гафу ит, иркәм. Минем өчен тормыш хәзер шундый бай, шундый күнелле, бер әйбер турында яза башладым исә, берсе-берсеннән матур булган тойгылар, фикерләр кәгазьгә агылырга гына торалар. Менә хәзер дә үзем сиңа хат язам, үзем радио аркылы Шубертның «Язылып бетмәгән симфониясен» тыңлыйм. Бу симфониядә нинди генә авазлар юк! Акрын, бик акрын башланган музыкаль тавышлар йомшак, ягымлы күченүләр белән зур зилзиләләргә җитә... тына... тагын күтәрелә. Йөрәк тә музыкага кушылып тибә башлый. Гафу ит, Искәндәр, Шубертны тыңлап бетермичә, хатымны дәвам итә алмыйм. Янымда утырган җиде яшьлек Кадриям дә:

— Әнкәем, шундый матур музыка... ә син тыңламыйсың, — дип тора. Улым Рафаэль йоклый. Нинди тыныч йоклый ул. Рафаэль дә, синең кебек үк, учларын яңак астына куеп йоклый. Әнә ул төшендә нәрсәгәдер матур итеп елмайды. Ә без аналы-кызлы, Кадрия белән икәү, Шубертны тыңлыйбыз. Хәер, Кадрия нәрсә уйлый торгандыр — белмим. Ул бик акыллы булды. Күпне белә башлады. Шулай да бала күңелен аңламассың: я «Әткәем ник озак кайтмый?», я «Әнкәем иртәгә нәрсә китерер икән?» — дип уйлана торгандыр. Без Шубертны эндәшмичә тыңлыйбыз. Бу музыкада сагыну моңы да,

рату-яратмау тавышы да, җил-давыл да — бар да бар. Рәхәтләнеп тыңлыйм әле. Үзәк калалардан бик ерак урнашкан Әдрәс авылында Шуберт симфониясе аеруча матур яңгырый.

Шатлыклы туган илем! Шуберт, Бетховен шикелле композиторларның иң тирән моңнарын ерак авылларга ишеттерүең өчен сиңа жылы рәхмәт яусын.

Искәндәр!

Хатымны дәвам итәм.

1923 нче ел иде. Аяусыз тормыш камчысы астында төрле шәһәр, авылларны гизеп туйганнан соң, мин Казанга килеп чыктым. Казанда университет рабфагына укырга кердем. Бу рабфак ул елларны университет белән бер бинада урнашкан иде.

Беренче дәресләрне тыңлау белән үк мин бәхеттән, шатлыктан нәрсәгә тотынырга белмичә шашып йөри башладым. Рабфакка барганда да, кайтканда да бик еш:

— «Шушы урамнар, шушы коридорлар буйлап кайчандыр китап, дәфтәр тотып Ленин йөргән, шул бинада Толстой укыган. Шунда укырга дип яшь Горький хыял корган. Шул бинадан дөньяның атаклы галимнәре чыккан. Мин укый торган бүлмәләрдә аларның да тавышлары яңгыраган», — дип уйлана башладым. Рус әдәбияты буенча кергән укытучы Морозов та беренче лекциясен шул фикерләр белән башлады.

Ә кайчагында университетның ап-ак колонналарына сөялә идем дә, башым югары күтәреп:

— Иптәшләр, күрәсезме, мин нинди бәхетле... Мин — Чулак Фәхри кызы — Ленин, Толстой укыган йортта укыйм, — дип кычкырып, бик каты кычкырып җибәрәсем килә иде.

Шушындый биеклеккә ашуыма, тормышка юл табуыма мин шат идем. Ул елларны тормыш минем өчен ал да гөл генә, бөтен бәхетләр бергә, минем йөрәгемә җыелгандай тоела иде. Мин бары тик ирек, матурлык көчен генә хис иттем. Мин үземне чәчәкле бакчада күрдем. Бер сынык икмәк белән ике бәрәңге ашап, алтышар сәгать дәрес тыңларга туры килгәндә дә мин шат һәм көләч идем. Чөнки мин күзләремне киләчәкне күрергә өйрәтә башладым. Ә киләчәкне күрү, шуны күрәм дип хис итү — иң авыр минутларны да җиңел һәм күркәм итә.

Менә шунда, бәхеттән шашып рәхәттә йөргән чагымда, мин сине очраттым. Һәрбер сөю һәм сөелүнең —

«Эх, яратасы иде, сөясе... сөеләсе иде», — дип хисләр ташкан чагы була. Алмагач та, тула һәм пешә башлагач, хуш исле алмаларын җиргә ыргытып, җир белән шаяра башлый. Шомырт та чәчәк ата. Сандугачлар да сайраша. Чияләр дә, вакыты җиткәч, кызаралар, тулылыктан матураялар. Мин дә үземнең матурлык тойгыларыма тулганымны сиздем. Минем дә яратасым, яраткан кешем белән:

— Без нинди бәхетле, безгә шундый рәхәт, — дип тын беткәнче кочышасым килде.

Озак вакыт үтмәде — студентлар арасында зур кичәгә хәзерлек репетицияләре башланды. Ул елларны мин рабфакның Островский урамындагы тулай торагында тора идем. Без бер бүлмәдә биш кыз тордык. Без бишәвебез биш төрле милләттән булсак та, безнең арада булган революция туганлыгы җыр белән дә әйтеп бирә алмаслык дәрәҗәдә тирән иде.

Без күбрәк киләчәкне уйларга яратабыз. Бүгенгенең матурлыгы, киләчәкнең тагын да сокландырырлык булуы аркасында, үткән заманны күздән кичерергә бик аз вакыт кала. Ә уйлана башласаң — чәчләр агара. Элек, 17 нче елга хәтле, Казан университетының йөз еллык тарихында без бары биш-алты гына татар студенты күрәбез. Ун елга бер татар студенты да туры килми. Болары да ак сөяк нәселеннән. Ә хәзер анда ярты мең татар студенты укый.

Мин бик еш татар музыкасының, җырының акрын үсүе турында уйлаганым бар. Башка сәбәпләр белән бергә, каһәр суккан заманда рәсем ясый башласаң: «Бу рәсем теге дөньяда синнән җан сорар, бирерлек җаның булмагач, ул синең үз җаныңны алыр, рәсем ясама, ташла», — җырлый башласаң: «Җырлама, фәрештәләрне качырасың... тукта», — дип куркытканнар. Ә хәзер безнең бәхеткә, безнең шатлыкка үлчәү юк. Кичә була дигәч тә, без бөтен бүлмәбез белән анда катнашырга язылдык. Беренче репетиция ТКУ студентлары тулай торагында билгеләнде. Без барып кергәндә, син анда идең инде. Сине күрү белән үк, без синең турыда яшерен сер итеп сөйләшә башладык. «Бу кем?» дип соравыбызга, шундагы бер студент:

— Артист Искәндәр, — дип җавап бирде. Яшермим, син безнең күбебезгә ошадың. Хәтта егетләрнең матур

булу-булмауларын билгеләүдә аяклы градус булып йөргән Лиза да түзмәде, кычкырып ук:

— Нинди чибәр, үбәсе килә каһәрне,— дип куйды һәм, сине сөйләтеп карар өчен, яныңа барды. Биш-алты минуттан соң Лиза, безнең янга кайтып, синең тавышың, күзләрең, тешләрең турында сөйләде.

Әйе, син матур идең. Безнең бүлмә кызлары исә синең бу матурлыгыңны хыял буяулары белән тагын да бизәргә, бизәп баетырга тырыштылар. Син сизденме, юкмы — белмим, әмма репетицияләрдә кызларның чиктән тыш күп булулары аларның сиңа карата җылы мәхәббәт тотуларына да бәйләнгән иде. Ә репетицияләр булмаган көннәрдә, афишада синең фамилияңне күргән саен, без, актык тиеннәребезне җыеп, театрга чаба торган идек.

Сөю кешегә шатлык һәм көч бирә. Чөнки кичәгә хәзерләнеп йөргән көннәрдә, мин рәтләп йоклаган чагымны да һәм шул ук вакытта арыганлыгымны да хәтерләмим. Бу зур кичә өчен мин «Тормыш турында җыр» әзерләдем. Бу җыр минем башымда бик күптәннән бирле йөрсә дә, көен таба алмыйча җырламый тора идем. Ләкин синең йомшак мөгамәләң, зәңгәр күзләреңне тутырып елмаеп каравың миңа көч бирделәр, уйланган җырымны көйгә салдылар.

«Тормыш турындагы җыр»га мин үземдә булган бөтен иркәлегемне бирергә тырыштым. Мин аның һәрбер сүзе, һәрбер авазы турында озак-озак уйландым. Әллә күп уйлап йөргәнгә, колак төбемдә гел шул көй яңгырап торды. Бу җырда мин азатлык һәм матурлык, табигать һәм сөю турында күп кенә нәрсә әйтергә теләдем. Мин җырымның һәрбер сүзенә ачык буяу һәм тавыш яктылыгы бирергә тырыштым. Кырга чыгып, буш биналарга кереп репетицияләр ясадым. Җырланасы җырымны мин иртәнге һава җилләрендә назладым, кояш нурларында җылыттым. Минем җырымны илебезнең матурлыгы бизәде. Иртәнге завод гудоклары аңа аккордлар бирде. Хезмәтем бушка китмәде. Зал мине тиз аңлады. Минем җыр, ямь-яшел үләннәр, ал, зәңгәрсу чәчәкләр арасыннан атылып чыккан чишмә кебек, аккан саен арта, киңәя барып, диңгезгә кушылган зур елга төсен алды... Чәчәкләр арасыннан чыккан чишмә диңгезгә кушылган кебек, минем җырым да шәхес лирикасыннан, аерым кеше тойгысыннан җиңүче сыйныф лирикасына, җыр диңге-

зенә әйләнде. Мине кат-кат сәхнәгә чакырдылар. Ә мин, нишләргә белмичә, сәхнә артына чыгып, үзем тудырган җыр тәэсиреннән исереп, декорацияләр арасына кереп качтым. Шул вакыт берәү:

— Сезнең чәчегез нинди йомшак, нәфис, җылы,— диде.

Бу «берәү» — син идең. Мин, синең шулай якын булуың шатлыгыннан бернәрсә дә әйтә алмыйча, синең зәңгәр күзләреңә карадым. Йотыла-йотыла матур итеп карарга тырышканымны хәзер дә хәтерлим. Шул ук вакытта бу зур бәхеттән әллә кая качасы, чыгып китәсе килгән иде. Ләкин баскан урынымнан кузгала алмыйча тордым. Чөнки сул аяктагы оегымның сүтеге ботинкама тыгып куелган иде. Менә шул чыккан төсле тоелды. Мин аны сиңа күрсәтмәс өчен уң аягым белән капларга тырыштым.

Концерттан соң танецлар булды. Син вальска чакырдың. Танец вакытында син:

— Галия, сезгә артистка булырга кирәк... Сез үзегездә булган талантның кадерен белмисез... Мин сезне шефка алырга телим... Сез атаклы җырчы булырсыз... Сезнең җырыгыз бөтен Союзга, бөтен җир йөзенә ишетеләр... Мин сезнең кара күзләрегезне яратам... Алар әллә ничек ягымлылар... Сезнең күзләрдә мин үземне күрәм. Рөхсәт итсәгез, мин сезне озата барыр идем, — дидең. Мин шатлана-шатлана риза булдым.

Икәү бергә залдан чыгып киткәндә, мин әллә кемне эзләгәнсыман як-якка карандым. Юк, мин берәүне дә эзләмәдем, бу бары тик хатын-кыз табигатенең «күрәсезме, мин кем белән чыгам!» дип масаерга тырышуы иде. Без чыгып киткәндә, безгә таба бик күп күзләр текәлделәр. Безне озаткан күзләр арасыннан аермачык күренгәне студент Вәли Сафиуллинның кара күзләре булды. Сафиуллин мине ярата иде. Дөрес, ул үзе бу турыда миңа бервакытта да әйткәне юк. Киресенчә, ул һәрвакыт миннән качарга, миңа күренмәскә тырыша иде. Иптәшләремнең әйтүләренә караганда, аның һәр иртәкич шахмат тактасына карап уйлана-уйлана җырлый торган җыры шагыйрь Тукайдан алынган:

> Әмма ләззәтле дә соң яшерен газап, яшерен яну!
> Бар микән, белмим, моның миннән бүтән аңлаучысы? —

сүзләреннән гыйбарәт булган. Ә мин Сафиуллиннан көлеп йөрдем. Мин бу акыллы студентта, бөтен фәннәрдән

иң алда барган укучыда, хатын-кызларның байтагын сокландырган кыюлык, батырлык сыйфатларын күрмәдем. Ул күп вакытта йокымсырап йөри иде. Минем карашымда мондый йокымсыраган салмак кеше озак яши алмас, хәрәкәт яраткан заманыбыз андый кешеләрне онытыр дигән фикер туган иде. Безне озатып калган чагында да, Вәли Сафиуллинның күзләрендә әнә шул бетү, сүнү эзләре күренде.

Искәндәр!

Бу кичне син гаҗәп игътибарлы идең. Сүзләрең җылы, тавышың йомшак иде. Айлы кичтә яуган беренче кар тәңкәләрен чәчәкләргә охшатып, син сүзне киң күңелле, батыр йөрәкле, тирән хисле зур акыл ияләренә бордың. Син бу кичне байтак даһиларның үзләрен һәм аларның әсәрләрендә булган каһарманнарны телгә алдың. Бөек кешеләр турында булган сүзләрең, мине канатландырып, самолетта очырткан кебек югарыга таба күтәрделәр. Төн буе сине тыңлыйсы килде. Мин бу кичне сине култыклап барганда:

— Нинди бәхет! Мин үземнең киләчәк тормышымны күрәм. Акыллым Искәндәр, мин сине үлгәнче яратырмын, мин сиңа яхшы иптәш булырмын, — дип уйладым.

Син мине тулай торакка хәтле озаттың. Таңга хәтле янында торырга, синең белән бергә булырга теләдем.

— Бик соң инде, иртә торасы да бар, бүгенгә җитәр,—дип китәргә ашыктым. Ә үзем: «Ник киттем?»— дип үкендем.

Парадный төбенә җиткәч, син йөрәккә ятышлы гаҗәеп бер елмаю белән минем иреннәремә карадың. Ә мин оялып читкә борылдым. Син: «Галия... син нинди акыллы... бу онытылмаслык кичәнең дәвам итүен телим», — дип мине кочагыңа алдың. Бертуктаусыз үбә башладың. Минем тыным бетте. Тыштан: «Кирәкми, җитәр, нишләвең инде?» — дисәм дә, эчемнән бу беренче үбешүнең озаграк дәвам итүен теләдем. Чөнки синең үбүең шул минутта бар нәрсәдән дә өстен иде. Чөнки синең кочагың ана кочагыннан да җылырак иде. Шушындый рәхәт кочактан соң баскыч буйлап ничек менгәнемне, бүлмәгә ничек кайтып кергәнемне дә хәтерли алмыйм.

Мәхәббәт кешене матур итә. Бүлмәгә керү белән үк мин көзгегә карадым. Гомеремдә беренче тапкыр мин

үземнең йөзем-кыяфәтем белән канәгатьләндем. Шатлык кызыллыгы белән бизәлгән бит алмаларым кара күзләремнән сибелгән нурлар яктысында һәм чәчелеп төшкән бөдрә чәчләрем астында тагы да матуррак булып күренделәр.

— Мин матур..: трал-лә-лә,—дидем мин.

Хәтерлисеңме, «трал-лә-лә» дип Фатыйма Ильская бер рольдә сәхнәгә чыга иде. Мин аның шулай «трал-лә-лә» дип әйтүендә әллә нихәтле тәм табам. Анда ниндидер җылылык, матурлык бар. «Трал-лә-лә» дигәч, ничектер күңелле булып китә.

Шулай «трал-лә-лә» дип чибәрләнеп торганда, мин үземне:

«Галия, боларны бит син Искәндәр өчен эшлисең», дигән фикердә тоттым. Кинәт:

— Ә шулай булса соң?! Трал-лә-лә, — дидем дә, төнге сәгать бердә урындык алып биергә тотындым. Биеп туйгач, өстәл алдына утырып, бергә тора башлавыбызны, син талантлы артист, мин врач булып, яраткан кешеңне тирән итеп сөяргә, теләгәнчә шат яшәргә мөмкинлек биргән Советлар иленә хезмәт итүебезне уйларга керештем.

Төнге сәгать икедә бүлмәдәшләрем кайттылар. Алар өстәлгә күз төшерү белән үк:

— Оһо, эш зурга киткән икән. Хәер, зарар юк, егете чибәр, — диделәр.

Мин уйланып утыра-утыра өстәлгә җәелгән кәгазь өстен «Искәндәр», «Искәндәрем», «Искәндәрчегем» шикелле бөдрәле сүзләр белән язып тутырганмын. Әйе, бу кичне мин сине чиктән тыш дәртләнеп ярата башлаганмын. Ә Лиза, чынлап яратудан курыккан Лиза, миңа карап немец телендә Гейненең бер шигырен укыды. Иптәш кызым Фатыйма: «Бу шигырьнең русчасы да бар бит», — дип, түбәндәге юлларны декламировать итте:

Старинная сказка, но вечно
Останется новой она,
И лучше б на свет не родился
Тот, с кем она сбыться должна.

Менә шунда, гомеремдә беренче мәртәбә, мин Гейненең бу фикерләренә каршы чыктым. Дөрес, мин яшь идем әле. Ләкин әдәбият укытучыбызның дәресне күңелле итеп алып баруы аркасында, күп кенә әсәрләр белән танышырга өлгергән идем. Аннары рус теле һәм әдәбия-

ты кабинетында көтепханәче булып эшләвем дә үсүемә аз ярдәм итмәде. Мәхәббәт турында сүз чыккач, мин, үземдә булган бөтен белемемне җыеп, әлеге шигырьнең соңгы ике юлын шатлыкка, бәхеткә борып үзгәртергә теләдем. Илебез белән бергә безнең хисләребез дә үзгәрә... Без мәхәббәттән курыкмыйбыз. Безнең тойгылар тагы да баерлар, матураерлар... без матур итеп, җылы итеп яратырга өйрәнәбез, — дидем мин.

Иртәгесе көн — ял көне иде. Шунлыктан бу төнне минем белән бергә Фатыйма да йокысыз үткәрде. Без төн буе синең турында сөйләшеп чыктык. Фатыйманы онытмагансыңдыр бит. Ул соңыннан да безгә килеп йөрде, хәзер Бондюгта инженер булып эшли.

Беренче мәхәббәт яраткан кешеңне матур итеп күрсәтә. Чөнки бу төнне мин, синең турында уйлаганда, синдә бер генә дә кер, начар як күрмәдем. Тик Фатыйма гына:

— Яхшы кара, Галия, ул синең җырыңа гына гашыйк түгелме? — диде.

Икенче тапкыр кайда һәм ничек очрашу турында без сүз куешмадык. Репетицияләр дә билгеләнмәде. Ә күрешәсе килә. Шуның өстенә кичәге кадерле минутлар да өзелеп калган матур төш булып кына тоелдылар. Мин иртүк беркемгә бернәрсә әйтмичә урамга чыктым. Кабан күле буе урамына киттем. Ник? Белмим. Әллә булмаса, син сүз арасында үзеңнең шул урамда торганыңны әйткән идеңме? Шулай бугай шул. Ләкин урам — озын, йортлар — күп. «Минем бәхетем шундадыр, ул да мине уйлый торгандыр», — дип, мин тәрәзәгә күз төшердем. Әмма син күренмәдең. Бу көнне дөнья якты, көн җылы иде. Кабан күле күперенә барып, бик озак басып тордым. Миңа карап күп кенә халык үтте. Узып баручыларның берсе янындагы иптәшенә:

— Күрдеңме кошны... кашыкка салып кына йотарлык бит... Каһәр суккан җенес... Аларның һәрберсе шул... Син аларга ирек кенә бир... эләккән бер иргә тагылачаклар, — диде дә миннән ике-өч адымда туктады. Бераз карап торды. Аннары иптәшенә:

— Телисеңме, валлаһигазим, хәзер алып китәм үзен, — дип мактана-мактана сөйләшеп китте.

Юк, юк, мин гомеремдә дә андый ирләр колы булмам. Мин үземнең хисләремне чүпрәкләтмәм. Мин бер генә кешене сөяргә, бер генә кешене үбәргә телим.

Шулай уйланып торганда, янымнан ирле-хатынлы бер пар үтеп китте. Эх, кешеләр дә соң... Баруларына гына кара: берсе — алдан, икенчесе — арттан, эт белән мәче шикелле, ырылдап-мырылдап баралар. Кем белә? Бәлки, алар да беренче очрашканда гыйшык сатканнардыр, алар да, бәлки, бер-берен тизрәк күрер өчен озын төннәрне сәгатькә карап уздырганнардыр. Ә хәзер — карарга чирканыч!

Искәндәр!

Бу уйлар мине хәзер дә ташламыйлар. Менә шушы хатны язганда да:

— Соң нигә бездә матур семьялар аз? — дип сорау бирәсем килә.

Минем Маркс турында аның кызының истәлекләрен укыганым бар. Маркс һәм аның хатыны Женни иң авыр минутларда да, шәһәрдән шәһәргә куылып йөргәндә дә бер-берсен яратып, үзара ихтирам тотып, күтәренке рухта яшәгәннәр. «Капитал»ны язып, кешелек дөньясына яңа гыйлем ачкан Маркс үзенең иптәше өчен иң ягымлы, иң шигъриятле җырларны җыйган, аларны «Минем йөрәгемә» дип, аңа, сөекле дустына багышлаган. Материалист Маркс иптәшенең матурлыгы, күркәмлеге, зифалыгы белән мактанган. Ә кичләрен балалары өчен Шекспир әсәрләрен, «Небелунги» поэмаларын кат-кат укып чыгарга вакыт тапкан. Женни Маркс әсәрләрен акка күчергән, аларны массага таратырга булышкан, Маркс өчен хатлар язган. Димәк, ул Маркс белән бергә тору гына түгел, Маркс белән бергә бер йөрәк, бер хис, бер уй булып яшәгән. Дөньяда ул заманны алардан да шат, алардан да күләч һәм күнеллерәк яшәүче кеше булмаган. Ләкин бу бөек кешеләрнең төп максатлары үз бәхетләрен кайгыртудан күп югары булган. Алар кешелек дөньясын коллык богауларыннан азат итәр өчен, аны бәхетле ясар өчен яшәгәннәр. Шунсыз мин аңлаган семьяның бәхетле булуы мөмкин дә түгел.

Искәндәр!

Хатым бер-ике көн өзелеп торды. Инде дәвам итәм.

Әйе, матур семьялар да бар. Ләкин аларны күп итәсе килә. Юкса, начар семья аркасында тормышлар ватыла, кешеләр биртелә, гарип тойгылар җәмагать эшенә начар тәэсир итә. Бездә семья эшенә җиңел карап, иртә өйләнү, иртә кияүгә чыгу, ике-өч ел бергә торганнан соң, «характерлар белән килешә алмадык», дип аерылышулар бар.

Мондый бозык семьяларның иң авыр ягы эшкә һәм яшь буынга төшә. Менә сиңа 12 яшендә семья эшен кайгырта башлаган пионерка А. И. Мойкинаның хаты. Бу хат «Работница» журналында басылган:

«Барлык эшчеләрдән, эшче хатын-кызлардан һәм «Работница» журналын укып баручылардан миңа, минем әтиемне табып бирүдә ярдәм күрсәтүләрен үтенеп сорыйм. Минем әтием Мойкин Иван Петрович. Мин дөньяга тугач та, ул мине һәм әниемне ташлап качып китте. Шуннан соң аны бик тиз таптылар һәм ул ике ел әниемә булышып килде. Ләкин тагын качты. Хәзер менә ун ел инде аның кайда качып йөрүе безгә билгеле түгел. Зинһар табарга ярдәм итегез.

Пионерка А. И. Мойкина».

Семья турында уйлана алган киң күңелле кеше өчен бу документ йөрәк әрнетерлек нәрсә.

Үзем хат язам, үзем Кабан күле күперенә басып торгандагыдай уйланам. Яңадан күз алдыма шул чагымны китерәм. Күзләремне йомып, онытыла башлаган күренешләрне хәтерләргә тырышам. Әнә бер пар бара. Нинди бәхет. Бу ике кеше бер-берсенә кысылып, чит кешеләр ишетмәсен дигәндәй, нәрсә турындадыр сер итеп сөйләшеп баралар. Тукта... Әллә күзләрем саташамы? Булмас, ялгышамдыр...

Әйе, күпме генә аһ-ваһ итсәм дә, бу ике кешенең берсе син идең. Бу күренеш, дөресе — сине тану, минем иң матур уйларымны пычратты. Күпме катып торганмын, ачык хәтерләмим, ләкин шул минутта күз алдымнан нинди картиналар узганы исемдә. Әле мине үпкән эзләрең бетәргә дә өлгермәгән... инде аны, янында бара торган кызны үбәсең, кочасың төсле тоелды. Миңа сөйләгән сүзләрне аңа да сөйлисең кебек ишетелде.

Син мине күрмәдең. Ә мин сезне театр урамына хәтле озата бардым. Көлешкән чактагы кыланышларың, театр урамы чатында аның белән саубуллашуларың — синең ул вакытта ук ирләрнең бозыкларыннан икәнлегеңне күрсәттеләр.

Шуннан соң без гаҗәп озак тоелган ике атна буенча очрашмый тордык.

Мин тормышта, Искәндәр, сөйләп бетергесез кыенлыклар күрдем. Сигез яшемдә мин ата-анасыз калдым.

Тугыз яшемдә туганнарым тәрбиясенә күчеп, бала чагымны, сабый көннәремне бишек тирбәтеп үткәрдем. Әнә шуңа, шушындый авырлыклар корбаны булганга күрә, мин «Уралда гына» җырын бөтен нечкәлекләре белән бирелеп җырлыйм. Син бу җырны бик ярата идең. Сүзләрен язып җибәрүемне дә сорагансың. Мин аны кичке тынлыкта, синең Кабан күленә караган бүлмә тәрәзәләреңне ачып, моңга чумып җырларга ярата идем. Күзләреңне йом да, күз алдыңа шулай җырлавымны китер. Менә мин җырлыйм, ләкин бу юлы хат аркылы гына... Тавышымны хәтерләсәң, ишеткәндәй булырсың:

Уралда гына микән әй туфани,
Әйләнәсе алты ла чакырым.
Тауга гына менеп, ташка басып,
Еглый микән Зәлифә факырым.
Зәлифәкәй кайда? Су читендә
Су сибә лә микән бакчага?
Зәлифәкәй мескен — нихәл итсен,
Үз агасы саткачтын акчага?

Мин үксез балалар белән бергә урамда йөрдем. Хаксызга кыйналганым, гаепсезгә иң әшәке сүзләр белән сүгелгәнем бар. Ләкин болар бар да синең ялганыңны белүдән җиңелрәк иделәр.

Кайбер җиңел карашлы кешеләр арасында якын күреп йөргән иптәшенең хәленә, уйларына керә алмау, тирән тойгылар белән хисаплашмау бар. Мин моны, ихтимал, врач булганга күрә, артык дәрәҗәдә югарыга күтәреп әйтә торганмын. Чөнки үз эшен яраткан врач авыруны тиз аңлый торган сизгер күзләргә дә, ягымлы йөрәккә дә хуҗа булырга тиеш. Синең ялганың турында яза башлап әллә кая сикергәнмен. Әйтергә теләгән сүзем: кешеләр стандарт түгелләр. Бер уйда, бер фикердә йөргән кешеләр арасында да характерда, башкада аерымлык була. Герцен да бит (нинди зур кеше!) яраткан иптәше — хатыны белән икесе арасында семья фаҗигасе күтәрелгәч, исемен пычратудан курыкмыйча, шул вакыйганы матбугатта язып чыгып, дуслары хөкеменә бирә.

Синең ялганыңны сизгәннән соң, мин ябыктым, суырылдым.

Икенче очрашуыбызда мин синнән кем белән булуыңны сорадым. Син: «Күрше йортта торучы танышым», — диден. Аннары сораганны көтмичә үк: «Аның белән минем арада шикләнерлек бернәрсә дә юк», — дип шиклән-

дерерлек әйберләр сөйләдең. Яшермим, мин сиңа ышанмадым. Чөнки кешеләрнең бозык өлешендә булган әхлаксызлык аларны ялганларга өйрәтә. Ялганлау сезне кызартмый да. Сез, ирләрнең бозык өлеше, бер үк «сөям» сүзен ике-өч көн эчендә өч-дүрт кешегә әйтә аласыз. Кайбер ирләрнең семья, мәхәббәт мәсьәләсендә булган бозыклыклары шул дәрәҗәгә җитә ки, — алар ялган белән дөреслекне дә аера белми башлыйлар. «Яратам» дигән минутта сез — бозык ирләр — чын күңелдән яратам дип уйлыйсыз. Сез Гогольнең Хлестаковы шикелле үз ялганыгызга үзегез ышанасыз. Сез — ирләрнең бозык холыклы өлеше — бер кечлек хисләр, сатып алынган «бәхетле» минутлар колы булганга, озакка сузылган матурлыкны, тирән тойгыны аңлаудан бик ерак һәм түбән буласыз. Болар бар да иске заман тәрбиясеннән, хатын-кызга курчак, чәчәк итеп караудан килгән нәрсә.

Бу карашлар үткән заманда үзенең фахиш шагыйрьләрен дә тудырган иде. Андый шагыйрьләр: «Хатын-кыз — матур чәчәк, син аны хуш исле чагында, чәчәк атканда өзеп алырга тырыш, өзмәсәң үкенерсең, шиңәрләр алар...» — дип җырлаганнар иде.

Хатын-кызларның кайбер өлеше үзен шулай мактауны (ә мактау хатын-кызның байтак өлешен бик тиз буйсындыра әле), чәчәкне өзеп ташлаган шикелле, үзен үтеп барышлыйдан өздерүне матурлыкка санады һәм ирләр хөкеменә бирелде. Ялган ярату күп кенә хатын-кызны курчак итте. Ә чын ярату ире белән бергә урак урган крестьян хатынында, ата-аналары сөйгәненә бирмәгәнгә протест итеп суга ташланган кызда, иренә булышлык итеп станокка баскан, дөнья батырларын тәрбияләгән эшче-анада, ире артыннан Себергә киткән декабрист хатыннарында иде.

Казан университетында укыган чакта, мин җәмәгать эше буенча Елга аръягы эшчеләре арасына йөрдем. Анда миңа Галиәкбәр дигән бер эшчене өенә йөреп укытырга туры килде. Гаҗәп бәхетле семья иде бу. Галиәкбәр абзый революциягә хәтле Бондюгта, Алафузов заводында эшләгән. Тәүлегенә унике-ундүрт сәгать эшләгәндә дә аның семьясы ачлыкта, ялангачлыкта михнәт чиккән. Салкын барак өч баласын тереләй кабергә керткән. Ә хәзер квартирасына керсәң — чыгасың килми: коры һавалы, яп-якты өч бүлмә, ванна,

кухня. Зур улы Кызыл Армиядә командир, икенче улы— инженер-төзүче, бер кызы инженер-химик, Леруна исемле иң кече кызы музыкага өйрәнә.

Беренче баруымда Галиәкбәр абзый бер мина, бер карчыгына карап:

— Балаларың командир да инженер булгач, надан калу ничектер килешми. Нехорошо. Хәреф таный булмасмы дим. Карчыгым, самоварыңны куеп җибәрсәң, ничек булыр икән? Сабактан соң эчәсе килер бит, — дип, дәрес арасында үзенең тормышын сөйләп китте. Миннән дә сөйләтте. Мине тыңлап бетергәч, ул:

— Без икебез дә бер алмагачтан икәнбез, — диде. Ул өч ай эчендә укырга-язарга өйрәнде. Матур итеп сөя-сөя үзе белән бергә китапка хатынын да тартты. Менә шушы карт белән карчыкның, Советлар илендә яңадан яшәргән, яшьлек белән чәчәк аткан ике кешенең шатлыгын күрсәң — шаккатар идең. Хәтта тик торганда сабыйларча шаярган чаклары да еш була. Мин аларга бик тизияләштем. Алар да мине үз кызлары тик йөртә башладылар.

29 нчы елны Галиәкбәр абзыйның заводта эшләвенә утыз ел тулу уңае белән зур бәйрәме булды. Завод правлениесе аңа, кызының музыкага өйрәнүен белеп, пианино һәм тагы да башка нәрсәләр бүләк итте. Хөкүмәт Хезмәт батыры исемен биреп олылады. Бәйрәмгә картның бөтен балалары җыелдылар. Басмачыларга каршы көрәштәге батырлыклары өчен орден белән бүләкләнгән улы турында Кызыл Армия дивизиясеннән котлау хаты да килде. Клубтагы тантаналардан соң, без — Галиәкбәр абзыйның якын дуслары — аның квартирасына җыелдык. Монда татыган шатлыгымны мин хәзер дә тыныч яза алмыйм. Аннары син аны бик тиз генә аңлый да алмассын...

ИКЕНЧЕ ХАТ

Искәндәр!

Беренче хатымны сиңа җибәрмәдем.

Өзек-өзек җөмләләр белән язылган фикеремне аңлата алмыйм төсле. Әйтергә теләгән төп фикерем әйтелмичә кала кебек. Хатымны җибәрерменме, юкмы —анысын да белмим. Менә хәзер дә синең өчен түгел, үзем өчен язам, үземнең тормышым белән сөйләшкәндәй утырам.

Икенче очрашуыбызда син:

— Галия, мин сине генә яратам. Минем матур тормыш төзисем килә. Яшермим, мин бик күп хатын-кызны күрдем. Ләкин андый тормыштан туйдым. Хәзер бер генә кешене яратасым килә. Ул бер кеше — син, әйдә, бергә тора башлыйк, — дидең.

Француз язучысы Анатоль Франс яхшы ярату өчен күп яратырга кирәк дигән фикерне әйтә. Сәхнә кешесе булганга күрә, син мәхәббәттә дә репетицияләр ясадың ахры, чөнки син: «Сиңа хәтле булган гыйшыкларым сине күбрәк, тирәнрәк ярату өчен булырлар, иске танышларым онытылырлар», дигән идең. Мин ышанмадым. Чөнки ирләр үзләренең ярсып сөйгән ярларын бик тиз онытучан булалар. Ирләрнең бозык өлеше биш-алты елдан соң яраткан кешеләренең исемнәрен дә хәтерләреннән чыгаралар. Андый фахиш дон-жуаннар үзләре белгән хатын-кызларны бармак бөгеп мактана-мактана: «Полячка, маржа, еврейка, татарка, чувашка, украинка», — дип, милләт белән генә саный башлыйлар. Нинди кабахәтлек!

Мин сине, Искәндәр, артык якын күрдем. Шуңа күрә сине бу кабахәтләр арасына кертергә теләмәдем. Аннары үзең дә үзгәргән, бунтарьлыгың басыла төшкән кебек тоелдың. Без еш очраша башладык. Һәрбер очрашуыбыз матур төш шикелле үтә иде.

Башта мин бу очрашулар укуыма зарар китерер дип уйладым. Ләкин көчле ярату эшне яратуга да бәйләнгән. Сине күргән саен, мин үземдә яңа көч артканын сизә идем. Синнән кайту белән дәресләремне хәзерләргә тотынып, бик кыска вакыт эчендә иң авыр материалны бик тиз үзләштерә идем.

Илебезгә кара! Кыска вакыт эчендә аның искиткеч уңышларга ирешүе — эшчеләр сыйныфының, хезмәт ияләренең партияне, тормышны, туган илне яратулары, киләчәккә ышанулары нәтиҗәсендә булган нәрсә түгелме! Әйе, чын ярату кешене генә түгел, илне дә үстерә.

Шушындый кадерле минутлар белән матур кыш үтеп тә китте. Яз... чәчәкле яз... Мәхәббәтле яз җитте. Сирень агачлары чәчәк атты... Беренче май байраклары җилфердәде... Урам шауларга тотынды. Сандугачлар сайравы ишетелде... Бакчалардан музыка яңгырады... Май костюмнарына киенгән яшь йөрәкләр йолдызларга карап төрле телләрдә, төрле тавышта «сөям», «яратам» сүзләрен әйтә башладылар.

Бу яз минем хәтердән бик озак чыкмас. Бу язда мин рабфакны бетердем. Бу язны без бергә кушылдык.

Хәтерлисеңме, бу язны синең урамыңны су баскан иде. Кабан күле тирәсе чын-чынлап Венециягә — су шәһәренә охшап китте. Ләкин бу матурлык шәһәребезгә күп кенә зарар да китерде. (Матурлыкның да ямьсез ягы була икән.) Кешеләр урам буйлап көймәләрдә йөрергә тотындылар. Мин дә көн аралаш кичке кояш нурлары астында көймәдә, көймә булмаса, аякларымнан салып, итәкләремне җыеп, сиңа, синең бүлмәңә ашыга идем.

Очрашу кичәләре гадәткә кереп киткәнгә, син мине зур самоварыңны куеп, тәмле күчтәнәчләреңне хәзерләп көтә идең. Тора-бара оялуым да бетте. Квартира хуҗаларына да ияләштем.

Шул кичәләрнең берсендә, син миннән «Гыйшкым» көенә җырлавымны сорадың. Ярату тойгысы көчле булганга күрә ахры, мин аны бөтен тәнем, рухым белән җырладым. Шуннан соң син мине «Гыйшкым» дип кенә йөртә башладың. Бу кичәләрдә байтак матур китаплар укылды, күп кенә рольләр өйрәнелде. Мандолина белән көймәдә йөргән чаклар да исемдә әле. Спектакльләр булганда, син театрга китә идең, ә мин синең бүлмәңдә ялгыз калып, китаплардагы каһарманнар белән сөйләшә-сөйләшә синең кайтканыңны көтә идем.

Ярату миңа күп көч бирде. Синең алда кечкенә булып калмау, иптәшләрең белән очрашканда күздән югалмау өчен, мин үземнең белемемне арттырырга өйрәндем. Дәрес китапларын укып арыган сәгатьләрдә дәрестән тыш әсәрләр белән дә таныша килдем. Әдәбият, фән, техника китапларын, тарих-политика журналларын һәрвакыт күздән кичереп бардым. Иң яратып укыган китапларым — бөек кешеләрнең тәрҗемәи хәлләре һәм алар турында язылган истәлекләр иде. Хәзер дә мин аларны яратып укыйм. Син дә укы. Алар сине дөньяда ничек яшәргә, нәрсә өчен көрәшергә өйрәтерләр.

Ләкин культура югарылыгына омтылган, эшкә чумган кеше өчен вакыт җитмәве — зур бәла. Бу нәрсә, бигрәк тә, хатын-кызларның алдынгы өлеше өчен кыен хәл. Мин монда утыз яшькә җитмәс борын үз-үзләрен оныткан хатын-кызларны кертмим. Андый хатыннар, заманга иярүне ялгыш аңлап, башларына кепка, аякларына итек киеп, тәмәке тартып, ирдәүкә булырга тырышалар.

Мондый хатын-кызлар, шулай кыланып, болай да кыска булган гомерләрен тагы да кыскарталар. Андый хатын-кызларга мыек үстерәсе генә кала. Мондый типларның: «Без җәмәгать эшчесе, без совет хатын-кызлары, без мещан түгел», — дип, яссы күкрәкләренә суга-суга сөйләүләре ялган. Мин эш-белем ягыннан алдынгы ирләр белән бер югарылыкта торган, күркәм һәм сылу рус, грузин, татар, еврей, төркмән, украин, казах хатын-кызларын беләм. Коллык чадраларының ертылып ташлануына аз гына вакыт үткән булса да, эшлекле, талантлы, матур инженер, агроном, врач, профессор, эшче, колхозчы хатын-кызлар бездә хәзер искиткеч күп бит.

Яшермим, мин алдынгы совет хатыны гына түгел, гүзәл хатын булырга да теләдем. Менә шуның өчен дә мин сине театрдан кайтканда белемемне арттырып кына түгел, матурлыгымны сакларга тырышып та каршы ала идем. Син дә мине буш итмәдең. Бик еш, гримынны да сөртмичә, миңа, минем яныма, кочагыма ашыга идең.

— Нигә болай?—диюемә, син мине үбә-үбә:

— Галиям, мин бу рольне син күрсәткән төзәтмәләр белән, сине сөеп, синең турыңда уйлап, син биргән шатлык эчендә уйнадым. Бүген иптәшләр дә, таныш тамашачылар да яныма кереп кулымны кыстылар, рәхмәт диделәр. Залда яңгыраган алкыш бер миңа гына түгел, сиңа да иде. Аңладыңмы инде ни өчен мин «Гыйшкыма» чаптым? — дип җавап бирдең.

Кайбер көннәрне мин дә спектакльгә бара идем. Синең белән бергә шатлана һәм кайгыра торган идем. Синең яхшы уйнавың — минем өчен дә шатлык, синең начар уйнавың — минем өчен дә кайгы була торган иде. Ләкин син, Искәндәр, сәхнәдә генә түгел, тормышта да артист булгансың. Бу ягың белән син татар совет сәхнәсенең чын артистларыннан, алдынгы көчләреннән аерыласың. Бер язарга керешкәч, тәртип белән языйм инде.

Артистлар тормышы белән якынтын таныша башлаганда, язның соңгы айларында, мин рабфакны бетердем. Рабфакны бетергән көнне үк сиңа күчендем.

Көз көне мин Казан университетының медицина факультетына укырга кердем. Бу көзгә хәтле безнең тормыш яхшы барды. Ә көз көне иртә чәчәк аткан мәхәббәтебезнең хуш исле яфраклары арасында сары яфраклар күренә башладылар.

Иң элек син минем укырга керүемә каршы тордың.

— Артистка булырга теләмисең икән, миңа яхшы иптәш бул... Белемең болай да житәрлек... Күгәрченнәр күк гөрләшеп торыйк, укыма, — дидең.

Бу беренче бәрелешүдә синең сүзләреңдә ата-бабаларыбызның тавышлары ишетелгәндәй булды. Ләкин мин үземнең иркемне, теләгемне, киләчәгемне корбан итәрлек дәрәжәдә түгел идем. Чөнки мин, синең әмерләреңә карамастан, университетка кердем. Ә сәхнә мине кызыктыра алмады.

Шуннан соң без бер бүлмәдә бергә торсак та, сирәк, бары тик төнлә белән генә очраша торган булдык. Иртә белән мин дәрескә киткәндә, син йоклап кала идең. Ә кичләрен сине театрдан көтә-көтә мин йокыга китә идем. Чөнки син уникедә кайтасы урынга, бик еш икедә, өчтә кайтырга өйрәндең. «Гыйшкым» белән башланган матур тормышыбызның шушындый төс алуы турында мин байтак уйландым. Җимерелә башлаган семьяны ныгыту өчен «Семья дәфтәре» уйлап чыгардым. Минем уемча, без бу дәфтәргә семья эчендә булган барлык кимчелекләрне яза барырга, шуны укып төзәлергә тырышырга тиеш идек. Бу дәфтәр миндә хәзер дә саклана әле. Менә аның беренче бите:

«Искәндәр!

Хәзерге чорда да семья — җәмгыятьнең кирәкле бер ячейкасы. Семьяны буржуаларча аңлаудан арынып, яхшы совет семьясы төзергә кирәк. Быел без шушындый җаваплы эшкә керештек. Гарип семья өчен без бер-беребез алдында гына түгел, ил алдында да, балаларыбыз алдында да гаепле булачакбыз. Яхшы уйла, акыллым, чөнки начар семья эшкә зур зарар китерә.

Менә бу дәфтәр семьябызның көзгесе булсын. Семья көзгесенә карап, үзебезнең яхшы якларыбызны да, яман якларыбызны да күрик. Бәлки, бу романтикадыр. Булса соң! Минемчә, семья һәм мәхәббәт романтикасыз булмый.

Бу дәфтәргә мин үземне кызыксындырган, икәвебез өчен дә кирәк булган барлык фикерләремне, уйларымны яза барачакмын. Син аларны илтифат белән укы һәм үзең дә яз. Кайчагында тел белән әйтә алмаган сүзләрне каләм белән әйтүе җиңелрәк була. Бу дәф-

тәр үзебез өчен файда китермәгәндә дә — балаларыбызга, киләчәк буынга ата-аналарының тормышлары турында бер документ булыр. Дәфтәрдән яхшы әйбер тапсалар — җылы итеп искә алырлар, начар нәрсә күрсәләр — туйганчы көләрләр.

Галия».

«Семья дәфтәре» әнә шулай башланган иде. Ләкин син бу дәфтәргә бары бер генә тапкыр карадың. Чөнки «дәфтәр» языла башлаган елларны «мещан» сүзе бик модада иде: танец — мещанлык, духи — мещанлык, чәчәкләр — мещанлык, галстук — мещанлык... күп нәрсәне мещанлык дип «аңлаучылар» бар иде. Син дә минем дәфтәремне «мещанлык» дип пычраттың. Менә синең җавабың:

«Галия!

Бу эшең миңа ошамый. Бу чеп-чи мещанлык. Дәфтәр белән генә семья төзеп булмый. Тизрәк ташла үзен. Күз алдында тотма. Кеше-фәлән күрсә, көлкегә калырбыз. «Дәфтәр»сез дә торырбыз әле. Кеше сокланырлык тормыш кору өчен күп нәрсә кирәкми. Минем характерымны өйрәнеп бет, мине ярат, сорауларыма игътибар ит, сәхнә эшемә ярдәм күрсәт... Яхшы семья өчен шулар җитә.

Искәндәр».

Шушы язуыңнан соң, син «дәфтәргә» әйләнеп тә карамадың. Ә мин сиңа болай дип җавап биргән идем:

«Ялгышасың, акылсызым!

Бу мещанлык түгел. Бу фәкать синең куркуың гына. «Кеше күрсә, көлкегә калырбыз», имеш. Аннары, «минем характерымны өйрәнеп бет, сорауларыма игътибар ит, ярдәм күрсәт», — дигән сүзләреңне ничек аңларга? Нигә мин сине өйрәнергә тиеш тә, син мине түгел? Синең бу сүзләрең: «Миңа буйсын, миңа кол бул», — дию белән бер бит. Бу бик иске караш. Шулай ук мин синең турыда ялгыштыммыни?

Галия».

Әйе, ялгышканмын шул. Чөнки без икәвебез дә ул чакны мәхәббәтнең нәрсә икәнен аңлап җитә алмаганбыз. Көрәшчеләр семьясын, совет семьясын кору өчен табигый һәм идея сайланышыннан туган мәхәббәтнең булуы кирәк. Табигый сайланышка тышкы матурлык, тән байлыгы, сәламәтлек, төс, күз, йөз, тавыш, йөрү күркәмлеге керә. (Әлбәттә, кемгә кем ошый. Кемдә нинди зәвык.) Бу сайланышка без икебез дә җавап бирәбез. Безне башта әнә шул табигый сайланыш бәйләде дә. Без бер-беребезгә сокландык. Шуның исереклегендә икенче сайланышны, идея сайланышын, аның кирәклеген сизми калдык. Идея сайланышына тормышка, җәмгыятькә, эшкә карашның бер булуы, сәяси караш бердәмлеге керә. Шушындый ике сайланыш булмаганда, семьяда талаш, кычкырыш туа, һәр көн нервлар какшый, фаҗигаләр башлана, ата-аналар тарафыннан балалар ташлана. Дөрес, матди як та зур урын тота. Ләкин бу нәрсә баштагы ике сайланышка нык бәйләнгән була. Безнең арада идея сайланышы юк иде. Киресенчә, бу сайланыш урынына синдә, Искәндәр, бергә тора башлагач та, тышкы матурлык астына яшеренгән иске карашлар чәчәк атарга тотындылар.

Озакламый мин балага уздым. Бу хәл икенче бәрелешүгә, талашуга сәбәп булды. Башта син чыраеңны сытып ике-өч көн эндәшмичә йөрдең. Ә соңыннан, артистлык талантыңнан файдаланып, мине сөяргә, назларга, назлаган булып, аборт ясатырга киңәш бирергә тотындың, хәтта куша да башладың:

— Без әле яшь. Синең укыйсың да бар. Мин артист, мин иҗат кешесе. Бала икәвебез өчен дә тере богау булачак, — сүзләреннән, — мине яратсаң, минем белән торырга теләсәң, бала китермә! — дип куркытуга күчтең.

Әгәр дә мәрхүм Такташның «Мәхәббәт тәүбәсе»н берәр генә ел иртәрәк белгән булсам иде, мин аның түбәндәге шигырен алтын кара белән язып сиңа бүләк иткән булыр идем.

...Шулай, дустым!
Сезнең песи халкы
Балаларын ташлап китәләр,
Песи халкы гына түгел,
Этләр, аюлар да,
Кешеләр дә шулай итәләр...
Ярый әле сезнең песи малайлары
Ни булса да тере туалар,

Ә кешеләрнең күбесе,
Бала табудан куркып,
Корсакта чакта ук буалар.

Әйе, киләчәк буынны корсакта чакта буарга, аборт өстәленә ятарга мин риза булмадым. Кысыр булып яшәүдән кешеләр нинди кызык табалар соң? «Тыныч» тормышларын, «рәхәт» көннәрен бозарга теләмичә, сәламәтлекләренә зарар китереп булса да, күбесенчә ирләренең кушуы белән, гомер буена баласыз яшәгән хатынкызларны беләм мин. Алар (алар белән бергә ирләр дә) коча-коча эт асрыйлар. Эт үбеп үзләрен юаталар. Ял көннәрендә кешеләр балаларын күтәреп йөрергә чыкканда, алар этләрен җитәкләп чыгалар. Эт белән бергә йокларга яталар. Һәм шуны югары культура нечкәлегенә хисаплыйлар. Ә мин киләчәк тормышка эт түгел, батыр егет, көрәшче үстерергә теләдем. Балага узгач, мин ниләр генә уйламадым. Беренче мәртәбә үзен ана итеп хис кыла башлаган хатынның татлы хыялларын, тәмле уйларын аңлата алган кеше бармы икән!

Карынымда чакта ук мин баламны әллә кем итеп күрдем. Менә ул егерме ике яшьлек егет, инженер, сыйныфсыз җәмгыятьнең атаклы кешеләреннән берсе, Советлар иленең яшь галиме, имеш. Шул ук минутта мин аны кыз дип тә күрдем. Чибәрлегенә исең китәр. Ул рәссам, имеш. Аның картиналарында илебезнең шатлыгын, эшчәнлеген күрсәткән иң якты буяулар күзләргә рәхәтлек бирә.

Мин кыз таптым.

Бала да булгач, кыз да тугач, син әллә нишләдең. Дөрес, елмайган булдың. Хәлемне сорадың. Ләкин синең һәрбер кыланышыңнан «менә көтмәгән бәла» — дигән фикерне укып була иде.

Кайберәүләр, хатыннары бала тапкач, семьяларын ташлап качып китәләр. Син качмадың. Ләкин барлыгың белән юклыгың бер иде.

Бала туу белән семьяга бала караучы кирәк булды. Син көн саен диярлек:

— Бүген дә рольне өйрәнеп булмады. Бу шау-шуда иҗат итеп буламыни?! — дия башладың. Күңел өчен генә булса да, әллә ничә айлар буенча баланы кулыңа алып карамадың. Балага исем кушарга кирәк булгач, син теш арасыннан әче көлү белән:

— Дездемона, Розалия, Луиза, Офелия кушыйк, —

дип йөрәккә тоз салдың. Чөнки бу исемнәрне тезгән чагында синең тавышыңда, «син, бичара татар кызы, Офелияләр үстерә аласыңмыни!» — дигән каһкаһә бар иде.

Әйе, семьяда бала тавышы яңгырагач, син мине татар кызы булуым өчен дә тирги башладың. «Татар кызы матур итеп сөя белми. Татар кызы, үзендә болай да аз булган матурлыкны балага биреп, үзе буш кала» шикелле сүзләр синең төп сүзлегең булып киттеләр. Шул рәттән үк минем җәмәгать эшенә катнашып йөрүемне дә тәнкыйть итә башладың:

— Җил куып йөрисең шунда. Шайтан кушамыни сиңа әллә кемнәрне укытып йөрергә? Җыелышларга чабарга бераү дә кушмый, үзең чабасың. Миннән чибәррәкне таптың, күрәсең. Дәрестән башка җиргә йөрергә мин сиңа запрещаю, — дип бармак янадың.

Җәмәгать эшен ташлау, заман агышыннан аерылып калу, синең «запрещаю»ларыңа буйсыну минем өчен үлем белән бер булыр иде. Дөрес, мин бик күп нәрсәгә төшенеп җитә алмый идем әле. Шулай да җәмгыять хисе, җәмгыять өчен яшәү фикере синең «запрещаю»ларыңа буйсынудан өстен булырга тиеш икәнлеген мин сизгән идем инде. Минем семья, мәхәббәт турында булган карашларым да әнә шул хисне — җәмгыять өчен файдалы булу тойгысын үстерергә теләүдән туган нәрсәләр. Идея сайланышы булмау аркасында безнең семьябызның җимерелүенә дә төп сәбәп — җәмгыятькә карата мөнәсәбәтне төрлечә аңлау булды. Мин үзем моны бик соң аңладым. Һәм шуны яхшы итеп аңлагач кына, семья фаҗигасе нәтиҗәсендә туган яраларым тиз һәм җиңел төзәлделәр.

Балама мин Кадрия дип исем бирдем. Бу да сиңа ошамады.

— Кадрия-я-я... ха-ха... Кад-ри-я-я-я... — дип баланы куркыткан чакларың еш булды.

Ә минем өчен ул кадерле иде, кадерле булганга күрә Кадрия дип атадым да. Мин аның өчен төн саен биш-алты мәртәбә тора идем. Ә син, Искәндәр, минем хәлемне беләсе урынга, әллә нигә бер уянганда да:

— Кешегә тынычлык бирмисең... — дип, баланы йоклатыр өчен кухняга чыгып китәргә мәҗбүр итә идең. Шунда да мин сиңа сүз әйтмәдем. Иптәшләрең алдында:

— Дөнья кызык ул: бер генә ел элек ялгыз идем, ә хәзер — өйләнү белән — дүрт кешелек семьяны кайгыртырга туры килә.

— Кызлар бар да яхшы, тик менә начар хатыннар кайдан килә? — кебек күгәргән авыр сүзләреңне шаяруга, шаярып әйтелгән сүзгә әйләндерергә тырыша идем.

Дөрес, сиңа җиңел булмады. Ләкин син бер генә тапкыр да семьяның кытыршы яклары турында күзгә-күз карап сөйләшергә, аңлашырга теләмәдең. Тик расходның күплеге турында гына зарлана идең. Хәтта көндәлек расходка бирелгән акчаның кайда һәм ничек тотылуы турында тиененә хәтле хисап алудан да тартынмый идең. Авырга алма, Искәндәр, бергә торган чагында мин сине чыгышың, тәрбияң белән шелтәләмәдем. Инде хәзер күп нәрсәне аңлый алганнан соң, тормыш күренешләренә тикшерү ясый алганнан соң: ул елларны син бик еш атаң мәзингә охшап китә идең, дип әйтә алам. Син бит балага сөт алырга биргән акчаны да, сәдака акчасын караган шикелле, әйләндереп-әйләндереп меңкат карый идең.

Шулай да мин түздем. Чөнки бер ел эчендә берберенне аңлап матур семья кору эше җиңел түгел икәнлегенә төшенгән идем. Вакытлы кыенлыкларга карап семьяны җимерергә, Кадриямне ятим итәргә теләмәдем. Мин, бик еш: «Искәндәрнең яхшы яклары да күп, ул үзгәрер әле», — дип уйлый идем. Һәм, кулымнан килгәнчә, сине үзгәртергә тырыштым. Йомшак мөгамәлә күрсәтү, Галиәкбәр абзыйларга илтү, студентлар арасына катнаштыру, яңа китаплар уку... төрлечә тырышып карадым. Мин сиңа төшкән расходны җиңеләйтү өчен аз сәгатьләр белән генә чикләнгән ялымны төрле учреждениеләргә плакатлар, лозунглар язып үткәрдем. Бу да ярдәм итмәгәч, бала караучымны чыгарып, Кадриямне яслегә йөртә башладым.

Хәзер шуларны уйласам, үземнең түзүемә гаҗәпләнәм. Кышкы салкында, эче буранда, иртәнге сигездә бер кулыма китаплар кыстырып, икенче кулыма бала күтәреп яслегә ашыга идем. Дәрескә соңга калмас өчен, ясле белән университет арасын ун минутта үтим дип чабачаба шабыр тиргә бата идем. Син татлы йокыда кала идең. Миңа булышу түгел, — «Болай торуның ахыры булырмы, юкмы? Ашарга хәзерләмичә киткәнсең», — дип тиргәү сүзләрен генә әйтә идең.

Рәхәт чагым — ял көне була торган иде. Ял көннәрендә син бик озак йоклый идең, йокыдан торгач кырынып, сөртенеп иптәшләреңә дип чыгып китә идең дә төнге 12 гә, 1 гә хәтле кайтмый идең. Ә мин Кадриямне сөя-сөя аның көндәлеген язам, дәрестән артта калмыйча таза бала үстерүемә гаҗәпләнеп шатланам, кайчандыр синең өчен җырлаган «Гыйшкым» җырын Кадриямә җырлыйм. Минем кардәшләрем юклыкны син яхшы беләсең. Ял көннәрендә миңа бары университеттагы иптәшләрем генә киләләр иде. Кайчагында үзем Галиәкбәр абзыйларга барып чыга идем. Ләкин эчке серләремне, берәүгә дә сөйләмичә, үземдә генә тота идем. Мин аларны «Семья дәфтәре»мә, «Баламның көндәлеге»нә яза идем.

Искәндәр!

Ана мәхәббәтенең зурлыгын, тирәнлеген, җылылыгын аңлатырга көч җитми. Бу мәхәббәт шигърияттән өстен. Аны бары тик кешелек дөньясының зур акыл ияләре генә аңлата алалар. Бу турыда Ленинның ата-аналарына язган хатларында иң матур, иң шигъриятле юллар бар. Шул хатларны укып, ата-анамның иртә үлүенә бик кайгыра идем. Назсыз, иркәсез үскән сабый чагымны хәтерләп, баламны әнкәем өчен дә иркәләргә, сөяргә тырыша идем.

Эх, шул тойгыларны китап итеп язсалар иде! Революция өчен көрәштә корбан булган аналарның да иң беренче җылы сүзләре балалары турында булган. Ольга Делевская шуларның берсе. Ул 1919 нчы елны Төмәндә аклар тарафыннан кулга алына. Шуннан соң аны ярминкә мәйданында газаплап үтерәләр. Ольга Делевскаяның төрмәгә утыртылу алдыннан язган соңгы хатын татарчага тәрҗемә итеп күчерәм. Бу хат сиңа минем балага булган тирән тойгымны һәм синең тойгыга ярлы булуыңны аңларга ярдәм итәр.

Менә ул:

«Александра Николаевна!

Бу хатны мин минем кулга алынуымнан соң укырсыз дип язам. Сезгә Ирина турында кайгыртырга туры килер. Беләм, үтенмәсәм дә, сез моны эшләрсез. Мин сездән бер генә нәрсә турында үтенер идем: мин үлгәч, сез дә минем кебек үк Ирочканы иртә-кич сөегез, иркәләгез. Мин аны, ихтимал, артык назлаган-

мын. Зинһар каты сүз әйтеп ачуланмагыз. Үләр минутларымда Ирочкамны җылы итеп иркәләүче калмады дип уйлау минем өчен бик авыр булыр иде. Минем уемча, революционерка йөрәгендә Ирочкага карата да җылы мәхәббәт һәм иркәлек табылыр. Әйтергә теләгән сүзем шул гына иде. Тоныкһәм төссез сүзләр. Матур сүзләр эзләргә хәзер соң инде. Бу хис — кешенең иң тирән һәм йөрәккә иң якын хисе. Мин аны аңлата алмыйм. Үзегез сизегез дә, Иринаны сөегез.

Ольга Делевская».

Менә шушындый хатларны укып, мин семья эчендә тупаслана башлаган хисләремне матур кешеләрнең тойгылары белән бизәргә, Ольгалар өчен дә Кадриямне сөяргә, иркәләргә тырыштым. Мин баламның көндәлек дәфтәрен язудан, язылганын укудан рәхәтлек таба идем. Дәфтәрне язган чагында бик еш Ольга хаты тәэсире астында Ирочканы уйлый идем. Менә хәзер дә күзләремне йомып, күз алдыма аны, Ирочканы, бастырырга, матур итеп күрергә тырышам. Хәзер 34 нче ел. Димәк, хатның язылуына 15 ел вакыт үткән. Ирочка әнкәсеннән 4—5 яшьтә калган булса, хәзер аңа аз дигәндә 19—20 яшь булырга кирәк. Әнкәсенең хаты аның өчен иң яхшы дәрес китабы булгандыр. Бу хат Ирочкада илебезгә, илебездәге эшкә — әйтеп бетергесез мәхәббәт, дошманга — ачу тойгысы тудыргандыр.

Ирочка Делевская, син хәзер кайда? Сине күрәсем, синең белән сөйләшәсем килә.

Ирочка турында уйлау баламның көндәлеген баетты. Ләкин син, Искәндәр, бу дәфтәргә бер генә тапкыр да күз төшермәдең.

— Андый мещанлык белән шөгыльләнергә минем вакытым юк, — дип кырт кистең.

Сонга калып булса да, «Көндәлек»нең кайбер урыннары белән таныш. Безнең арабыз ерак хәзер. Ләкин Кадрия синең дә балаң бит. «Көндәлек»нең кайбер өземтәләрен уку файда китерүе мөмкин. Менә алар:

2 ай, 20 көн.

Кадриям аңлырак була башлады. Үзенә эндәшкәндә тулы елмаю белән җавап кайтара. Әле күптән түгел генә бер тавышлы итеп елый иде. Хәзер төрле авазлар

чыгарып елый. Аның сәламәт елавы мине куандыра. Тик Искәндәр генә бу елауга ачулана.

3 а й, 10 к ө н.

Кадриям мине һәм миңа еш килеп йөрүче иптәшләрне таный, таныш булмаган кешене күрсә — кашларын җыера, ачулана. Нинди шатлык! Димәк, кызымның башы эшли. Тик Искәндәргә ияләшмәве генә мине борчый. Хәер, монда бала гаепле түгел. Искәндәр үзе гаепле. Ул әле һаман да кулына алып баланы сөйгәне юк: «Егармын дип куркам», — ди.

4 а й, 24 к ө н.

Бүген ял көне. Көн буе балам белән сөйләшеп утырдым. Кич белән Галиәкбәр абзыйларга барып кайттым. Әнкәм семьясындамыни! Шундый күңелле булып китте.

Бүген Кадриягә бер букет чәчәкләр алдым. Кадрия ачык, якты, ялтыравыклы әйберләр ярата. «Бым-бым» авазларын әйтә. Шатлануын шулай белдерәме? Әллә: «Әнкәем, сиңа бик авыр, әткәй аңламаса да, мин аңлыйм... Түз, мин тиз үсәрмен һәм сиңа җиңел булыр», — дип әйтүеме?

6 а й, 20 к ө н.

Мин биегән чагында, Кадриям кычкырып көлә. Качыш уенын да белә кебек. Башын күкрәгемә куеп, өйдәге кешеләр белән качыш уйнарга ярата. Ясследә дә үзен бик яраталар. «Бер дә еламый, аяклары белән тик уйнап утыра», — диләр. Мескенем. Исән үссен генә.

7 а й, 18 к ө н.

Кадрия «әннәннә» дип әйтә башлады. Бүген (ял көне) көн буе янымда шаярып утырды. Мин стена газетасына килгән мәкалә-хәбәрләрне төзәттем, ул кечкенә көзге алып, көзге артыннан үзен табарга тырышып, бертуктаусыз сөйләнеп утырды.

10 а й, 20 к ө н.

Кадриягә тешләр чыга. Ясследә калдырганда, мине моңаеп озата. Алырга баргач, кочагыма керә, күкрәгемә кысыла. Куллары белән битләремнән сыйпый: «Әннә

у-у», ди. Уенчыклар белән аңлы рәвештә уйный. Күбрәк кәгазьләр белән уйнарга ярата.

Искәндәр бүген беренче тапкыр Кадрияне кулына алды. Ләкин нишләргә белмәгәнгә: «Улым... улым... ә улым түгел лә, кызым... ә... син бит кызым» сүзләреннән башка бернәрсә әйтә алмады. Нишләп улым дип ялгышты икән? Әллә берәр җирдә улы бармы? Йөрәк сызлый.

11 а й, 18 к ө н.

Бүген көн буе Ирочканы уйлап йөрдем. Кем белә? Бәлки, Ольга да аның көндәлеген язгандыр. Кызым Кадрия, вакыт тиз уза. Син үсәрсең, зур булырсың. Илебез шул хәтле үзгәрер ки, бер сәгать эчендә теләгән бер кешеңне табып сөйләшергә мөмкин булачак. Ирочка турында мин сиңа үземнең уйларымны яздым. Әгәр дә мин үлеп китсәм, Ирочканы эзләп тап. Минем урыныма ул сиңа ана булыр.

Б е р я ш ь.

Советлар иленең кечкенә гражданкасына бүген бер яшь тулды. Тазалыгына сокланмаган кеше юк. Чисталык һәм сәламәтлек ярышында бүләкләделәр үзен. Бүген мин аңар яңа күлмәк кигездем. Күчтәнәчләр китердем. Иптәшләр дә котларга килделәр. Тик Искәндәр генә Кадриянең туган көнен оныткан. Ул бүген төнге икедә кайтты. Күптән елаганым юк иде. Бүген еладым.

Б е р я ш ь, 2 а й.

Кадрия йөри башлады. Бик матур итеп ладошки уйный. Минем китап алып утырганымны күрсә, ул да китап сорап йөдәтә. Биргәч, рәсемнәрен карарга тотына, сөйләвемне сорый. Шырпы савыты белән уйнарга ярата: бер бушата, бер тутыра. Шырпыга охшашлы уенчыклар сатмыйлармы икән — карарга кирәк.

Б е р я ш ь, 4 а й.

Кадриям кызамык белән авырый. Ләкин куркыныч түгел — җиңел уздыра. Шулай да больницага салдым. Һәр көн янына барып йөрим. Өйдә шундый күңелсез...

Бер яшь, 5 ай.

Баламны больницадан алдым. Хәле яхшы. Бик көчләнеп кенә качыш уенын уйнады. Шундый сагынган үземне: көн буе итәгемдә утырды. Ләкин Искәндәр Кадрия авырган чагында һич пошынмады төсле. Ул артык мәшәкатьтән котылу өчен, ихтимал, баласының үлүен дә теләгәндер. Бар бит шундый аталар. Китегез, таралыгыз юләр фикерләр!

Тагын Ирочканы уйладым. Аны да сөясе килде.

Бер яшь, 9 ай.

Кичә Кадрияне демонстрациягә алып чыктым. Кулына кечкенә кызыл флаг тоттырдым. Башта халыкның күплегенә, музыка тавышына аптырады булса кирәк — дәшми йөрде. Тора-бара ияләште. Флагын күтәреп кычкырырга, уйнарга тотынды. Өйгә кайткач, бик озак «шулай, шулай» дип урамдагыча маршлап йөрде.

Искәндәр!

Бергә торган чагында, син бу «Көндәлек»не укырга теләмәдең. Ә хәзер хатыңда балаларның көндәлек тормышлары, ничек тәрбияләнүләре турында язуымны сорыйсың. «Миндә дә аталык хисе кузгалды», дисең. Эч пошканнан гына әйтелгән сүз түгелме бу?

Балаларым яхшы үсә. Атасыз үсүләреннән башка зарланырлык нәрсәләре юк. Авыл дигәч тә, ала торган тәрбияләре шәһәрдәгедән бер дә ким түгел. Кадриям МТС янындагы балалар бакчасына йөри. Көз көне укырга башлый. Ләкин хәзер дә бик шәп укый, яза, рәсем ясый. Бик күп җырлар белә.

Кичләрен без аның белән икәүләп җырлыйбыз. Безгә карап Рафаэль дә җырлаган булып кылана.

Үткән ел радио куйдырдым. Бу радио балаларга гына түгел, үземә дә, күршеләргә дә зур шатлык булды. Райздрав үземә ашлык җыю вакытында медицина эшләрен яхшы куюым өчен патефон бүләк итте. Ул хәзер тулысынча Кадрия иркендә. Көзгә пианино алырга уйлыйм.

Искәндәр!

Хатыңны син бик нечкә, әйтергә яраса, бик төче язгансың. Ләкин аерылышкан минутлардагы чыраең һаман күз алдымда тора. Рафаэль тугач, нинди тамаша ясаганыңны хәтерлисеңме? Аны онытуы кыен. Син бит

больницага мине каршы алырга да бармадың. Иптәшләремнең ярдәме белән кайтырга туры килде.

Француз халкында гаҗәп яхшы бер мәкаль бар. Бу мәкальне болай тәрҗемә итәргә мөмкин: «Кеше үзенә күрергә туры килми торган кайгыларны, фаҗигаләрне кайгыртып картая, газап чигә». Син дә юкны, булмый торган нәрсәләрне була дип пошына идең бит. — Бу ике баланы ничек тәрбияләрмен, артистлык талантым бетсә нишләрмен, — дип уйламый идеңме? Син киләчәктән курка торган кеше түгел идеңме? Әйт, Искәндәр, сине нәрсә борчыды? Бәлки, берәр пычракка баткан булгансың.

Мин больницадан кайтып хәл җыярга да өлгермәдем, син:

— Сиңа, Галия, артист хатыны булырга түгел, яслегә бала караучы булып кирәргә иде, — аннары бераз йомшарып, — хәер, мин сине гаепләмим, мин үзем гаепле, уйламыйча өйләнүем өчен гаепле, сәхнә кешесе һәрвакыт иректә булырга тиеш... Ә мин семья белән, балалар белән богауландым... Язмыш шулай, күрәсең. Мине яшьтән үк бәхетсез диләр иде... Дөрес сүз... Мин синең белән артык тора алмыйм... Үсмәгән балалар өчен үземне корбан итә алмыйм... Хуш... Мине эзләмә, — дидең дә ташлап чыгып киттең.

Дөрес, йөрәгемнең әллә кай почмагында сиңа карата җылы хисем бар иде әле. Шулай да мин сине туктатмадым. Син, ихтимал: «Бу елар, муеныма асылыныр, миннән башка тора алмас, чакыртыр, ялварыр», дип уйлагансың. Чөнки синең шикелле түбән кешеләр үзләренә баш июне ярата лар.

Мин ялварырга да, тезләнергә дә теләмәдем. Башта миңа бик кыен булды. Син чыгып киткәндә, минем бөтен байлыгым, шатлыгым ике балам иде. Урамда елаган чакларым булды. Бер баламны бакчага, икенчесен яслегә йөрткәндә, рухани авырлыктан, баскан урынымда катып кала идем.

Әллә укуымны ташлыйммы дип икеләнгән чакларым да булды.

Мин синнән бер тиен дә сорамадым, үзең аңлап бирмәдең. Хәер, сине хәзер театрда эшләми, киткән дип тә сөйләделәр. (Алимент түләүдән качмагансыңдыр бит?)

Мине бәладән коткаручы кешеләр университет директоры Даутов иптәш белән партком секретаре Николаев

булдылар. Галиәкбәр абзый белән студентлар коллективы да күп кенә ярдәм иттеләр. Аларның миңа күрсәткән туганлыклары сыйнфый туганлык иде. Иптәшләрем күңелсезләнергә бирмәсәләр, башкалар матди егылудан саклап калдылар.

Даутов белән Николаев иптәшләрне мин бик озак онытмам. Алар гаҗәп яхшы җитәкчеләр. Галиәкбәр абзый, минем нинди хәлдә калуымны белгәч тә, Даутовка барып сөйләгән. Алар 14—15 нче елларны Бондюг заводында бергә эшләгән булганнар. Шуннан Даутов иптәш мине үзенә чакыртып алды. Николаев та шунда иде. Нинди сизгер кешеләр — алар минем семья тормышым турында бөтенләй сорашмадылар. Ярага тоз салып әрнетергә теләмәделәр, күрәсең. Бары уку турында гына сөйләштек. Шул көннән башлап миңа йөз илле сум стипендия билгеләнде.

Галиәкбәр абзый үзе дә, хатыны да бик еш хәлемне белә башладылар. Артта калган дәресләрдән куалап җитү өчен, үземә ярдәмгә иң яхшы студентларны беркеттеләр.

Бу соңгы бер ел эчендә без бөтенләй күрешми тордык. Ахырысында институт тәмам булды (бу вакыт медицина факультеты аерым институтка әйләндерелгән иде инде). Дәүләт имтиханнарын биреп бетергәч, мин Даутов иптәшкә барып (ул башка хезмәткә күчерелгән иде), зачет книжкамны күрсәтеп, аңа һәм аның аша партиягә, хөкүмәткә рәхмәтемне белдердем.

Галиәкбәр абзыйларда институтны бетереп врач булу хәбәре зур бәйрәмгә әйләнде. Ял көне туры килгән иде. Көн буе балаларым белән шунда сыйланып, кунак булып утырдым.

Һәм бер айдан соң ике баламны күтәреп, Әдрәс районына врач булып эшләргә киттем. Китәр алдыннан Кадриям белән «Швейцария» бакчасына бардым. Анда татарча спектакль куела, спектакльдә Искәндәр катнаша дигәннәр иде. Син үзеңнең яраткан ролеңдә идең. Без сиңа күренмәс өчен бик сакланып утырдык. Кадрия сине онытмаган икән, таныды:

— Әнкәй, әтием бит бу, — диде.

— Юк, акыллым, әтиең түгел... охшаган гына... Синең әтиең еракка, бик еракка китте. Синең әтиең хәзер артист түгел инде, — дидем мин.

Спектакльгә бару сиңа соңгы сәлам калдыру иде.

Син миңа күпме генә газап-михнәт китерсәң дә, миндәге йомшаклык һаман үзенекен итә килде. Казаннан киткәндә, ничектер, күңелсез тоелды. Пароход кузгалгач, Ольга Ковалеваның яратып җырлаган:

...Люди добрые, поверьте,
Помню, что было.
Расставание хуже смерти:
Его я не забыла...—

дигән җырын җырладым. Ләкин бик тиз:

— Җитәр, Галия, ташла... Искәндәр сиңа тормый,— дип, үземне кулга алдым да, башымны югары күтәреп, алга, күп кайгы күргән Иделнең тынычлыгына карадым.

ӨЧЕНЧЕ ХАТ

Искәндәр!

Мин сиңа моннан ике атна элек ике хат язган идем. Ләкин җибәрмичә калдым. Менә бу хатым белән бергә җибәрермен ахры.

Син үзеңнең хатыңда: «Тормышың ничек уза? Балалар мине сагынамы? Искә төшерәләрме? Үзең нәрсә эшләп ятасың? Авылда күңелсез түгелме? Берсен дә калдырмыйча яз»,— дисең. Кызыксынуың өчен чын күңелдән рәхмәт.

Мин район үзәге булган Әдрәс авылына килеп төштем.

Бу авыл миңа бик ошады. Монда иске авыл эзләрен күрсәтеп торган мәчет тә, фәлән дә юк. Авыл уртасыннан боргаланып-сыргаланып агым су үтә. Шунда шатлана-шатлана бәбкәләре белән казлар, үрдәкләр һәм нәни балалар коена. Су буена алмагачлар, чия һәм шомырт агачлары тезелгән. Яз көннәрендә авыл ап-ак чәчәкләргә күмелә. Авыл өстенә хуш ис — аромат җәелә. Күрше таулардан чишмәләр ага. Тау өстендә урман шаулый. Авылдан бер километрда урман эчендә ял йорты урнаша. Ял йортының флагы көндезге кызыл йолдызсыман җем-җем итә, җилферди. Бу ял йортына һәр ел саен илебезнең төрле почмакларыннан ял итүчеләр җыела.

Көн саен авыл өстеннән һава яңгыратып корыч кошлар оча. Авыл уртасыннан безгә дөнья яңалыкларын китереп, сәлам хатларын калдырып поездлар уза. Поездда баручылар чәчәкле авылга карап яулык селкәләр. Поезд

тавышына кушылып, бүртә башлаган кырларда тракторлар җыры янгырый. Ак тасмадай сузылган таш юлдан грузовик һәм җиңел машиналар йөри.

Авылның җәйге күренеше әнә шул төстә. Ләкин авылда тора башлау белән миңа бик күп кыенлыкларга да очрарга туры килде.

Иң әүвәл ике ай буена амбулаториянең кечкенә генә бер бүлмәсендә урнашып тордым.

Мин килеп төшкәндә, амбулатория — врач пункты ташландык хәлдә иде: бинасы җимерек, пычрак, салкын,— кичләрен җилләр ыжгырып тора. Миңа хәтле пункт белән бер фельдшер мөдирлек иткән. Ул пунктка килгән спиртны эчү һәм ялган справкалар язып өләшүдән башка бернәрсә белән дә кызыксынмаган. Мин килер алдыннан гына аны шундый эшләре өчен һәм дәүләт ашлыгын урлау эшенә катнашуда гаепләп кулга алганнар.

Мөдир үзе бозык булгач, пунктның башка медицина эшчеләре дә: фельдшер Николай Яковлев, акушерка Хәдичә Таһирова, санитарка Мәрьям Галиева, чәчәк салучы Петровалар да эшкә салкын карарга гадәтләнгәннәр. Хезмәткә соң чыгалар, иртә китәләр, пунктка кергән авылларга барып йөрмиләр.

Райздрав урындыгына вакытлыча утырган тәҗрибәсез 20 яшьлек кыз үзеннән чыгып бернәрсә дә эшли алмый.

— Монда мин ничек эшләрмен икән, — дип котым очты. Шуның өстенә балаларымның авырулар килеп йөргән җирдә яшәүләре дә йөрәкне әрнетә башлады. Райбашкарма кешеләренең пункт эшләре белән җитәрлек үк кызыксынмавы ачуны китерде. Аптеканың ярлылыгы эчне пошырды. Берничә тапкыр: «Әллә ташлап качып китимме?» — дип тә уйладым. Ләкин китмәскә, киртәләрне җимерергә булдым.

МТС эшчеләренең ярдәме белән тиз арада гына амбулатория бинасын чистарттым, түшәмен һәм стеналарын агарттым. Аптека мөдиренә кискен рәвештә иң кирәкле даруларны булдырырга куштым. Авыруларны караган чакта:

— Кай җирең авырта, апа?

— Башым.

— Мә алайса, шуның белән аптекадан порошок алырсың. Көнгә өч тапкыр эчәрсең.

— Синең нәрсәң авырта?

— Аякларым сызлый. Салкын тиде, күрәсең. Эчем дә рәтле түгел.

— Мазь булыр. Йоклар алдыннан сөртерсең, — дип кенә карауларны туктаттым. Авыруны тыңлап карау, градусник куллану, авыруга карточка тутыру шикелле нәрсәләрне керттем.

Билгеле, шушындый кечкенә әйберләр дә башта каршылыкларга очрады. Җыелыш уздырырга туры килде. Пунктның эчке тәртибен төзеп аңлаттым. Авылларга чыгып йөрергә план төзедем. Эшнең иң күп өлешен үземә алдым.

Ләкин иң курыкканым — авыруны белә алмау, дөрес диагноз куймыйча ялгышу иде. Икенче көнемдә үк үземә тилерә башлаган 6 яшьлек бер ир баланы китерделәр.

— Күптәнме авырый?

— Кичәгенәк бик яхшы иде әле. Бүген кичкә таба шулай булды, — диде анасы.

Аптырадым бит. Баланы тыңлаган булдым, температурасын карадым, пульсын санадым. Ләкин нәрсә белән авырый — белә алмыйм. Фельдшер да юк. Ә бала тилерә: акыра, куллары белән баш әйләндергеч хәрәкәтләр ясый, күзләрен акайта.

Бу беренче бәладән мине врачлык сизгерлегем коткарды: авыруны коендырырга, юеш простыня белән төреп тотарга куштым һәм нервларны тынычландыра торган дару биреп җибәрдем. Ике-өч көннән соң бала элекке сәламәт хәленә килде. Ул, мескен, тиле бәрән үләне ашаган икән.

Ашлык җыю вакыты җитте. Авылда берүзем калып, эшчеләремне участокларга беркетеп, төрле авылларга чыгарып җибәрдем. Ерак авыллардан монда килеп ат куып йөргәнче, халык үзенә кирәк беренче ярдәмне урында алсын дидем.

Шул вакыт эчендә районыбызда медицина эшен югары дәрәҗәгә күтәргән өч вакыйга булып алды. Шуның аркасында врач исеме бик озак телдән телгә сөйләнеп йөрде.

Беренче вакыйга — 6—7 яшьлек бер кыз баланың Әдрәс суына бату вакыйгасы. Бу кызны мин элегрәк тә белә идем. Аның исеме Нәфисә. Ул бик еш минем Кадриям белән бергә уйный иде. Беркөн Кадрия артыннан аларга кергәндә, семьялары белән дә танышып чык-

тым. Атасы ашлык хәзерләү пунктында механик булып эшли. Бик яхшы эшче. Партия члены. Анасы — Зәйтүнә, киоскта газета-журналлар сата. Тату торган менә шушы семьяның бердәнбер балалары — Нәфисә йөзә белмичә су кереп, тирән чокырга очрап баткан. Балалар шау-шуына җыелган халык аны берничә минуттан соң гына судан үлек килеш чыгарган. Атасы миңа чапкан. Мин өйдә юк идем. Амбулаториягә килделәр.

Бату хәбәрен ишетү белән үк, мин чемоданымны эләктереп су янына йөгердем. Ләкин баланы өйгә алып кайтканнар иде инде.

Хәзер дә күз алдымда. Әнә ул өстәлдә ята. Тәне күгелҗем төскә керә башлаган, иреннәре каралып бөрешкән. Аяк бармаклары арасына үлән кысылган. Нинди матур бала иде. Әле иртә белән генә безнең тәрәзә янына килеп, шатлыклы күзләрен уйната-уйната:

— Кадрия, әйдә уйнарга!..—дип кычкырган иде. Уйнарга, сикерергә, көләргә хәзер иде. Ә хәзер үлек. Анын баш очында, баласының юеш чәчләрен үбә-үбә, ана елый. Зәйтүнә апаның үксеп елавы үлем кайгысын тагы да авырайта. Аяк очында нәрсә эшләргә дә белмәгән ата:

— Доктор, берәү генә бит... Бердәнбер балабыз иде... Шулай ук үлдемени? — ди. Нәрсәдер әйтергә тели. Ләкин сүзен әйтә алмый, тотлыга. Аның сүзен ана дәвам итә:

— Мин... мин генә гаепле... мин карамадым... Бәгырем, ник мине калдырдың?.. Каты сүз әйткән идемме әллә?.. Зинһар... зинһар... доктор...

Өй эче халык белән тулды. Болар бар да минем күз алдымнан ике-өч секунд эчендә үткән нәрсәләр. Халыкны чыгарырга, ананы алып китеп тынычландырырга куштым. Баланың авызын ачып сулыш алу эшләргә тотындым. Пульс бөтенләй юк. Тәрәзәләрне ачтырып, һаваны алмаштырдым.

Бичара Нәфисә! Кадрия янында еш күргәнгә, мин аны яратырга да өлгергән идем. Ә хәзер үлек. Үзем сулыш бирү эшлим, үзем хыялланам. Гүя минем алдымда Нәфисә түгел, Кадрия ята... юк, икәве дә үлек яталар, имеш. Мин Нәфисәнең ике кулыннан тотып сулыш ясыйм. Иртә белән дә шулай иде бит: ул кулыма сарылып Кадрия белән бергә мине өйдән озата чыккан иде.

Тәрәзә төбендә Кадрия елый. Аның тавышын мин бик ачык таныйм. Ул Нәфисә өчен елый. Дустын кызгана. Мин Нәфисәнең атасына борылам:

— Кадрия елый, — дим, — ул бик сизгер. Ул Нәфисәсен сагына. Алар бергә уйныйлар иде. Судан чыгарганны да карап торган. Әйтегез, алып китсеннәр үзен. Нәфисә терелә диегез, юатыгыз үзен.

Кулларым талганчы сулыш ясадым. Соңгы өмет итеп баланың тәненә камфара җибәрәм. Тагын бер тапкыр авызын, борынын арчыйм. Күзләремнән яшьләр тамарга тора. Йомшаклыгыма ачуланам. Докторга болай изрәргә ярамый дип, үземә батырлык кертергә тырышам. Ә үзем сулыш ясый-ясый авыз эченнән генә: «Терел, терел, бәгырем, яңадан уйнарсың, Кадрия белән йөрерсең, зур үсәрсең, илнең матурлыгын, тормышта яшәүнең күркәмлеген күрерсең... терел...», — дим. Баланың атасы нәрсәдер сөйли: «Ардыгыз инде, доктор, булмый, күрәсең», — ди бугай. Ләкин мин ишетмим. Күрше бүлмәдә баланың анасы — Зәйтүнә апа акыра: «Баламны җәфалыйсыз гына... Харап булдым бит...». Монысын да ачык ишетмим. Һаман сулыш ясыйм, һаман авыз эчен арчыйм.

Һәм... шатлыгымнан күз яше тамды... Йөрәк тибешем кузгалды.

Бөтен өмет өзелгәч, бичара ана елый-елый тавышсыз калгач, бала үзенең тере икәнен белгезде, сулыш алган кебек булды, авызыннан сү акты. Күз кабакларын селкетте. Әйе, баланың йөрәге тибә башлады. Шуннан соң миндә көч арткандай булды. Мин бөтен көчемне баланы саклап калырга, тибә башлаган йөрәкне туктатмаска тырыштым.

Ата-ананың шатлыгын күрсәң иде.

Әйе, бала исән калды. Ун көннән соң ул яңадан Кадрияне уйнарга чакыра башлады.

Бу вакыйгага хәзер дүрт еллап вакыт узды. Ә Нәфисәнең ата-анасы хәзердә дә әле миңа рәхмәтләрен әйтеп бетерә алмыйлар. Ерактан күргәндә дә, берәр урында тавышымны ишеткәндә дә, яныма килеп исәнлегемне сорашалар, бик озак итеп күзләремә карап торалар.

Икенче вакыйга күрше авылда булды. Беркөнне үземне Чымты авылына авыруны карарга алып киттеләр. 40—50 минуттан соң мин анда идем инде. Кечкенә генә бер өй янына тукталдым. Эш вакыты булуга карамастан, өй һәм ишек алды халык белән тулган.

— Авыру кайда? — дидем.

Күз яшен сөртә-сөртә бер карчык (авыруның анасы булып чыкты ул):

— Менә, бәгырем, — дип сәкегә күрсәтте. Карасам, сәкедә толыплар белән томаланып, бармаклары белән мендәргә ябышып, авызыннан күбекләр чыгарып, 18—20 яшьлек бер кыз ята. Толыпларны алу белән, пар күтәрелде.

— Авыруны торгызырга кирәк, халыкны чыгарыгыз, тәрәзәләрне ачыгыз, — дидем.

Җыелган халык берәм-берәм чыга башлады. Ләкин әлеге карчык: «Юк, юк, болай гына авырый ул, кузгатмыйча гына карагыз», — дип авыруга кагылырга да бирми. Авыруның температурасын карадым — 39°. Пульсын санарга дип кулына сузылсам, бармакларым юеш бер нәрсәгә тиде. Бу — кан булып чыкты. Ә карчык һаман саен:

— Кузгатмагыз, узар... Зыяндашлы бала ул... Һәр ел шулай була торган иде, — ди.

Халык чыгып бетүгә, карчыкны читкә этеп җибәрдем дә авыруны, күлмәкләрен күтәреп, йөзе белән үземә әйләндереп, карарга тотындым. Ул кан эчендә иде. Карчык елый-елый кулларыма ябышты:

— Зинһар хур итә күрмәгез... чыгып китегез... сездән башка да терелә ул, — ди.

Мин янәдән карчыкны этеп җибәрдем. Ачу катыш:

— Балагыз үлә бит, күрмисезмени? — дип кычкырганымны сизми дә калдым.

Кулларымны юып авыруга ярдәм бирергә тотындым. Ул бала тапкан. Ләкин соңгылыгын алмыйча калдырганнар. Мин тиешле ярдәмне күрсәттем дә карчыкка:

— Авыруга тынычлык кирәк, беркемне дә кертмә, — дип авыл советына киттем.

Урамга чыгу белән, үземне карт-карчык, бала-чага сырып алды. Әле ансы, әле монсы:

— Нәрсә бар?

— Тереләме?

— Нишләттегез үзен?

— Бала табамы? — дип, сораулар белән ябырылдылар.

Авыл советына кызның бала тапканын, баланың юкка чыгарылуын һәм акт төзергә кирәклеген әйттем. Милиционер килде. Акт төзелде. Карчык елый-елый кызның балага узу тарихын сөйләде.

— Улым Габделхак авылда комсомолда эшли иде. Гэҗитләргә дә яза иде. Шәкүр бай семьясының калдыклары булган теге Низам, Гаязларны да язган дип әйттеләр. Авылдан куарга кирәк дип язган диделәр. Шуннан соң улым шәһәргә эшкә китте. Хәзер дә шунда. Ә теге явыз Низам Мәһинур кызым белән йөрергә тотынды. «Мин сине үземә алам, өйләнәм», дип сөйләгән, күрәсең. Кызым ышанган. Ә Низам Габделхактан үч алу өчен генә шулай йөргән икән. Соңыннан әллә кая качып китте. Мәһинурым балага узды. Кызым үзен хурлыктан саклап калу өчен төрле дарулар эчеп карады, бөтен серен миңа сөйләде. Ә мин: «Габделхак ишетсә, нишләр?» — дип бик курыктым. Кызым эчен бәйләп йөри башлады. Күбрәк өйдә утыра торган булды. Халык сизмәде, ахры. Ул-бу бер дә ишетелмәде. Һәм бүген таңда бала тапты. Ләкин бала үлек иде.

Шуннан соң без мунча янында җиргә күмелгән баланы казып карадык та тикшерү ясадык. Мин баланың чынлап та үлек тууын расладым.

Авыру бер атнадан аякка басты.

Ләкин мине кызның көлкегә калуы, анасы теле белән әйткәндә, «хур булуы» борчыды. Кыз, терелеп житкәч тә, беркая чыкмыйча, өйдә генә утыра торган булды. Йомыш белән кергән күрше хатыннар:

— Терелдеңме инде? Габделхак нәрсә яза?

— Кулак Низамны әйтәм әле... Төче телләнеп Габделхак сеңелесен ничек алдый алган! — дип ярага учлап-учлап тоз салалар.

Шуларны ишеткәч, мин кызның рухын күтәрергә, аны юатырга тырыштым. Ләкин күзләрендә ачу күрдем. «Нигә син катнаштың? Үлеп котылган булсам, бу хурлыкны күрмәгән булыр идем. Тере калсам да, болай сөйләп йөрмәсләр иде», дигән кебек миңа чирканып, ачуланып карый. Мин аңлатырга тырыштым, ләкин файдасыз, кыз тыңламый да. Үзәгенә үткән, күрәсең. Тирән итеп кайгыра белә ул.

Болай ярдәм күрсәтә алмагач, мин икенче юлны кабул иттем. Бөтен мәсьәләне аңлатып Габделхакка хат яздым. Кызны гайбәттән, «хурлыктан», үз-үзен үтерүдән саклап калу өчен аны хәзер үк шәһәргә алдырырга кирәклекне аңлаттым. Гадәтемчә, хатны йомшак сүзләр белән тутырдым. Хат тәэсир иттеме, әллә Габделхак шулай тиз аңладымы: ике атна эчендә ул Мәһинурны үз

янына алдырды. Хәтта рәхмәтләр белән тулган җавап хаты да яздылар.

Бу вакыйгадан соң авылда: «Доктордан яшереп кала алмассың, ул барысын да белә», — дип бик озак сөйләделәр. Ә кызны алырга килгән Габделхак авыл советында, комсомол ячейкасында:

— Кеше үлем алдында булган, үлә башлаган, ә сез, бәладән тартып аласы урында, гайбәт чәйнәтеп аңа кабер казыгансыз. Ярый әле шундый яхшы доктор туры килгән. Докторыгызның кадерен белегез, — дип сөйләгән диделәр.

Өченче вакыйга — төрле җирдә дәваланып та сәламәтләнә алмаган бер картның Әдрәскә килүе булды. Аны әлеге уңышлы эшләремнән соң туганнары: «Бездә бик шәп доктор бар, сине шул гына терелтсә терелтер»,— дип чакыртканнар. Бу карт Әдрәскә зур өметләр белән килде. Ул берничә район больницасында булган. Аны: «Синдә рак»,— дип куркытканнар. Карт миңа килгәндә бөтенләй ябык иде; яңаклары ябышкан, күзләре эчкә баткан, үзе көчкә йөри. Тыңлап карадым: йөрәге яхшы эшли, үпкәләре исән. Бөтен зарланганы:

— Ашый торган ашымны йота алмыйм, кире чыгарам, — ди. Шул уңай белән ике-өч көн эчендә үземдә булган бөтен әдәбиятны яңадан карап чыктым. Һәм шуннан соң гына ышандырырлык рәвештә картка:

— Куркырлык бернәрсә дә юк. Синдә рак түгел, — дидем, — шулай да рентген нурларына күренәсең калган. Берәр атна хәл җый да Казанга рентгенга бар,— дип, кулымнан килгәнчә үзен дәваларга тотындым. Нәрсә белән дәваладым? Җылы ванна. Аш юлын йомшарта торган дарулар. Сыек аш. Кишер сыгынтысы.

Шушындый чаралардан соң авыруым аз-аз гына булса да ашый башлады, баш чатнавы бетте, үзе тышка йөрергә тотынды һәм тыныч йоклый торган булды. Бер ай вакыт эчендә тәмам таза хәленә керде.

Бу өч вакыйга минем рухымны күтәрде, кыюлыгымны арттырды. «Укуым юкка булмаган, җәмгыятькә минем дә файдам тия», дип канатланып эшли башладым.

Доктор исеме халык телендә аеруча бер җылылык белән сөйләнсә дә, райбашкарма председателе пунктка һаман да ярдәм кулын сузмады. Ремонт ясатырга дип төзелгән сметаны кире кайтарды. Аптеканы башка бинага

чыгарырга рөхсәт бирмәде. Райбашкарма председателе Галиуллин, катырак сөйләшә башлагач:

— Ремонтка акча юк. Квартира өчен иртә тыпырчынасың. Юкны кайдан алыйм соң? Үз яныма торырга кермәссең бит, — дип коточкыч сүзләр тезеп китте.

Шушындый юләр башның районда житәкче булып торуына исем китте. Ул үзенә баш игәнне ярата икән. Йомыш белән кабинетына кергән кешегә урын да тәкъдим итә белми. Галиуллин белән ярты сәгать сөйләшүдән соң, мин районның ни өчен койрыкта сөйрәлүен, чәчү буенча да, башка кампанияләр буенча да планның тутырылмау сәбәпләренә төшендем.

Галиуллин үткән ел Казанда эшләгән. Анда ул бер учреждениенең башында торганда эшчеләр, хезмәткәрләр арасында талаш, жәнжал чыгарырга сәбәпче булган. Иң яхшы көчләрне үзеннән качып китәргә мәжбүр иткән. Быел каты шелтә белән районга килгән. Ләкин ул монда да: «Юл ерак, ишетелмәс», дип уйлагангамы, я булмаса иске «гөнаһлары» бетмәгәнгәме, һаман үзенекен итә килде.

Мин үземә, эшемә дигән булышлыкны бары тик МТС директоры Кадыйровтан һәм район мөдире Латыйповтан гына күрә идем. Алар миңа байтак ярдәм иттеләр. Амбулаториягә ремонт ясаганда, материал табыштылар. Ат сораганда, ат бирделәр. Аларның киңәшләрен истә тотып, Галиуллин кабинетыннан мин райкомга киттем. Һәм әле бер атналар чамасы гына районга килеп эшли башлаган райком секретаре иптәш Корбанов янына кердем. Ул, мин килеп кергәндә, нәрсәдер язып утыра иде. Бер бюрократтан икенче бюрократка эләктем, ахры, дип, ачуым килде. Һәм тавышыма усаллык биреп:

— Мин, иптәш, Казанга кайтып китәм. Мин тик яту өчен ВУЗ бетермәдем. Мин эшләргә килгән идем, ләкин сезгә эшчеләр кирәкми икән... Мин аңламыйм, Галиуллин шикелле булдыксыз кешеләрне эш башында нигә тоталар икән?

Корбановның елмаюы минем сүземне бүлдерде. Ул тагы да елмая төшеп:

— Гафу итегез, сүзегезне бүләм. Утырыгыз. Мин монда яңа кеше — ялгышмасам, без таныш та түгел әле. Сез кем буласыз? Мин Сафа Корбанов,— дип күрешергә кулын сузды.

— Доктор Галия Сафиуллина,— дип мин дә кул

бирдем. Оялуымнан битләрем уттай яна башлады. Яулык чыгарып маңгай тирләремне сөртергә тотындым. Аның тыныч тавышы, күзлек аркылы миңа текәлгән соргылт күзләре йомышымны оныттырдылар. Ул:

— Килүегез өчен рәхмәт. Мин сезнең турыда күп кенә яхшы нәрсәләр ишетергә өлгердем. Халык: «Әдрәс доктор күргәне юк иде. Инде менә дигәне булды», — ди. Үзегезне бик яраталар. Нигә китәм дисез? Галиуллинга ник ачуландыгыз? Ярдәм кирәкме? Сөйләгез, мөмкин булган булышлыкны эшләргә тырышырбыз, — диде дә, урыныннан торып, бүлмә буенча йөрергә тотынды. Ул кечкенә буйлы.

— Сез минем ачуланып керүемә гаҗәпсенмәгез. Менә мин гаепле түгел, Әдрәснең Галиуллиннары гаепле. Сезне күргәч, дөресе сез торып йөри башлагач, ничектер җиңелрәк булып китте. Йомышым шул: амбулатория ташландык хәлдә, шунда ук аптека да, квартиралар да. Кышка хәтле ремонт ясатырга кирәк. Ә Галиуллин бу турыда ишетергә дә теләми.

— Ярый, — диде Корбанов, — мин сөйләшеп карармын. Хәзергә бернәрсә ышандыра алмасам да, мөмкин булганын эшләргә тырышырбыз.

Корбанов яныннан мин тәмам тынычланып чыктым. Корбанов минем белән сөйләшкән кебек үк, Галиуллин янына барып тыныч кына сөйләшәсем килде.

Шул ук көнне кич белән, мин күрше авылларның берсенә киткән арада, Корбанов, Галиуллин һәм техник — өчәү амбулаторияне килеп караганнар. Ә иртәгесе көнне Галиуллин мине үзенә чакыртып алды да:

— Әмма усал да икәнсең. Усаллар эшлекле булалар. Мин үзем дә усал. Ат докторына дип тоткан бер квартирам бар иде. Шуны сиңа бирәм. Барып кара. Ошаса, бүген үк күчәргә мөмкин. Иртәгә президиум утырышы була. Шул вакытка райздрав, техник һәм үзең—өчәүләп ремонт турында смета төзегез. Ләкин сметаң ике мең сумнан артмаска тиешле. Докладны үзең ясарсың, — диде.

Шаркылдап көләсем килде. «Квартирам бар, шуны сиңа бирәм, имеш». Корбанов каты кыздырган, күрәсең!

Ахырысында квартирага да күчтем. Мең бәла белән аннан такта, моннан кадак, тегеннән бур җыеп, ремонтны очлап чыктым. Аптеканы икенче бинага күчердек. Ләкин бу эшләрнең ахырына чыгар өчен күп көч түгәргә, йокы

калдырырга, аш вакытын истән чыгарып, онытылып эшләргә туры килде. Ә эш муеннан: ашлык жыю, допризывникларны хәзерләү, ремонт алып бару һәм башкалар. Менә болар һәммәсе дә медицина өлкәсе буенча беренче айларымда ук минем өстемә төшкән иде. Шул ук вакытта көн саен авылларга да чыгарга туры килә иде. Аннан арып, тузанга буялып кайтасың. Өйгә килеп керү белән, ике яктан ике балам сарыла. Алар белән рәхәтләнеп, уйнап-көлеп йокларга ятасың. Изрәп йоклыйсың. Ләкин туйганчы йокларга бик сирәк туры килә иде. Чөнки бик еш төнлә белән авыруларны карарга алып китәләр. Мин зарланмыйм. Иренмичә татлы йокымны ташлап караңгы төндә сикәлтәле юллардан, кара урман аша авыруга ярдәм кулын сузарга барам. Тик Галиуллин шикелле кешеләрне очраткач кына, йөрәк әрнеп китә. Автомобильне аның кебекләргә түгел, докторларга бирергә иде», — диясе килә. Соңыннан, тынычлангач, шундый фикерләремә үзем дә гажәпсенәм һәм кычкырып көләм. Шулай да яхшы эшләре өчен жиңел автомобиль белән бүләкләнгән «Кызыл Тан» колхозы доктор артыннан автомобиль жибәргәндә, шул автомобильгә утырып киң кырлар аша барганда: «Берничә елдан соң минем матур илем һәрбер район врачын автомобильгә утыртып йөртер», — дип, шул нәрсәнең тормышта булуына ышанып уйланам.

Искәндәр!

Бу юлларны укып, син тагын: «Галия кызу эш аркасында балаларын да оныткан», — дип уйлый күрмә. Балалар — минем шатлыгым. Бала караучы Наташа да аларны үзем кебек ук тирән ярату белән ярата. Үткән ел балаларым өчен радио куйдырдым. Жәй көннәрендә бу радио өй алдын клубка әйләндерде. Балалар гына түгел, зурлар да килеп кич буе концерт тыңлыйлар, жырлыйлар, бииләр. Хәзер Әдрәстә 40 радиоточка бар. Шулай да халык күбрәк минем радионы тыңларга жыела. Чөнки минем радио буенча теләгән бер шәһәрне тыңларга мөмкин.

Еш булмаса да, балаларым белән бергә су керергә барам, урманга чыгам.

Киләсе елга пианино алырга жыенуымны яздым шикелле. Ләкин балалар өчен болар гына житми. Аларга тере кеше дә, ата да кирәк. Авыл тормышын күрмәгән кеше генә, крестьян балалары ата-ана мәхәббәтен күр-

мичә үсәләр дип сөйлиләр. Бу дөрес түгел. Әйе, авыл балалары, күбесенчә, үз ирекләрендә үсәләр. Ләкин ата-аналары бушаган минутта, туйганчы сөеләләр дә, назланалар да.

Синең белән аерылуга өч еллап вакыт узгач, Кадрия бик еш:

— Әнкәй, нигә безнең әтиебез юк? Ул кайчан кайта? Минем әтием кемгә охшаган? Ник ул хат язмый? — дип сорашырга башлады.

Менә шуңа күрә дә эштән арткан һәрбер минутымны мин балаларыма биреп килдем. Миңа алар янында ана да, ата да була белергә кирәк иде. Ә бу бик кыен нәрсә. Балаларым яшь, әтиләре турында дөресен сөйләсәм, аңлый алмаслар. Шул ук вакытта: «Без аерылдык, сез ятим калдыгыз», — дип иске заман сүзләре белән кәефләрен дә бозасым килми. Ата турында сүз чыккан саен, мин аларга:

— Ул Мәскәүдә укый. Укып бетергәч кайтыр. Сезгә бүләкләр китерер, — дип сөйлим.

Балаларга шулай сөйләгәч, семья тормышым белән кызыксынган чит кешеләргә дә «ирем читтә», дип ялганларга өйрәндем. Кем белә, бәлки гайбәттән саклану өчен генә дә мин «ирем бар» дияр идем. Чөнки авылда тол хатынга, ире булмыйча балалар асраган кешегә начар күз белән карау бетмәгән әле.

Хатын-кызга карата хайвани теләкләрне җиңелрәк үтәү күзлегеннән карау бетеп җиткәне юк әле. Үткән ел мин үзем шушындый типларның берсенә очрадым. Бу тип — әлеге Галиуллин.

Мәсьәлә яхшырак аңлашылсын өчен, мин сине бер вакыйга белән таныштырып үтәм.

Безнең авылда бер автомобиль бар. Бу автомобильгә, күбесенчә, райбашкарма председателе Галиуллин утырып йөри. Бу машина турында үткән елларны төрле-төрле әкиятләр сөйләнде, җыр-бәетләр әйтелде.

Көннәрнең берендә миңа районыбызның иң ерак Аккаен дигән авылына эш белән барып кайтырга кирәк иде. Ат сорап йөргәндә, әлеге Галиуллинны очраттым. Ул, ат сораганымны ишеткәч:

— Ат көчен юкка әрәм итмәгез, хәзер шул якка машина китә. Сезгә генә урын табылыр. Машина белән үк кайтырсыз да, — диде.

Мин риза булдым. Башта дүрт кеше барырга тиеш

булсак та, китү вакыты җиткәч, машинага шофердан башка Галиуллин белән мин генә утырдык. Шушындый үзгәрештән һәм Галиуллинның минем белән бүген «сез» дип төче телләнеп йомшак итеп сөйләшергә тырышуыннан мин үземә тиешле нәтиҗәләрне чыгардым.

Юлда үземне мөмкин хәтле иркен тотарга булдым.

Авылны чыгу белән үк, Галиуллин, минем тормышым турында сүз башлап: «Ялгызына күңелсез түгелме? Менә сезнең кебек усал хатыннар авылда күбрәк булса, без бик тиз үсәр идек. Юк шул, аз. Аннары матур хатын-кызга авылда яшәве дә күңелсез. Матурлар бик сайлаучан булалар. Бер сорау бирсәм, ачуланмассызмы? Юк. Физиологический потребностька ничек карыйсыз?» — дип, бер-бер артлы өзек-өзек җөмләләрен тезеп китте. Шул арада тозсыз анекдотларын да сөйләп алды. «Туңмыйсызмы?» дип җилкәмә салынган плащымны төзәткән булып, кулларын хәрәкәткә китерә башлады. Аннары, үзен зур каһарманга исәпләп, шәхси тормышында, өй эчендә рәхәт күрәсе килгәнен, ләкин бу рәхәтнең унмаган хатыны аркасында юклыгын аңлатты. Ләкин мин аны кирәгенчә тыңламыйча, сорауларына җавап кайтармыйча бардым. Чөнки аның, мәче күзләрен елтыр-елтыр китереп, мал карагандай сөзеп каравы, мышнаулары мине чиркандырды. •

Бер ярты сәгать барганнан соң, без куе урманга кердек. Галиуллин шоферга акрын барырга кушты. Ул бу урманның матурлыгын, чәчәкләрен, җиләкләрен мактады. Шул урман аркылы үткәндә кулаклар тарафыннан үтерелгән ике коммунистның батырлыкларын сөйләде. Һәм бераз эндәшми баргачтын, «Кара урман» көенә җырлап җибәрде. Галиуллинның һәрбер кыланышы, җырлаган чакта җилкәләрен селкетүе, тавышы, мәче күзләренә моңлык кертүе — бөтенесе дә миңа ошарга тырышуын күрсәтәләр иде. Ләкин ул шулай ясалма кылланган саен, минем нәфрәтем тагын да арта барды.

Урманны чыгабыз дигәндә, ул машинаны туктатырга кушты. Мин аңа киңәшмәгә барасын, үземнең дә ашыгуымны әйттем. Ул ярым гаҗәпсенү белән:

— Табигатьне яратмыйсызмыни? Миңа калса, сезнең шикелле матур хатын белән шушындый яшел урманда, чәчәкләр арасында, саф һава уртасында бергә булу өчен мин киңәшмәне генә түгел, бөтен дөньяны оныта алам,— дип, куе агачлар арасына кереп китте.

Мин машинадан төшмәдем. Биш-ун минуттан соң Галиуллин бер букет чәчәкләр һәм тамырлары белән үк өзелгән кып-кызыл җиләкләр китерде. Ул аларны:

— Теләсәгез ничек аңлагыз, миннән истәлек, — дип миңа сузды.

Машина кузгалып китте. Галиуллин үзенең тактикасын үзгәртте. Турыдан-туры алырга мөмкин булмагач, йомшак мөгамәлә белән минем күңелемне табарга тырышты.

Аккаен авылында озак тормадык. Мин балалар яслесендә смотр уздырып, шуның күршесендә үк бизгәк белән авырган бер хатынны караганда, Галиуллин килеп тә житте.

— Киттекме, доктор? — диде.

Кире кайтырга дип машинага утырганда, караңгылык төшә башлаган иде инде. Бөдрәләнә башлаган болытлар яңгыр булып яварга җыеналар. Ашыгырга кирәк иде. Янадан урман аркылы кайтырга туры килде. Юл буе Галиуллин үзенең киңәшмәдә булуы, анда нәрсә сөйләве турында мине таныштырып барды. Аның тавышында да, сүз сайлавында да «күрәсеңме, мин сезнең белән ничек уртаклашам, сезне якын күрергә теләүдән шулай итәм бит», дигән нәрсәне аңлап була иде. Шуңа бәйләп үзенең семья тормышын, хатынының булдыксызлыгын да сөйләде. Очраган бер кешегә хатынын, семьясын яманлап йөргән вак кешеләрне яратмыйм мин. Шуңа күрә бу сүзләрдән соң миндә Галиуллинга карата нәфрәт тагы да артты, үсте.

Урманга кердек. Урман уртасында машинабыз кинәт туктады. Шофер Ибрай:

— Их, шайтан алгыры, машинаның моторы бозылды бит, — диде.

— Ну? — диде Галиуллин.

— Инде нишлибез? Төзәтеп буламы? — дип соравыма, шофер, борчылган кыяфәт белән:

— Өстемә карап тормасагыз, тиз төзәтермен, — диде дә моторның калфагын алып казынырга тотынды. Галиуллин, мине култыклап:

— Минем шофер бик тискәре кеше, әйдәгез бераз читкәрәк китеп тынычландырыйк үзен. Ибрай карап торганны һәм үз эшенә тыгылганны яратмый, — дип сөйләнә-сөйләнә мине урман эченә, юлдан читкә алып китте. Шофер, машинаны төзәтеп бетергәч тә, быргы кычкыртырга булды.

Галиуллин ярым караңгыда миңа җиләкләр җыйды, чәчәкләр китерде. Ә мин быргы көттем, машина турында уйландым. «Машина ватылмаган. Бу бары урманда туктап тору өчен корылган хәйлә генә. Галиуллин нинди планнар кора икән?» Минем бу уйларымны Галиуллинның, яңадан бер кочак чәчәкләр китереп, яныма утыруы өзде. Ул бер чәчәк алды да аның яфракларын берәм-берәм өзеп: «Ярата — яратмый, ярата — яратмый», — дияргә тотынды. Сүзне мәхәббәткә борып шаяра башлады. «Урманда сулавы рәхәт», — дип кулларын бер күтәреп, бер төшереп, тирән-тирән суларга кереште. Аннары:

— Ә сез нигә суламыйсыз? Сулагыз, сезнең тирән сулавыгызны карыйсым, тыңлыйсым килә. Хатын-кызларның, бигрәк тә сезнең шикелле матурларның, сулавы аеруча матур була: күкрәк бер күтәрелә, бер төшә... ягез, — дип, минем кулларымнан эләктереп алды һәм, ничектер җаен туры китереп, үбәргә омтылды.

Мин:

— Бу нәрсә тагын? — дидем дә бар көчем белән үзен этеп җибәрдем.

Ләкин Галиуллин кылануыннан тукталмады, мин этеп җибәргәч, шаярам дип белде, күрәсең, шаркылдап көлде дә:

— Һо, сез көчле... карап карыйк... кайсыбыз көчлерәк икән, — дип мине кочаклап алды. Мин лач итеп аның битенә төкердем һәм каты кычкыру белән (шофер ишетсен дип) «кабахәт», «шакшы» дип аны этеп җибәрдем. Үзем машинага йөгердем.

— Нигә быргы кычкыртмыйсыз?

— Кычкыртырга гына тора идем, үзегез килеп җиттегез, — диде шофер.

Машина кузгалып киткәч, Галиуллин бөтенләй башка, гаепле кеше тавышы белән:

— Зинһар гафу итегез... Мин белмәдем... Мин түзмәдем, назланасым килгән иде... Каршы тормассыз дип уйлаган идем, — диде.

— Сез кабахәтнең дә кабахәте икәнсез. Бер тапкыр этеп җибәргәч, нигә инде икенче кат сузылырга?

— Шаярасыз дип белдем. Хатын-кызлар бервакытта да: «Мин синеке», димиләр. Алар һәрвакыт: «Нишләвең инде бу? Кирәкми», диләр, ә үзләре кочакка кысыла баралар. Ә сез башка. Онытыйк. Бу турыда бервакытта да искә төшермәгез, — дип ялварды. Шуннан соң безнең

сүз әллә ничек бәйләнмәде. Мин Галиуллинның бу кыланышына әллә артык әһәмият биргәнгә, әллә аны өйрәтергә теләгәнгә, машинаны туктатырга сорап, шофер янына күчеп утырдым һәм каһкаһә белән: «Синең начальнигың, Ибрай, хатын-кызлар янында үзен тота белми, хулиганнарча кылана. Мин синең янында утырып барам», — дидем. Галиуллин бер сүз дә эндәшмәде.

Төрле бәет, такмаза, җырларның тууына сәбәп булган Галиуллин машинасы әнә шул инде. Такмаза-җырларда-төп каһарманнар булып әлеге Камал Галиуллин, МТС кешесе Мөстәкыймов һәм хатын-кызлардан ясләдә бала караучы Мәрфүзә һәм тимер юл станциясеннән Тамара исемле бер кыз йөри. Әйтелгән такмаклар, җырланган җырлар буенча да машинаның моторы бик еш бозыла икән.

Ләкин Галиуллинның бу «батырлыклары» озакка бармады. Чуан тиз тишелде.

Эш Галиуллинның партиядән чыгарылуы, урыныннан алынуы белән бетте. Галиуллин китеп, яңа җитәкчеләр сайлангач, районыбыз бик тиз алга, югарыга таба күтәрелә башлады. Ышанмассың, быел урамнарга агачлар утыртылды, тротуарлар ясала. Колхозчылар да, Галиуллин куылгач, ничектер яхшырак эшлиләр кебек тоела. Корбановны бик яраталар. Ул Галиуллинның киресе, онытылып эшли белә, тынычлыгы белән иң авыр бәлаләрне дә җиңеп чыга.

Искәндәр!

Бу хатны мин өзеп-өзеп, ялгыз калган минутларымда язам. Яза башлавыма байтак вакыт үтте, ә ахырына, соңгы сүземә һаман җитә алмыйм әле. Хатларымда аңлашылмый торган урыннар, әйтелеп бетмәгән фикерләр булса, гафу ит. Күрәсең ич, балалар турында яза башлаган идем, Галиуллинга күчкәнмен. Кайчагында шундый озын хатлар язуыма кәефем дә китә. «Ни өчен язам?» — дип үз-үземә сораулар бирәм. Йөрәккә тулган шул. Бушанасым килә. Ә вакыт-вакыт хатларда кузгатылган мәсьәләләрнең тирәнлегенә төшенеп, аларны «Ана хатлары» исемендә газетага да язасым килә.

Мин сиңа балаларыма «әткәй» табуым турында язарга уйлаган идем. Бу гаҗәп эш болай булды.

Кичләрнең берсендә, студентка чагымнан калган дәфтәрләрне актарганда, корзина төбеннән бер рәсем килеп чыкты. Бу рәсем минем белән бергә укыган, миңа

яшерен мәхәббәт тотып йөргән рабфак студенты Вәли Сафиуллин рәсеме иде. Рабфакта чакта мин стена газетасында секретарь булып эшли идем. Шуннан эләгеп калган рәсем, ахры. Рәсемне кулга алып карый башлау белән, күз алдыма тере Вәли килеп басты. Кара күзләрен төбәп, безнең залдан чыгып китүебезне карап калуын хәтерләдем. Кызгандым үзен. Аңардан көлеп йөрүемә ачуландым. Ләкин рәсем караган кичне, Искәндәр, мин сине уйламаска тырыштым. Иректә-ирексез гел Вәли Сафиуллин тирәсендә әйләндем. Һәм кинәт яңа дөнья ачкан шикелле: «Вәлинең фамилиясе дә минем фамилиям белән бер, мин дә Сафиуллина бит. Кадрия: «Әткәй кайда? Ул кемгә охшаган?» дип сорый. Менә синең әткәең. Менә минем ирем»,— дип, Вәлине үземә хыялый ир иттем.

Ачуланма, Искәндәр! Бу кичне мин сине бөтенләйгә оныттым. Бу кичне мин Сафиуллин рәсемен, рамага куеп, стенага элдем. Ә иртәгесен Кадрия белән Рафаэльгә:

— Карагыз, әткәегез нинди чибәр. Ул тиздән кайтыр,— дип, аларны хыялый аталары белән таныштыра башладым.

Рәсем төшерергә яратуымны син яхшы беләсең. Торабара Вәли рәсемен мин берничә данә итеп эшләдем, зурайттым, кечерәйттем. Һәм Вәли рәсемен үз рәсемем белән янәшә куеп төшердем — икәү бергә төшкәндәй чыкты.

Бервакыт үтенеп сорагач, син минем белән рәсемгә төшәргә барган идең. Шунда син Кадрияне итәгеңә алып төшкән идең. Бу рәсем миндә әле дә саклана. Алар икәү. Шуның берсеннән синең башыңны кисеп алып, Сафиуллин башын куеп төшердем.

Бу рәсемнәрнең барысы да стенага эленделәр. Аларга үзем дә, балалар да, күршеләр дә ияләштек. Ә Рафаэль:

— Әткәең кайда? — дигәч:

— Менә,— дип, бөтен рәсемнәрдән Вәлине күрсәтеп чыга.

— Әткәеңне ничек яратасың? — дип сорагач,

— Менә ничек,— ди дә Вәлинең рәсемен үбәргә тотына.

Ләкин кайчагында шушындый нәрсәне уйлап чыгаруыма үземнең дә исем китә. Шаярудан башланган әйбер чынлап та зурга китте.

Иң курыкканым Сафиуллинның тере булып чыгуы

яки аның танышларына очравым иде. Ләкин, нишләптер, күп миллионлы халык арасында Сафиуллин югалгандыр, онытылгандыр, дөньяның алтыдан бер өлеше булган киң Советлар Союзында Вәли минем белән очрашмаслык урында эшләп ята торгандыр дип, үз-үземне төрлечә тынычландырырга тырыша идем.

Яшермим, бик еш Вәлине күрәсе килгән көннәрем була. Хәтта амбулаториядәге уңышлардан соң өйгә кайтып кергәч, аның рәсеменә карап: «Вәли, син хәзер кайда? Галия исемле «хатының» барлыкны үзең беләсеңме? Галия — синеке!» — дип хыялланам.

Балаларга ата табылды. Ләкин хыялый атаны чын ата итеп өзлексез рәвештә саклап баруы бик кыен булды. Кадриянең «Әткәй ник хат язмый?» дип соравына каршы, үз-үземә хатлар язарга туры килде. Соңра һәр ун көн саен мин, башымнан уйлап чыгарып, Вәлидән дип, үземә һәм балаларга сәлам хатлары китерергә өйрәндем. Хат алгач, җавап та язарга кирәк була. Айга бер-ике тапкыр минем белән бергә, үткән җәйдән бирле, Кадрия дә Вәлигә, дөресе — «атасына» хат яза. Менә аның бүген салып җибәрергә дигән яңа хаты:

«Әткәйгә сәлам! Рафаэль дә сиңа хат язган булып утыра. Ул яза белми. Минем кәгазьләрне генә боза. Мин аңа ачуланмыйм. Рафаэль кечкенә, ә мин зур. Ләкин ул усал — таяк белән башка суга. Таяк белән кыйнашырга ярамый дип әйтәм, аңламый.

Әткәй, син кайчан кайтасың? Тизрәк кайт инде. Икәү бергә урманга йөрербез. Анда бик күп матур чәчәкләр бар. Әнкәй күп эшли, бушамый. Наташа Рафаэльне карый, ә ялгызымны җибәрмиләр. Син кайтсаң, икәү йөрер идек. Син миңа рисовальный дәфтәрләр, цветной карандашлар, пионерский галстук һәм скакалкалар алып кайт, Рафаэльгә дә ал. Алмасаң, ул елар, минекен сорар.

Кайт инде, әткәй. Мин сиңа үзем ясаган рәсемнәремне күрсәтермен. Үбәм.

Кызың Кадрия».

Тора-бара Вәлидән «килгән» хатларга мин газеталардан укылган хәбәрләрне, кызыклы вакыйгаларны алып, аларны хатлар итеп балаларга тәрбия бирерлек рухта язарга өйрәндем. Сирәк кенә булса да: «Вәлидән—атагыздан посылка»,—дип балаларга бүләкләр ки-

терә башладым. Ләкин бу эшнең ахыры куркыта. Балалар үскәнче, бу «сер» ачылмасын гына иде. Ә үскәч, мин аларга үземнең юләрлегемне әкият итеп сөйләрмен. Ул чагында кешеләр дә бит бик нык үзгәргән булырлар.

Ләкин үткән ел әлеге суга баткан Нәфисәнең анасы Зәйтүнә апа, газета китереп, бик каты куркытты:

— Кара әле, Галия, монда синең иреңне язганнар, рәсемен дә төшергәннәр, — диде.

Аптыравымнан нәрсә әйтергә белмәдем. Катып калдым.

— Нигә шатланмыйсың? Аны мактаганнар бит. Мә, укы, «укытучы Сафиуллин» дигән,— диде дә миңа газетаны сузды.

— Әткәйне язганнармы? Карыйм әле,— дип Кадрия дә йөгереп килеп карарга тотынды.

— Нишләп шатланмыйм! Әлбәттә, шатланам. Ләкин мин бик арыганмын. Аннары Вәли бу турыда миңа хатта да язган иде,— дип курка-курка гына газетаны укырга тотындым.

Вәли Сафиуллин Казан рабфагын бетергәннән соң Мәскәүгә киткән. Университетның физматында укыган һәм төннәр буенча математика өстендә утырган. МГУ ны бетергәч, Мәскәү урта мәктәпләренең берсенә математика укытучысы булып кергән. Анда ВУЗларда сокланырлык рәвештә математика кабинеты оештырган. Укыту эшенә үзенең модельләрен керткән, профессорның әйтүенә караганда, Сафиуллин математиканы иң күңелле, иң җиңел дәрес иткән. Сафиуллин мәктәбе үрнәк мәктәпкә әйләндерелгән. Хөкүмәт Сафиуллинның укыту хезмәтләрен, җәмәгать эшен искә алып, аны Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләгән. Мәкаләдә әнә шулар языла.

Зәйтүнә апа чыгып китте. Ә мин, Вәлинең газетада басылган рәсемен карап, төрле уйларга чумдым. Илебез Вәлинең йокымсыравын югалткан, кешеләрдән качып йөргән Вәли партиягә кергән.

Туган илем, син нинди көчле! Вәлине атаклы кеше булу дәрәҗәсенә күтәргәнсең. Мине дә, мине дә, илем, үзеңнең кочагыңнан чыгарма.

Күпме уйланып утырганмын — ачык хәтерләмим. Тик, болай булгачтын, Вәлинең «хыялый ата» булуы ачылыр, миннән көләрләр, дип курка башлавым гына исемдә. Нишләргә? Аның ата булуына үзем дә, балалар

да, күршеләр дә ияләшкән идек инде. Аннары Советлар илендә Вәли шикелле атаклы кешеләр байтак санала. Вәлине Әдрәстә кем күрсен соң? — дип үз-үземне юатып та куйдым. Һәм:

— Кадрия, Рафаэль, тыңлагыз, эткәегез турында сөйлим,— дип, әлеге мәкаләне балалар теленә күчереп аңлата башладым.

Ярый. Тыныч йокы яки хәерле иртә, Искәндәр. Вәли турында уйлап, өченче хатымны шуның белән тәмам итәм.

ДҮРТЕНЧЕ ХАТ

Искәндәр!

Хатларымда язылган вакыйгалардан соң, үз-үземә ачуым артты: «Син, Галия, иске карашлардан арчынып бетмәгәнсең, семьяны бик югары күтәрәсең, романтикага бирелеп, тормыштан читкә тәгәрисең. «Врач хатлары», «Амбулатория хатлары» язасы урынга, Искәндәргә язасың», дип үземне тиргәргә тотындым.

Тик эштә генә онытыла алам. Амбулаториянең чисталыгын, килгән авыруларның газета-журнал карап утыруларын күргәч, приемда булган кайбер тәҗрибәләрне дәфтәргә яза башлагач кына, чын-чынлап рәхәтләнәм.

Ял көннәремдә балаларымны житәкләп, Мәфтуха апайга барам. Ул колхоз председателе булып эшли. Без аның белән кечке лампа алдында колхоз турында, илебез турында сөйләшәбез. Кечкенә-кечкенә китаплар укыйбыз. Революция корбаннарына багышланган истәлекләрне актарабыз. Мин Мәфтуха апайның көннән-көн үсә барганын күрәм.

Кайчагында бу сөйләшү чәенә күрше хатын-кызлар да, хатын-кызлар баш булганны карап тору өчен ирләр дә керәләр.

Шушындый чәйләрнең берсендә мин җыелган халыкка түбәндәге документны татарчага тәрҗемә итеп укып чыктым. Бу документ 1920 нче елны Одесса шәһәрендә аклар тарафыннан үтерелгән кыз турында. Менә ул:

«Кадерле иптәшләр!

Мин үземнең кечкенә тормышымны намус белән үттем, намус белән үләм дә. Бүген кич мине атачаклар. Әсигез көннән миңа 22 яшь тула. Үлүем кызганыч түгел, революция өчен бик аз эшләдем — шунысы кызганыч.

Үләсе килми. Чөнки мин үземне, хәзер генә, төрмәгә эләккәч кенә аңлы революционерка һәм партия эшчесе итеп сизә башладым. Эшлисе килә.

Кулга алынганда һәм судта үземне ничек тотуым турында иптәшләр сөйләрләр. Алар: «Син үзеңне егетләрчә тоттың»,—диләр. Әнкәй бәгыремне кысып-кысып үбәм. Әнкәй, тормышымның ахыры төрмә эчендә, пуля астында бетүе өчен елама. Советлар иленең эшчән анасы булырга тырыш. Дошманнар кулында үлгән кызыңның истәлегенә кер төшермә — большевиклар яклы бул.

Без, үлемгә хөкем ителүчеләр, барыбыз да үзебезне яхшы хис итәбез. Бүген соңгы мәртәбә газеталар укыдык. Безнекеләр Перекопка киләләр. Тиздән Украина иркен сулыш алыр. Кызу эш, иркен хезмәт, рәхәт көннәр башланыр. Илебез чәчәк атар. Тик мин булмам. Менә шунысы кызганыч.

Я, хушыгыз, бәхетле булыгыз.

Д. Любарская.»

Йомыш белән генә кергән 60 яшьлек Минниса әби түзмәде. Җыерчыклар белән капланган бите буенча мөлдерәп аккан күз яшьләрен сөртә-сөртә:

— Кем яза дисең әле, доктор? — дип сорады.

— Любарская. Нигә сорыйсың, әби?

— Яхшырак кара, доктор, минем кызым Фәтхуллина түгелме? 22 яшь дигән бит. Аннары Украинасы да бар. Минем кызым Мәрьям дә атасы янына Донбасска киткән иде. Атасы турында хәбәрем бар. Безнекеләр кая киләләр дип укыдың әле?

— Перекопка.

— Әйе, картым менә шунда, Перекопны алганда үтерелгән. Ә кызым турында һичбер хәбәрем юк. Бәлки бу хатны ул мескенем язгандыр. Теле бик йомшак. «Әнкәй бәгырем», дигән бит. Минем кызым да йомшак күңелле иде, — дип үксеп елый башлады. Мин мөмкин хәтле җинел итеп аңлатырга һәм юатырга тырыштым.

Мәфтуха апай төрмәдән язылган әлеге хатны үзенә бирүемне сорады һәм башка хатны укырга кушты. Икенче хатны да, укыгач, үзенә алды.

Хатлар укылып беткәч, шул уңай белән без гражданнар сугышы һәм сугышта хатын-кызларның катнашулары турында сөйләшеп алдык. Сөйләшү озакка сузылды. Киткән чагында Мәфтуха апай:

— Мин син укыган хатларны изба-читальняга бирәм, — диде.

Мәфтуха апай бик зирәк кеше. Икенче баруымда, ул мине, авыру карарга дигән булып, Миңниса әбигә алып китте. Тик юлда барганда гына:

— Син инде бернәрсә дә белмәгән бул. Миңниса әби сине бик ошаткан. «Докторны миңа алып кил», ди. Кунакка чакыра үзеңне. Башка хатын-кызлар да булачак. Син безгә авырудан саклану, балаларны ничек тәрбия итү турында сөйләрсең, — диде.

Бу турыда мин үзем дә уйлап йөри идем. Хәтта бер тапкыр Мәфтуха апайга: «Берәр колхозница йортында әңгәмә уздырасы иде. Шәһәрдә хәзер җыелышларны ударниклар өендә уздыралар», — дип сөйләгән идем.

Без барып кергәндә, Миңниса әби бер хатын белән өстәл хәстәрләп йөри иде. Өе чиста. Идәннәр сап-сары итеп юылган. Тәрәзәләргә ап-ак пәрдәләр корылган. Стенада Ленин рәсеме.

Озакламый егермеләп кеше җыелды. Сүз ара сүз чыгып, мин санитария-профилактика турында сөйләп алдым. Миңниса әби, иске заманны искә төшереп, ачлытуклы яшәвен, газап-михнәт эчендә көн күрүен сөйләде. Ирен, кызын сагынды. Аның улы — районның иң яхшы тракторчысы — Мәрдәнша гармонь алып уйный башлады. Арадан берәү ул уйнаган көйгә сүз кушты. Җыр күтәрелде.

Авылга килгәннән бирле бер генә тапкыр да җырлаганым юк иде. «Безнең доктор җырчы икән», дип сөйләүләреннән курыктым. Докторлыгыма караганда, җырчылыгыма тизрәк ышанырлар, дип уйлаган идем. Ә монда түзмәдем — җырлап җибәрдем.

Җыр бетүгә, гармонь бию көенә сиптерергә тотынды. Комсомолка Галия һәм тагын берәү ду китереп бии башладылар.

Тәрәзә алды халык белән тулды. Бер минутлык тынлыктан файдаланып, Мәфтуха апай ашлык җыю кампаниясенең житүе һәм ничек эшләргә кирәклек турында сөйләде. Үзенең колхозындагы алдынгы кешеләрнең исемнәрен дә әйтеп үтте. Шуннан соң ул җыелган халык арасыннан әллә кемне эзләп табып алды да аңа сорау бирде. Аңардан җавап алгач, икенче кешегә күчте, аннан өченчесенә, дүртенчесенә... Аның сораулары һәм алган җаваплары бу төстә булды:

— Камәр апа, синең Фатыйма исемле бер кызың бар иде, ул хәзер кайда һәм кем булып эшли?

— Беләсең ич, Буа районында агроном ул хәзер.

— Ә син нәрсә тик торасың? Синең дә бит, Гайшә җиңги, Шәмсинур исемле кызың бар иде. Кайда соң ул?

— Ул Казанда инженер булып эшли.

— Ә синең кызың Халисә кайда?

— Халисә Мәскәүдә укый. Судья була ул.

— Ә син, Җиһанша абый, ник дәшмисең? Тәрәзә төбендә торасың. Өйгә керер идең. Синең дә бит Майшәкәр исемле кызың бар. Ул хәзер кайда?

Җиһанша абый тиз генә җавап бирмәде. Башта мыек астыннан елмайды, аннары: «Рәхмәт, кызым Мәфтуха, мине дә телгә алдың», дигәнсыман тамак кырды. Шуннан соң гына:

— Минем кызга берәвегез дә тормый. Минем Майшәкәрем трактористка. Менә минем кызым кем, — дип мактанып җавап бирде.

— Күрәсезме, иптәшләр, — диде Мәфтуха апай, — безнең авыл хатын-кызлары арасыннан кемнәр чыга. Агрономнар, инженерлар, врачлар, судьялар, тракторчылар, председательләр. Бу безнең илдә. Ләкин дөньяда башка илләр дә бар. Хатын-кызлар анда ничек яши соң? Яле, доктор, син укыган кеше — аңлатып бир әле,— дип һич көтмәгән җирдән миңа борылды да:—Миңа сөйләгән нәрсәләрне сөйлә,—диде.

Искәндәр!

Мин үземне яхшы ораторлардан санамыйм. Ләкин сөйләр әйберең булганда һәм сөйлисе килгән чагында сүз үзеннән-үзе агып тора икән. Мәфтуха апай «сөйлә» дигәч тә, мин миңа текәлгән йөздән артык күзне күрдем.

Бервакыт мин Мәфтуха апай белән утырганда, аңа йөрәк өзгеч бер документ укыган идем. Бу документ чит ил хатын-кызларының ачы фаҗигасе, күз яше турында. Менә ул:

«Ошбу договор күңел ачу йортының хуҗасы (исем, фамилия) һәм шул йортка эшкә керүче (исем, фамилия) арасында, (исем, фамилия)нең матди хәле начарлану сәбәпле, ата-аналарының яки башка туганнарының рөхсәте белән фахишә булуы турында төзелә.

Шушы договор нигезендә, күңел ачу йортының хуҗа-

сы (исем, фамилия) фәлән тиен күләмендә (исем, фамилия) гә ссуда бирә. Бу ссуданы (исем, фамилия) фахишәлек итеп тапкан акчаларыннан һич тоткарсыз фәлән срокта түләп бетерергә тиеш.

Фахишәлекнең һәрбер прием хакы фәлән күләмдә билгеләнә.»

Япония үзенең фахишәлек «промышленностен» әнә шушындый договорлар белән үстерә. Мондый договорлар бер Аумари районында гына җиде мең крестьян кызы белән төзелгән. Буржуа матбугатында чыккан материалларга караганда, хәзер Япониядә регистрация аркылы узган илле мең өч йөз илле өч фахишә бар.

Германия фашистлары хатын-кызны моңарчы күрелмәгән хурлыкка калдырды. Анда хатын-кызларны университетлардан, институтлардан куалап чыгардылар да:

— Синең эшең хатын булу, синең эшең ирләрненазлау, син милләтнең сөяркәсе, син эшләмә, укыма, синең урының кухня, чиркәү, кровать, — диделәр.

Искәндәр!

Миндә газета-журналлардан һәм үзем күргән вакыйгалардан җыелып барылган искиткеч документлар бар. Документлар папкасы үзенең бөтен гомерен эшчеләр сыйныфына, кешелек дөньясының иң якты киләчәгенә багышлаган Ленин иптәш белән бер сафта эшләгән Надежда Крупская, Клара Цеткин һәм башка кешеләрнең исемнәре белән башлана. Минем папкамда төрле милләт хатын-кызлары бар. Менә математика фәлсәфәсе буенча профессор, әнә гистология профессоры. Ә менә үзбәк кызы, күкрәгендә мактау ордены ялтырый. Әнә парашютта дөнья рекорды ясаган орденлы Федорова. Менә салкын котыпны өйрәнүгә күп көч куйган һәм орден белән бүләкләнгән гыйльми эшче Русинова. Әнә инженер. Менә очучы. Язучы.

Өч йөз битлек папка-журналым шушындый документлар белән тулган. Бу минем йомшак ягым. Кайберәүләр ташлар, күбәләкләр җыя, икенче берәүләр маркалар коллекциясе төзи. Ә мин батыр совет хатын-кызлары турында документлар җыям.

Миңниса әби өендә мин менә шуларны сөйләдем. Бик гади итеп сөйләргә тырыштым. Аңладылар, ахрысы, чөнки япон крестьян кызларын кызганып елаучылар булды.

Чөнки парашютта дөнья рекорды куйган Федоровалар турында сөйләгәндә, тыңлаучылар тәрәзә аша күккә карап тордылар. Колхоз председателе Мәфтуха апай турында сөйләгәндә, безнең арада нинди шәп кешеләр бар, дигәнсыман берничә тапкыр кул чаптылар.

Искәндәр!

Тормышыма зур үзгәреш керткән бер вакыйга булу аркасында, бу хат нәкъ 20 көн өзелеп торды. Шунлыктан Мәфтуха апай турында да яза алмый калдым. Мин сиңа байтак нәрсә турында язарга уйлаган идем. Ләкин көтмәгән бер вакыйга килеп чыгып, хатымны чуалтты. Шуның аркасында башта язылган өч хатымны да җибәрми калдым.

Беркөн амбулаториядә авыруларны карап бетереп китәргә җыенганда гына, ял йорты докторы кереп:

— Ирең безгә ял итәргә килде. Синең турыда сөйләгәч бик шатланды. Бүген яныңа килә,— диде.

Кулымда градусник иде — төшеп ватылды. Бер-ике минутка телсез калдым. Нинди ирем? Кем? Искәндәрме? Вәлиме? Нәрсә уйларга да, кемне күрергә дә белмәдем. Ял йорты докторы гаҗәп культуралы кеше. Ул канлы ярага тоз салырга яратмый — минем нинди хәлдә калуымны аңлады күрәсең:

— Шатлыгыңнан шаккаттың бит, Галия. Ярый, мин киттем. Иреңне каршы алырга комачауламыйм. Аннары ашыгыч эшләрем дә бар. Икәүләп безнең янга мороженое ашарга барыгыз, — дип чыгып китте.

Ял йорты докторы чыгып киткәч, ярты сәгать чамасы кабинетымда бикләнеп утырдым. «Искәндәр булмас, аның белән бөтен нәрсә өзелгән, беткән. Ул булса — күрешермен, сөйләшермен дә бетәр. Вәли булса нишләрмен? Романтикага бирелеп тудырылган хыялый ирем юкка чыккач, халыкка, балаларга нәрсә әйтермен?»— дип уйландым. Авыр уйлардан башым авырта башлады. Өйгә кайтырга җыенып, амбулатория ишеген ачтым. Ишек төбендә Вәли Сафиуллин иде.

— Мөмкинме? — диде.

— Рәхим итегез...

Без кабинетка кердек. Ул бик нык үзгәргән. Йокымсыравы беткән. Олылык төсе кергән. Тик аның күзләрендә генә элекке Сафиуллин билгеләре калган. Йөзендә — шатлык.

— Әдрәстә очрашырбыз дип кем уйлаган?!

— Әйе.

— Я, ничек торасыз? Сез мине оныткансыз да инде. Хәер, белмим. Ә мин рабфакны, рабфак белән бергә, сезне дә бик еш искә төшерәм, — дип сөйләп китеп, мине уңайсызлыктан чыгарырга тырышты.

Бер ярты сәгать сөйләшкәннән соң:

— Буш булсагыз, мине чәй белән сыйлар идегез. Ял йортында чәйне көнгә бер генә тапкыр бирәләр, ә мин яратып чәй эчәргә өйрәнгән кеше. Семьягыз белән дә таныштырырсыз,— диде дә урыныннан кузгалды.

Башта мин аны өемә чакырырга да, чакырмаска да белмәдем, чөнки балаларым әткәй дип Вәлинең муенына асылынулары мөмкин. Рәсемнәрне күреп мине дә, үзен дә уңайсыз хәлдә калдырыр. Мин шулай уйладым. Ләкин шулхәтле озак күрешми торганнан соң, «вакытым юк» дип, Вәлине дә кайтарып җибәрергә теләмәдем. Тик амбулаториядән чыккач кына, башыма килгән фикерне әйтә алдым:

— Әнә теге ак йортны күрәсезме? Мин шунда торам инде. Приемнан соң өс-башны алмаштырасы бар. Ун унбиш минуттан соң шунда килергә булсагыз, мин сезне вареньелап чәй белән сыйлармын,—дидем.

Ул риза булды.

Мин өйгә кайтып, балаларны урманга җиләккә җибәрдем. Самовар куеп, өстемне алмаштырдым. Һәм түземсезлек белән Вәлине көтә башладым. Стеналарга эленеп куелган рәсемнәрне кузгатмаска булдым. Сер ачылгачтын ахырына кадәр ачылсын, дидем.

Самовар өстәлгә менү белән, Вәли килеп керде.

— Сезнең квартирагыз шәһәр квартираларыннан бер дә ким түгел,—дип, керүенә бүлмәләремне мактый-мактый күзен стеналарга, рәсемнәргә төшерде. Рәсемнәрдә үзен күрүгә гаҗәпсенде. Ләкин эндәшмәде. Тик чәй алдында гына, бер-беребезгә ияләшә төшкәч кенә, түбәндәгечә сөйләшүләр китте:

— Карагыз әле, Галия,—диде ул,—мин ял йортына килеп төшкәннең икенче көнендә үк миңа: «Сезнең хатыныгыз биредә доктор булып эшли»,—диделәр. Юлда йөргәндә, ял йортларында ятканда кеше белән нинди кызык нәрсәләр булмый! Тиз танышасың. Шунда моңарчы берәүгә дә сөйләмәгән серләреңне сөйлисең. Моннан соң мәңге очрашмаслык кешеләр белән дусланасың.

Бу юлы да: «Мине берәр кеше белән бутыйлар күрәсең, әйдә, кызык булсын»,—дип уйладым да, «Хатының монда» дип әйтүчеләргә: «Әйе шул, минем хатыным монда эшли»,—дия башладым. Ләкин ял йорты докторы да шул ук сүзне әйткәч, «сезнең хатыныгыз Галия Сафиуллина» дигәнне дә ишеткәч, борчылырга тотындым һәм сезне күрәсем килде: «Фамилияләр бер булганга, шулай әйтә торганнардыр»,—дип уйласам да, «юк», дип җавап бирергә телем бармады. Чөнки рабфакта чакта мин хыял итеп йөргән Галиямнең хәзер кешеләр тарафыннан «синең хатының Галия» дип йөртелүе минем өчен рәхәт иде. Инде үзегезне күрдем. Менә монда, сезнең өегездә утырам. Стенада үземнең рәсемнәремне күрәм. Ләкин бит мин сезнең белән бервакытта да рәсемгә төшкәнем юк. Миңа охшаган кеше кем ул? Ялгышмасам, сез артист Искәндәргә чыккан идегез. Аерылдыгызмы әллә? Искәндәрдән соң әнә шушы рәсемдәге кешегә чыктыгызмы? Нинди кәмит бу? Зинһар, аңлата күрегез.

— Искәндәр белән мин күптән аерылдым. Шуннан соң берәүгә дә чыкмадым, дияр идем, хата булыр. Чөнки рәсемдәге кеше «ирем» булып хисаплана. Балаларым аңа «әткәй»,—диләр.

— Кем соң ул?

— Ул — сез. Мин ул рәсемне рабфактан калган дәфтәрләрем арасыннан таптым.

— Димәк, сезне минем хатыным дип йөрүләре дөрес?

— Әйе, дөрес.

— Ләкин мин бернәрсә дә аңлый алмыйм. Бу эшкә сәбәп нәрсә?

— Әгәр дә бу эш сезне борчыса, мин хәзер үк рәсемнәрне алып яшерә алам һәм, телисез икән, ял йортына барып: «Бу Сафиуллин минем ирем түгел»,—дия алам. Ләкин сез монда күп булса тагын бер ай торырсыз. Авырсынмасагыз, мин сездән бу «кәмит»нең, «фаҗигале кәмитнең» дәвам итүен сорар идем.

— Ягъни?

— Ягъни, семьягыз турында сүз чыкканда...

— Мин өйләнмәгән, минем семьям юк...

— Минем турыда сүз чыкканда, дим мин...

— Әйе...

— Галия минем хатыным, иптәшем, дип әйтегез.

— Ни өчен? Нигә? Һич аңламыйм.

— Вәли, сез миңа бик авыр сораулар бирәсез. Курыкмагыз, мин сезгә ике баламны тагарга, сезгә кияүгә чыгарга уйламыйм. Бу бары сезне һәм үземне кешеләр алдында кыен хәлдән чыгару өчен генә. Юкса, я сез, я мин, икебезнең берсе хәзер үк моннан китәргә тиеш.

— Беребез дә китми. Мин риза. Тик үзем белмичә, мин ничек итеп сезнең ирегез булганмын? Шуны беләсе килә.

— Ансын хәзергә сорамагыз. Мин аны сезгә... Димәк, риза?

— Риза.

— Рәхмәт,—дидем дә кулымны суздым һәм аны балаларның яшьләре, исемнәре белән таныштырдым. Үз өенә килгән кебек, миңа кереп йөрүен сорадым. Балалар белән әткәйләре шикелле сөйләшүен үтендем.

Шуннан соң ул көн саен безгә килеп йөри башлады. Балалар аңа бик тиз ияләштеләр. «Әткәй», «Әткәем», дип артыннан калмыйча йөриләр. Бергә урманга, чиягә йөрдек. Шул вакытларны райздрав:

— Ирең дә кайткан, ашлык җыю вакыты да җитә. Син бер 15 көнгә отпускыга чыгар идең. Аннары кызу эш булыр,—дип үземә отпуск бирде.

Без көн саен очраша торган булдык. Бергә төрле китаплар укылды. Студент чаклар искә төшерелде. Ләкин Вәли һичбер вакыт Галиуллин шикелле начар кыланмады. Мин үземнән курыктым. Чөнки Вәлине чын-чынлап ярата башлаганымны сиздем. Аның белән ничек саубуллашырмын, бергә кушылмас борын — ничек аерылырмын, дип йөрәгем сызлады.

Менә хәзер дә, шушы хатны язып утырганда да борчылам. Вәли көн саен миннән үземне аның хатыны дип халыкка белдерүемнең сәбәбен сорый. Мин «иртәгә», «иртәгә» дип сузып килдем. Соңгы соравына «китәр көнеңдә әйтермен» дидем. Иртәгә ул китә. Ничек аңлатырга! Кайчагында миңа ул мине элеккечә үк ярата төсле тоела. Хәтта шаярып утырганда:

— Галия, чынлап та мин синең чын ирең — иптәшең булсам, ягъни без бергә кушылсак, ни әйтер идең?— дип сораулар да бирә.

Ләкин мин мондый сораулар бирелгәндә, я эндәшми калам, я шаярып әйтелгән сүзгә борам. Чөнки мин аның мәхәббәтенә җавап бирә алмам төсле. Ике балалы булуым, рабфакта аңардан көлеп йөрүем — синең белән

торуым аның исенә төшәр, ул борчылыр, борчылса да әйтмәс. Әйтми калуы аңа газап булыр. Ә мин аның газап күрүен теләмим.

Иртәгә Вәлинең китү көне. Мин бүген эшкә чыктым. Башым һич эшләми. Гел аның турында уйланам. Аның белән аерылу Казаннан киткән минутларыма караганда да авыррак буласын беләм. Бу хатны шунда өзеп: «Вәли, мин сине яратам бит, ләкин без синең белән хыялда гына ир белән хатын булып калырбыз»,—дип хатны аңа борасы килә.

Берәү ишек шакый.

Вәли: «Иртәгә соңгы кич, озак утырырга килермен»,—дигән иде.

— Ярыймы?—ди. Ул!

Искәндәр!

Күрше бүлмәдә Вәли утыра. Яза алмыйм, кулларым калтырый. Вәли:

— Иртәгә китәм, Галия. Ләкин китәсе килми. Ияләштем. Шулай да китәм. «Хыялый ирең» булуымның сәбәбен беләсем килә. Тагы да ярты айга калырга мөмкин иде. Калсам, бөтенләй китә алмам дип куркам. Серне ачыгыз,—ди.

Мин «хәзер» дип, икенче бүлмәгә керәм һәм шушы сүзләрне язам. Болай гына сөйләп мин аңа барыбер аңлата алмам. Чөнки үземне бик начар хис итәм. Шуңа күрә дә сиңа язылган хатларны Вәлигә бирергә булдым. Укысын да, теләсә ничек аңласын. Хәзер янына чыгам да:

— Мә, дустым, шуларны укып чык. Бу — минем тормышым. Шуннан барысын да аңларсың,—дим.

Хуш, Искәндәр. Сау бул! Хуш, Вәли! Синең белән саубуллашуы миңа бик авыр булыр.

Галия.

АВТОРДАН

Кадерле укучым!

Быел яз көне миңа бер семьяда кунакта булырга туры килде. Бу семья үзенең шатлыгы, бәхетлелеге белән мине бик кызыктырды. Шулхәтле тату торган семьялар әле бездә хәзер генә күбәеп чәчәк атып баралар. Берсе укытучы, зур эшләре өчен орден

белән бүләкләнгән, икенчесе доктор — яңа гына партиягә кергән. Ике балалары бар. Мин аларга һәркич саен кереп йөри башладым. Һәм соңгы баруларымның берсендә:

— Сез бик яхшы торасыз. Беренче танышуыгыз ничек булды? Ничек бер-берегезне таптыгыз? Сөйләргә ярыймы? — дип сорадым.

Яңа дусларым миңа сез укып чыккан әлеге хатларны чыгарып бирделәр һәм:

— Сез язучы бит, файдаланырга мөмкин,— диделәр.

Мин хатларны укып чыгу белән, фамилияләрне һәм район, авыл исемнәрен алмаштырып, аларны, дусларымның рөхсәте белән, мабугатка чыгарырга уйладым. Бу хатларга карап мин үзем дә әлеге таныш семья кешеләрен Галия һәм Вәли дип кенә йөртә башладым. Тик Ирочка Делевскаяның исемен генә алмаштырмадым. Ул үз исемендә яши. Аны күрәсе килгәнемне аңлата алмыйм.

Ира, исән булсагыз, миңа хәбәр бирегез. Мин сезне сезнең турыда уйлаган, сезне күрергә теләгән Галия белән таныштырырмын.

1935

ПУБЛИЦИСТИКА

РУС ӘДӘБИЯТЫНЫҢ Г. ТУКАЙГА ТӘЭСИРЕ

КЕРЕШ

Татар матур әдәбиятының көннән-көн гыйльми тикшеренүләр астында чәчәкләнә баруы соңгы елларның киң кырлы җимешләреннән саналырга тиешле.

Алдыбызда торган мәүзуг та әнә шул тикшеренүләргә кечкенә генә булса да бер тәҗрибә итеп алына.

Тәэсир мәсьәләсе бер бездә генә түгел, хәтта рус матбугатында да аерым язучыларына карата хәл кылынмаган кыен проблемаларның берсе.

Бу мәсьәләне хәл кылу яки шуңа таба адымнар ясау вакыты бик җиткән инде. Чөнки әдәбият тарихының шактый тармаклары әдип-шагыйрьләрнең иҗатларына бәя кую, аларны таный белү кебек бик күп яклар әнә шушы тәэсир астында чишелмичә кала килделәр.

Фатих Әмирханның «Тигезсез»ләре Чеховның «Чайка»сына яки Мәҗит ага Гафуриның Некрасовка бәйләнешле булуы һәм башка кайбер әдип-шагыйрьләребезнең азмы-күпме рус язучыларының итәкләренә тагылып барулары безнең алдыбызга хәл кылынмаган бик зур һәм тирән мәсьәләләрне китереп бастыралар.

ТӘЭСИР — ЙОГЫНТЫ

Тәэсиргә бирелү — ул бер кешенең икенче бер кеше канаты астына керүе дигән сүз. Әдәби тәэсир дә шулай ук. Бер әдип яки шагыйрьләр икенче бер әдип-шагыйрьләрнең канатлары астына урнашып, төрлесе төрлечә аларның иҗатларыннан файдаланалар.

Әдәби тәэсир бер милләтнең үз язучылары арасында гына булган кебек үк, ике милләт язучылары арасында да бар. Һәм ул бик еш очрый да.

Соңгы заман материалларына карап, әдәби тәэсирне өч төргә бүләргә мөмкин; алар түбәндәгечә:

I. Тәкълит (ияру). Бу төр тәэсирдә бер язучы икенче бер язучының әдәби көченнән, аның иҗатыннан, канаты астыннан һич тә чыга алмый. Тәэсир итүче язучы нәрсә язса, нәрсә җырласа — тәэсиргә бирелүче дә гел шуны гына, аның җырларын гына җырлап, кабатлап бара. Бу вакыт тәэсир итү көче тәэсиргә бирелү көченнән артыграк, көчлерәк була.

II. Үзләштерү. Бусында инде тәэсир итү көче белән тәэсиргә бирелү көчләре бер дәрәҗәдә, бер баскычтарак торалар. Бу турыда бер язучы икенче язучының әдәби характерын, жанрын, материалын, әсәрне эшләп чыгу методларын үзләштерә дә үзенчә яза. Шушы материаллардан файдаланып, үзе иҗат итә башлый. Үз көен җырларга керешә... Икенче төрле әйткәндә: «Картузлы Иванны Гайнетдин итә».

III. Файдалану. Бусы инде тәэсирнең иң күп таралган төре. Монда тәэсир итү көче тәэсиргә бирелү көченнән түбәнрәк, көчсезрәк дәрәҗәдә тора. Бу төрдә, күбесенчә, язучының мәүзугларыннан, тел-эслүбеннән яки формасыннан файдаланалар.

Билгеле, бу төрләр турында тагы да озынрак тукталырга кирәк иде, һәм бу яхшы да булыр иде. Болар арасына тагы IV итеп тәрҗемә мәсьәләсен дә кертәсе калган. Ләкин хәзерге мәкалә моны сыйдырмый, бер. Аннары, Тукайга күчәр өчен шунсы да җитәр кебек тоела.

ТУКАЙ ҺӘМ ПУШКИННАР

Шагыйрь Тукай рус мәктәпләренә кереп бер системалы рәвештә укымаса да, ләкин ул татар шагыйрьләреннән рус әдәбиятының тәмен белгән, аны укыган, аның белән нык таныш булганнарның берсе иде. Моңар Тукайның Пушкин, Лермонтов, Кольцовлардан өзек-өзек тәрҗемәләр биреп баруын әйтү дә җитә. Ул, заманында шаулап та, хәзерге көндә гаммә алдында онытылып барган Майков, Федоров кебек шагыйрьләрне дә тәрҗемә иткән, Потапенколарны да хәтердә тоткан.

Аннары Тукайны белгән иптәшләр аның «Пушкинны» корьән итеп кочаклап йөргән дә сөйлиләр. Димәк, Тукай рус әдәбиятын укыган, хәтта Тукайның иң матур, иң чәчәкләнгән, шигъри яктан чәчәк аткан әдәби дәвере дә — аның рус әдәбияты белән ризыклана башлаган, анардан тәржемә үрнәкләре бирә башлаган елларына туры килә.

Г. Кариевның язуына караганда, аның беренче шигыре дә «Мужик йокысы» була. Тукайның беренче тәржемәләре 1906—1907 нче елларны чыга башлый.

1907 нче елгы шигырендә Тукай болай ди:

Пушкин илә Лермонтовтан үрнәк алам,
Әкрен-әкрен югарыга үрләп барам...

Чынлап та, Тукайның төп шагыйрь-мөгаллимнәре әнә шулар булдылар. Ул моны үзе дә бөтен гомере буенча тәкрарлап килде.

Аның:

Хәзрәте Пушкин авылда язды үз Евгениен,
Мин исә жырлыйм фәкать монда бәрәңгенең көен.
Шунда да күрмим үземне һич тә Пушкиннан түбән,
Тугъры күз салсаң әшемә, ул үзе миннән түбән...—

дип жырлаган жырлары «ярым шаяру» жырлары булса да, Тукайның Пушкинга табынганлыгын яки Пушкинны өйрәнеп йөргәнен күрсәтәләр. Ул Пушкинның тәржемәи хәлен дә укыган, «Евгений Онегин»ның авылда язылганын да белә.

Яки 1911 нче елгы «Җавап» шигырендәгечә:

Шигъри Лермонтов вә Пушкин — олуг саф диңгез ул,
Хәзрәте Пушкин вә Лермонтов, Тукай — өч йолдыз ул! —

дип, үзен Пушкиннар белән рәттән куя. Өч йолдызның берсе — ул мин дип кычкыра! Тукайның рус әдәбияты тәэсиренә (бигрәк тә Пушкиннар, Лермонтовлар тәэсиренә) бирелүенә бик күп сәбәпләр, мөмкинлекләр бар. Мәсәлән:

I. Татарның шигьри дөньясында Тукайга чаклы әдәби мирасның аз яки бик аз булуы. Тукай татарның шигъри дөньясында үзенең теле-эслубе[1] белән дә, күтәреп чыккан мәүзуг, мөндәрижәләре белән дә нова-

[1] Эслубе — стиле.

тор иде. Шуңа күрә дә бу зур вазифаны Тукай рус әдәбиятыннан алган белеме аркасында гына үти алды.

II. Лермонтов һәм Пушкинның (шулай ук болар аша Байронның да) романтизмнары Тукайда туган романтизмга ят түгел, бәлки «Пушкин илә Лермонтовтан үрнәк алам» дигәндә, үрнәк булырлык, Тукайның бүтән иҗатына да әсас[1] булырлык агым иде. Аннары Лермонтовның тормыш юлы, аның ялгызлык характеры белән Тукайның хосусый характеры, тормышы арасында да аларның иҗатларын бер итәрлек сызыклар, сыйфатлар бар. Билгеле, менә бу бердәмлек сыйфатлары, Тукайга Лермонтов яки Пушкинның романтизм шигырьләре азык бирмәделәр дип әйтеп булмый.

III. 1905 нче елгы революция хәрәкәтләре тәэсирендә яңалыкка, «европеец» булуга омтылулар. Бу дулкыннар да Тукайга нык тәэсир иттеләр, аны рус әдәбиятына, рус классикларына таба этеп җибәрүдә яхшы ук бер көч булганнардыр диясем килә.

IV. Каты реакция вакыты... яки Пушкин, Лермонтов, Некрасовлар җырлаган рус халкы белән Тукай җырлаган татар халкының (төрле дәверләренә карамастан) ничәмә гасырлар буенча бер тырнак, бер үк төркемнәр астында изелүләре...

Менә болар һәм монда кермәгән бик күп яклар Тукайның рус әдәбияты тәэсиренә бирелүенә сәбәпче мотивлар булып яталар, болар аша Тукай:

> Мин мәхәббәтсез дидем, ләкин мәхәббәт төрлечә,
> Йолдыз ул күктән атылган җиргә Генрих Гейнечә, —

дигәнсыман, Шекспир, Шиллер, Байрон, Гейне кебек әдәбият дөньясының иң бөек шагыйрьләреннән дә авыз итте. Алардан алган тәм белән ләззәтләнде, бөек шагыйрьләрнең иҗатларын хис итеп, үз иҗатын баетты, нечкәртте, шигъриятләндерде. Ә болар өчен Тукай да, Тукайны укучылар да иң беренче нәүбәттә Пушкин, Лермонтовларга яки, тулаем алганда, рус әдәбиятына бурычлы булып калалар. Ләкин Тукай бу бурычны үзенең онытылмаслык шигъри җәүһәрләр бирүе белән түләде инде.

Билгеле, һәрбер шагыйрь яки әдип үз иҗатында елдан-ел алга таба бара. Үсә. Аның һәрбер яңа әсәре

[1] Әсас — нигез.

элекке әсәрләренә караганда шагыйрь-әдипнең үсү баскычын күрсәтеп туарга тиешләр.

Ләкин бу үсү, тормыштагы бик күп күренешләргә, вакыйгаларга бәйләнгән кебек үк, кемне яратып укуына да, төрле әсәрләрнең йогынты ясауларына да бәйләнгән. Шагыйрь-әдипләргә, җәмгыятьнең сәяси-иҗтимагый, икътисади яклары белән бергә, төрле заманның төрле китаплары да киң тәэсир, күп материал бирәләр.

Пушкин рус әдәбиятына зур үзгәреш кертте. Ул үзенең теле белән — халык телендәгечәрәк язылган җәүһәрләре белән — рус әдәбиятында яңа бер чор башлады. Әдәби мәктәп тудырды. Лермонтовлар аны үстерделәр.

Шулай ук Тукай да.

Тукай рус әдәбиятына тотыну белән үк, тәрҗемәләрендә дә, оригинал әсәрләрендә дә үзенең тел-эслүбен бик тиз үзгәртте. Гаммә теленә таба борылыш ясады. Төрек тәэсиреннән ычкынып, рус әдәбияты тәэсиренә бирелде. Бу күренеш — яңа туып килә торган әдәбиятта бик еш очрый торган хәл.

Тик шунсы бар: Тукай русның бер генә язучысына да иярмәде, бәлки рус әдәбиятыннан үзенең эчке рухына, татар тормышына якын була алганнарын гына, яки үзе шуларны хис итеп, алардан тәэссорат алып, аларны яңадан бер кат тудырып, якын итә алганнарын гына сайлап, чүпләп алды, шуңа күрә дә Лермонтовның:

> Я оплеван, я и бит,
> Но все храню свой гордый вид

лары, Пушкинның:

> Великим быть желаю,
> Люблю России честь;
> Я много обещаю,
> Исполню ли — бог весть

лары белән бергә, башка шагыйрьләрнең:

> Вечерный звон, вечерный звон,
> Сколько дум наводит он...

лары,

> Погиб я мальчишка,
> Погиб навсегда...

лары Тукайда, бер караганда, чуарлык та тудырдылар. Ләкин ул, кемдер әйтмешли, «тәкълит ителә алмаслык тәкълитче» иде. Чөнки ул монда китерелгән үрнәкләрне дә башкалардан үз заманына, үз тормышына ягымлы итеп ала белгән.

Я ул «беттем мин яшь малай, беттем гомергә дә», дип турыдан-туры алган... я булмаса:

> Кичке азан, кичке азан,
> Моңнар, уйлар килә аннан...

яки:

«Телим булырга мин инсани гали»,—дип уңайлабрак та алгалаган.

Димәк, Тукай, хәзрәте Пушкин, Лермонтовлардан үрнәк алып, үзенең иҗатын баеткан, өйрәнчек каләмен шомарткан һәм Пушкиннарның бу тәэсире Тукайның тел-эслүб якларын гамәлләштерүдә дә кечкенә урынны тотмадылар диясем килә. Бәлки минем бу карашыма каршы чыгучылар да булыр... Ләкин монда күрсәтелгән һәм күрсәтелми калган бик күп дәлилләр әнә шушы югарыдагы фикерне куәтлиләр. Хәтта Тукайның садәлеккә, халык теленә күчүе рус әдәбиятын укыган саен, өйрәнгән саен көчәя генә барды дияргә дә мөмкин.

Бу киң тәэсир Тукай шигырьләренең техникасында да, төзелешләрендә дә нык сизелә. Аның шигырьне оста башлап, осталарча тәмамлавы күп җирдә Пушкин кебек мастерларны яки Пушкинның мәктәбен хәтерләтә.

Моңар мисал итеп Лермонтовның «Сосна»сы белән Тукайның «Чыршы»сын чагыштыру да җитәр дип уйлыйм. Яки Тукайның:

> Кыш, буран, салкын һава, яфрак кадәрле кар төшә...
> . . . .
> Шул вакыт мәчет катында дөм сукыр бер карт тора..
> . . . .
> Бирсәгезче бер тиен тик, тәңкә түгел бит, тиен!..—

дигән юллы «Теләнче» шигырен һәм русның халыклашып беткән:

> Зима. Метель. В охлопьях снега
> Старушка божья стоит.
> Лишилась голоса и зрения,
> Подайте ж христа ради ей...—

дигәнен бергә карап чыгу да житә. Ләкин Тукай, «Телим мин булырга...»ларын күрсәтмәгән кебек үк, монысын да русчадан дип күрсәтмәгән. Болар тәэсир чишмәләре. Алар кайбер вакытта техника, форма ягыннан гына түгел, хәтта фикри яктан да шагыйрьне тезгенлиләр.

Тукай күп җирдә моңардан ычкына алмады. Ләкин ул аннан бик матур иттереп файдалана белде. Кирәк җирдә тәрҗемә дә итте, тәкълитче дә булды, үзләштерде дә, файдаланды да.

Иртә туып, иртә үлгән талантлы шагыйрь Г. Тукайның иҗатында татар тормышы белән аһәңләшә алган әнә шундый мотивлар да булды. Бу бер аңарда гына түгел, башка танылган язучыларыбызда да, соңгы чор язучыларында да бар.

Анысы турында икенче бервакытта тукталырбыз.

1928

ХӘЙДӘР ФӘЙЗИ

Моннан берничә ел элек (1923 нче елны бугай) миңа элекке татар театрында үзен озын язучы дип тәкъдим иткән озын буйлы, ябык йөзле, сабыр табигатьле бер иптәш белән танышырга туры килде. Без икебез дә «Адашкан күңел»гә керә алмыйча контрамарка артыннан чабып йөри идек. Сез кем буласыз диюгә, ул:

— Мин әнә шушы «Адашкан күңел» пьесасының авторы Мирхәйдәр Фәйзи булам,—диде.

Мин моңар ышанмадым... Ничек ул алай? Үз әсәреңне куйсыннар имеш тә, мин шуны карарга керә алмыйм имеш. Шулай да мин бу икеләнүемне яхшырак белү өчен, спектакль беткәч тә:

— Автор! Автор!—дип кычкырырга тотындым. Тавышка кушылып акыручылар күп булды, һәм озак та үтмәде, әлеге иптәшем, сәхнәгә чыгып, ояла-ояла башын ия башлады.

Әйе, бу иптәш татар әдәбиятында исеме танылган, вакытында үзенең «Галиябану»ы белән татар театрын шаулаткан шагыйрь-драматург Мирхәйдәр Фәйзи иде. Чынлап та аның шәхесе, тормышы ничектер читтә, кы-

рыйда,— башка язучылар белән, каләмдәшләре белән аралашмыйча яшәргә ярата торган иде. Бу каләмдәшләре белән генә шулай. Ул бәлки моны үзен язучы иттереп күрсәтергә теләмәүдән генә эшли торгандыр, чөнки аның авыл яшьләре арасында йөрүен, эшче яшьләр белән бергә йөреп, алар белән бергә көлеп, шаярып, алардан «сабак алуы» турында хатларында бик еш күреп була иде.

Хәйдәр ага (ул соңгы елларны үз исемен Хәйдәр дип кенә йөртә иде) 1892 нче елны хәзерге Башкортстанның Җалер кантонында Күкшел утарында туа һәм 16 яшьләренә чаклы байда хезмәтчелектә булып торган атасында тәрбияләнеп, үзенә хезмәт мәйданы эзли. Бу мәйданны ул әдәбияттан таба, һәм 1911 нче елны 19 яшьлек мөхәррирнең «Чәчәкләр арасында» дигән тәрҗемә әсәре басылып та чыга.

Театр аның иң яратып эшләгән хезмәт мәйданы иде. Ул, шигырьләре белән беррәттән ук, монда да моңлана, монда да авылның көнкүрешен җырлый, аннан алып матур-матур сурәтләр тудыра.

Драматургия бабында ул барлыгы 15 пьеса тудыра, алар арасыннан сигезе басылып таралып, төрлесе төрле җирдә сөелеп куелып йөри. Ул 16 нчы елны татарның музыкаль әсәрләренә ата булган һәм бу мәйданда беренче итеп «Галиябану»ны яза. Әнә шуннан соң гына «Яшь йөрәкләр», «Сүнгән йолдызлар» кебек музыкалы әсәрләр туа башлады. Хәтта «Галиябану»да бирелгән Хәлил, Исмәгыйль типларын «Галиябану» энеләре булып туган башка пьесаларда да күрергә мөмкин.

Хәйдәр ага әдәби материалның күп өлешен авылдан ала иде. Ул моны үзенең шигырьләрендә дә җырлый. Авыл комсомоллары белән бергә ул, чәчендә күренгән энҗе бөртекләренә карамастан, үзен дә комсомол дип атый. Моны аның балалар өчен язылган «Коммунага» дигән шигъри пьесасында да күреп була.

Хәйдәр Фәйзи үзен яңарту нияте белән Урал буе эшчеләре арасына эшкә китә. 23 нче елларны ук сәламәтлегеннән зарланган сабыр язучы онытылып эшкә керешә. Бакыр кою приискаларындагы үзәк эшчеләр көтепханәсен ныгыта, яна чыккан китаплар белән баета. Көтепханә эшеннән башка эшче яшьләр арасында төрле

түгәрәкләргә катнаша. Күңеле күтәрелә, шатлыгы арта... Хатларында да:

«...Эшчеләр арасында яшәү минем өчен зур мәктәп булды. Монда яңа «Галиябану»ларны тудырып була. Ашыкма, Кутуй, ашыкма — монысын да язарбыз, монысын да җырларбыз...» дип, яңа «Галиябану»ларны тудырырга ашкынган иде. Ләкин 20 ел буенча әдәби хезмәтләр өстендә утырган үпкәләр тагын да какшый төшәләр. Үпкә туберкулезын Кырым да, Мәскәү дә бетерми, Хәйдәр ага үлә. Ул үзенең соңгы сулышларын да Баймакта эшчеләр арасында сулый. 9 нчы июль көнне җисмән аның соңгы көне була.

1928

АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫНДА «ГАЛИЯБАНУ»

Моннан 13 еллар элек татар театрын шаулаткан, татар әдәбияты тарихында үзенең мактаулы кыйммәтен алган «Галиябану» хәзерге яңа тамашачы, совет тамашачысы өчен дә ят түгел, якын әле.

«Галиябану»—Хәйдәр Фәйзинең үз әсәрләре арасында да, башка драматургларыбызның пьесалары арасында да яктырып торган бер йолдыз ул. Аны үзеннән соң сәхнәгә менгән бик күп татар пьесаларының атасы дип була. Ул бездә:

— Беренче музыкалы әсәр.

— Мөндәриҗәсе дә беренче иде.

— Типлары да үзенә охшаш Хәлилләр, Галияләр, Исмәгыйльләр — прототиплар тудырды.

«Галиябану» белән татар драма әдәбиятында, Галимҗан Ибраһимов теле белән әйтсәк, яңа мәктәп башланды. Шуңа күрә дә Академия театрында аның спектакльләрен яңарту — тамашачының соравын ишетү дигән сүз.

Хәйдәр аганың үлүенә ярты ел тулганда, Шопенның матәм маршы, атаклы Салих Сәйдәшевнең увертюрасы белән без яңадан:

Галиябану, сылуым иркәм... —

дип «Галиябану» пьесасын карый башладык.

Бу пьесаны куймаган режиссер, уйнамаган артист юктыр. Кариев башлап жибәргән, Мутин да уйнаган. Тинчурин да иҗат иткән, Тарханов, Вәлишин, Синяевлар да булган. Айдаров, Шамильскийлар да типлар биргәннәр.

«Галиябану»да исем алганнар, анда артистлар үскән.

Соң ничек шундый юлларны кичергән, шундый исемнәрне күргән «Галиябану» бүгенге куелышларында үзгәргәнме? Берәр яңа нәрсә өстәлгәнме? Дөресен әйтергә кирәк, бик аз, аз... ләкин кыйммәтле.

Сәйдәшев тарафыннан язылган увертюра, һичшиксез, аңа зур өстәмә. Аның увертюрасы пәрдә ачылмас борын ук бөтен пьесаның аһәңен сөйләп бирә. Скрипка тавышы йөрәктән чеметә — Галия елый... Гармонь өстәлә — авыл яшьләре Галиябану көен җырлап узалар. Кларнет шыңшып ала. Хәлил сөйгән яры янына килә, гобой акырып куя — Исмәгыйль арага керә... Бакыр инструментлар күтәреләләр, дулыйлар, өермә күптаралар, виолончель үкси, Галияне мең сумга саталар... тирән тынлык... тагын шыңшу, тагын скрипка, тагын елау, Хәлил үлә.

Сәйдәшев кул астында телгә килгән музыка әнә шуларны сөйли. Алдагы куелышларда бу тел тагы да ачылыр, тигезләнер, нәфисләнер. Оркестрга гармонь кертү — Европа музыкасына хезмәт массасының телен кертү бит ул.

Икенче, Девишев белән Сперанский тарафыннан эшләнгән оформление спектакльнең тышкы калыбы, бизәге. Кечкенә генә сәхнәдә чын тормыштагыча, өй, ишек алды, су буйлары күренешләрен бер йомгакка җыеп бирү өчен бик күп нечкәлекләрне белергә кирәк. Авыл да булсын, театр да булсын, чын да булсын, нәфислеге дә күренсен, тулылыгы да югалмасын. Рәссам Сперанский кабыктан ясалган өйләр белән әнә шуларны эченә алып, тормышчанлыкны биргән.

Саф һәм матур! Очсыз, ләкин кыйммәтле! Спектакльнең башка яклары турында (Исмәгыйль ролендәге Шамильскийны искә алмасак) өстәмәсез генә тукталып була. Галия ролендәге Кушловскаяны да Шамильский рәтенә кертәбез. Алар спектакльнең үзәге булып, ике тормышның көрәшүен бирделәр. Аларда, алар күрсәткән типларда, Хәйдәр Фәйзинең елавы да, ачуы да

күренде; Галиягә булган мәхәббәте, Исмәгыйльгә булган ачуы гәүдәләнде. Шулар аша без ярлының зарын, кулакның «мин Исмәгыйль» дигәнен ишеттек һәм сиздек.

Шамильский белән Кушловская Фәйзилекне күрсәттеләр. Әбҗәлилов (Бәдри), Сәлимҗанов (Хәлил) соңгы пәрдәләргә таба гына спектакльнең гомуми аһәңенә керә башладылар. Кем соң ул Бәдри? Кызын байга бирергә тырышучымы? Ни өчен байга? Кем ул Хәлил? Галияне яратып йөрүче бер мескен, бәхетсез егет кенәме? Әллә Исмәгыйль кебек үк авылның берәр катлавын күрсәткән гомуми бер тип тамы? Әбҗәлилов белән Сәлимҗановның уеннарында без менә шундый сорауларга тулы җавап таба алмадык. Мин амплуасызлыкны бик яратам. Ләкин аның да чиге бар. Кичә «Югалган матурлык» * та үзәк булган, үзенең уены белән кайнар мәхәббәт калдырган Сәлимҗанов бүген тамашачыга кимрәк житте. Яшь талантны мондый нагрузкалардан бушатырга кирәк. Кугушева, матур уенына карамастан, җәй көне «Галиябану» авылында йөреп, ничектер, салкын тидергән. Состав житмәгәнгә, монысын «условный» дип алсак та ярар.

Инде тавыклар?

Алар артист та түгел, алар театр мәхәббәтен дә күрмәгәннәр. Шуңа күрә алардан әллә нәрсә сорап та булмый. Тик бары, тавыклар реализмга пародия иде дип кенә бетерәбез.

1929

САЛИХ СӘЙДӘШЕВ ҺӘМ ТАТАР МУЗЫКАСЫ

Татар музыкасының елдан-ел үсә баруы аерып ала алмаслык рәвештә Салих Сәйдәшев исеме белән бәйләнгән. Бу яшь композитор һәрбер яңа әйбер биргән саен үсә, ныгый, канатлана гына бара.

Ул үзенең хәзерге хезмәтләре белән дә нык танылды инде. Аның музыка әсәрләре радио, театр, концерт кичләре аркылы Советлар иленең ерак почмакларынача

* Һади Такташ драмасы.

җәеләләр. Вильом исемендәге мәшһүр Дәүләт квартеты Сәйдәшев музыкасын Европаның иң атаклы композиторлары белән берр әттән уйнап йөри.

Моның белән татар музыкасы тарихында яңа бер сәхифә ачыла.

Сәйдәшев үзенең иҗатын башкалар кебек уртадан, әллә кайдан башламыйча, иң җиңеленнән алып китте. Ул, аерым җыр, мелодия, балетлар аркылы, музыкаль пьесалар белән опералар таба атлый.

Бу юл ышанычлы һәм өметле юл! Сәйдәшев гармониясе татар халык музыкасын өйрәнү, тикшерү нәтиҗәсендә килеп чыккан, Европага башка үзенә бер музыка мәктәбе тудырып бара. Ул яшь вакытларында ук саф халык моңын тыңлый, авыл көйләренә колак сала, аның чын табигый җырчыларын ишетә. Музыканы этнография хәлендә күрә, гаиләсеннән яшеренеп, Иванова дигән бер музыка укытучысына йөреп, шул көйләрне рояльдә чыгарырга тырыша, Заһидулла Яруллин кебек саф халык моңнарын уйнап йөргәннәрдән дә сабак ала. Еллар үтү белән, аның бу укытучылары Корбут, Родзевич, Бормусов кебек профессорлар белән алмашыналар.

Талант, музыка белеме белән сугарылып, мастерлык ала; Сәйдәшев эшкә керешә.

Ул 1918 нче елга чаклы укып, 17 яшендә №... армиясенең сәяси бүлеге белән Оренбург, Төркстаннарга барып чыга. Тормыш бөтен гәүдәсе белән аның күз алдына баса. Шатлыклы минутлар белән ачлык, ялангачлыкны да күрә, татый.

Болар аның музыкасына Сәйдәшев өчен иң характерлы булган моңлык эзләрен салдылар. Кайгы, матәм көйләреннән алып, шатлык симфонияләренәчә иҗат баганалары, музыка баскычлары торгыздылар.

Татар музыкасы композитор иҗатында телгә килде.

1922 нче елны инде без Сәйдәшевне татар театрында күрәбез.

Әле дә хәтерлим. Артист Сакаев үлгән көн иде. Театрда зур тынлык. Тик күрше бүлмәдән Таждарованың үксеп-үксеп елаган тавышлары гына ишетелә. Тинчурин авыр уйга баткан. Сәйдәшев кечкенә генә бер кәгазь өстендә авыз эченнән өзек-өзек тавышлар чыгарып нидер сызгалый. 5 минут вакыт үткәнмедер, юкмы, бәлки алай да үтмәгәндер, Сәйдәшев:

— Бетте,— диде.

Бу минем өчен театр эчендә кайгылы, аһ-зарлы күренешләр вакытында күргән минутлар көндәлек дәфтәремнең матур бер сәхифәсе булдылар. Әнә шулай Сәйдәшев үзенең мәшһүр матәм маршын тудырды.

Чылтырап аккан дулкынлы тавышлар үлем орлыгы белән яшәү шатлыгын, яшәү кыйммәтен сөйләп бирделәр.

Сәйдәшевнең музыка адымнары — кыюлы адымнар. Ул оркестрга масса теле булган гармоньны кертү, тирән художестволы әсәрләр бирү белән бергә, революциячел музыка бабында да хезмәт күрсәтте инде. «Наемщик» музыкасы шунын беренчесе иде.

Бүген исә ул тагын бер җиңү күрсәтте. Әгәр дә физиклар съездына килгән академик Иоффе һәм немец профессорлары Сәйдәшев музыкасын Европа музыкасы белән бер дәрәҗәдә күреп тәкъдир итсәләр, бүген без аны революциячел композитор дип тәкъдир итәбез.

Сәйдәшев Кызыл Армиянең XI еллыгы исеменә яңа марш язып, аны татар полкына бүләк итте. Марштан алган тәэсирне каләм белән генә әйтеп булмый...

Өзелмәслек алкышлар яуды... Ура күтәрделәр... Әллә ничәмә тапкыр тәкрарлаттылар, шатлык татар театры бинасына сыймады, кызыл казармаларга күчте.

Сәйдәшев бу хезмәте өчен татар полкынын почетный кызылармеецы итеп сайланды.

Тиз көндә Татиздат тарафыннан чыгарыла торган Сәйдәшев ноталары үсеп барган татар музыкасына тагы да бер зур өстәмә булыр диясе килә.

1929

БОЛАЙ ЯРАМЫЙ

Соңгы вакытларда татар совет язучылары алдында, барыбызның да башын ваткан иң зур омтылышларыбызның берсе булып, зур әдәбият тудыру мәсьәләсе тора.

Без күпне җиндек. Без вакыты белән чәнечкеле чыбыркы адымыннан да уза алмаган бик ярлы тәнкыйть белән генә булса да, идеология уңышлыгына ирештек. Тел, эслүб, формада да үзебезне иркен хис

кыла башладык. Кулга каләм тотарга өйрәндек. Инде хәзер күргәненне, белгәнеңне сурәтләндерергә, тормыштан алган куе буяуларны зуррак романнар, озын хикәяләр хәленә китерергә генә калды.

— Бары шул гынамы?

Юк, татар совет язучылары алдында тагы да, бәлки моннан да зур, моннан да җаваплырак бурычлар тора. Менә бу зур әдәбиятны тудырыр өчен аның башка тармакларын да тудырырга кирәк.

Һичбер халыкның, һичбер сыйныфның, һичбер заманның әдәбияты да үзенең тармакларыннан аерылып, ялгыз бер атау булып кына үсми... һәм үсә дә алмый.

Бездә халык әдәбияты кебек өйрәнелмәгән хәзинәләр, юмор-сатира кебек көн тәртибенә этәрелмәгән мәйданнар, журналистиканың иң мөһим, иң көчле баганаларыннан саналган фельетон, очерк кебек жанрлар татар язучыларыннан читтә, файдаланмыйча торалар әле.

Бездә, хәзерге татар язучылары арасында, көндәлек мәсьәләләр буенча язучы, шуларны күтәреп чыгып җәмәгать фикере алдына куеп баручы публицистлар юк. Икенче төрле әйткәндә, рус әдәбиятын үстерүдә чиксез зур хезмәт күрсәткән Белинский, Герцен, Чернышевский, Писарев, Добролюбов, Кольцов кебек язучыларыбыз юк...

Безнең татар язучылары арасында газета-журналистика эшеннән янгыннан качкан кебек качу да бар. Имеш, ул исеме танылган язучы, мәшһүр шагыйрь, газетага мәкаләләр язып, хәбәрче булып, каләмен бозсын. Язса да бары тик матур әдәбият турында гына яза. Шигырь житешми икән:

— Мә, рәхим итеп баса бир, әмма мәкалә көтмә,— диючеләр дә бар. Бу сүзләрне бүгенге көннең әһәмиятен, җитдилеген аңламаган кешеләр генә әйтә алыр.

Хәзерге язучы көндәлек мәсьәләләр белән нык танышып барган вакытта гына заман соравын үти ала. Газета-журналистлык эше аны шуның белән таныштыра. Мин моны урыннардан килгән хәбәрләрне төзәтеп утыру мәгънәсендә түгел, бәлки фельетон, очерк, газета сыйдырган типлар, новеллалар бирү, яңа мәсьәләләрне, яңа мәүзугъларны[1] күтәреп чыгу кин-

[1] Мәүзугъларны — темаларны.

легендә алам. Язучы гадәттә хәбәрче күрә алмаган, тота алмаган күренешләрне күрә. Ул 15 юл белән генә аңлатып узган һәм укучы күзеннән югалыр дәрәҗәгә житкән вак хәбәрне дә әһәмиятле итеп күпертә ала. Журналист-язучы вакыйганың тышкы ягын гына күрсәтмичә, вакыты белән укучыны сискәндерерлек дәрәҗәдә көчле итеп вакыйганың эчке ягын да тасвир итә. Шунын аркасында ул үзенең теге әдиплек ижатына да чиләкләп-чиләкләп азык ала. Ләкин, кызганычка каршы, безнең язучыларның моңар ирешә алганнары юк әле.

Соңгы айларны «Кызыл Татарстан» битләрендә татар пролетариатын үстерү, яңалиф, сәнәткә каршы, прогуллар белән көрәш, мәчет, чиркәүләрне аң-белем йортларына алу, татарлардан гыйльми көчләр житештерү... һәм башка шуныңише бик күп кампания, вакыйгалар күтәрелеп узды. Ә соң шуларның берәрсе турында гына булса да, татарның берәр танылган яки таныла башлаган язучы шагыйре үзенең сизгер күңеле, укучыны тиз ышандырырлык матур теле белән берәр сүзен әйттеме? Юк, әйтмәде, хәтерләмим.

Инде шушы вакыйгалардан читтә торгачтын, аларны үзеңнең ижат кярханәңә[1] кертмәгәчтен, ничек иттереп хәзерге заманның һәм сәяси, һәм мәдәни, һәм хуҗалык сорауларына җавап бирерлек әсәрләр, җәүһәрләр тудырырга кирәк.

Менә бу мисаллар язучыларның колак салып, журналистика мәйданының ничаклы әһәмиятле бер мәйдан икәнен аңлауларын сорый.

Европа әдәбиятының иң бөек талантлары да әнә шул журналистика мәйданыннан үстеләр. Монда Горькийны да, Синклерны да мисалга китереп булыр иде.

Соң нишләргә кирәк?

Минемчә, хәзердән үк зуррак газета идарәләре үзенең тирәсенә татар язучыларын туплап, шул турыда (редакция эчендә) фикер алышуларны кузгатырга тиешләр.

Татар мәдәнияте йорты каршында яки «Кызыл Татарстан» редакциясенең үзендә, журналистика семинариясен оештырып, тәртипле рәвештә шунда эш, беседа, доклад, лекцияләр алып барылырга тиешле.

---

[1] Кярханәңә — лабораторияңә (фабрика) мәгънәсендә.

«Безнең юл», «Яңалиф» журналларында очерк, фельетон һәм гомуми журналистика турында назари[1] тикшеренүләр, тәҗрибәләр эше кузгалырга тиеш һәм башкалар.

Язучы иптәшләр моңар колак салырлар дип уйлыйм.

1929

ЯЗА БЕЛЕП ЯЗЫГЫЗ!

Газетада, журналда, шигырьдә, хикәядә һәм, гомумән, бөтен кешелек дөньясында сүз иң зур урыннарның берсен тота. Үзенең төп мәгънәсенә җавап бирерлек рәвештә урынлы кулланылган сүз фикергә җиңеллек китерә, уйның, максатның ачык булуына ярдәм итә. Уйлап әйтелгән, уйлап китерелгән сүзләр ике төрле мәгънәнең килеп чыгуына урын калдырмыйлар.

Ләкин, кызганычка каршы, безнең бик күп язучыларыбыз моңар аз игътибар итәләр. Газета-журналларыбызда басылып килгән бик күп мәкаләләр, шигырьләр, хикәяләр, хәбәрләр ничек әләкте шулай язылалар. Урынсыз сүзләр кулланыла. Күптән түгел генә әле «Кызыл Татарстан» газетасында бер милиционерның бер хатынны кыйнавы турында хәбәр басылган иде. Ләкин шул хәбәр, җөмләнең ялгыш язылуы аркасында, милиционер түгел, бәлки киресенчә, хатын милиционерны кыйнаган мәгънәне аңлата. Шушындый кирле-мырлы нәтиҗәләрне бездә бик еш очратып була. Бу бәладән татарның танылган карт язучылары да котыла алмыйлар; котылырлар иде, сүзгә, җөмлә төзелешләренә кирәгенчә әһәмият бирмиләр.

Һәрбер сүзнең аерым мәгънәсе, аерым табигате бар. Хәтта язучының нинди сүзләрне алуына карап, аның идеологиясен дә билгеләргә мөмкин. Шулай ук сүзләрне, аларның табигатьләренә, эчке мәгънәләренә карап, дөрес китерү аркасында укучыга йогынты да ясарга мөмкин. Мәсәлән, берәү җыелыш турында хәбәр яза. Җыелышны мактый, ә үзе ахырдан гына: «Клуб залы яртылаш буш иде»,— дип куя. Укучы: «Ә... клуб буш булган икән», дип кала. Шул җөмләне: «Клуб залы

[1] Назари — теоретик.

яртылаш тулы иде»,— дип куйсаң, бөтенләй башка бер иогынты ясала.

Менә шуңа күрә дә без язучыны әдәбият-матбугат заводында эшләүче бер эшче итеп таныйбыз. Газета җыйганда хәреф җыючы тиешле хәрефләрне җыярга, эшче үзе эшләп чыгара торган товарны нәрсәдән, ни белән һәм ничек эшләргә тиешлегенә игътибар итсәләр, язучылар да сүзнең, җөмләнең урынлы-урынсыз алынуына күңел бирергә тиешләр.

Укучыларыбызга бу мәсьәлә аңлашылсын өчен, «Авыл яшьләре» журналының үткән 4 нче санынна кайбер мисаллар да китереп узабыз.

Язгы кояш сөеп иркәгән көй
Кырлар кайный — кырлар тилергән.
Кем шул вакыт кырлар сулый белән
Чыңнашалар корыч — тимерләр.

(М. Сөндекле шигыре.)

Татар телендә «иркәгән» сүзе юк; «иркә», «иркәлә», «иркәләгән» сүзләре генә бар. Шагыйрь монда үлчәүнең тигезлеге өчен бер сүзне бөтенләй ватып, җимереп ташлый. «Иркәгән көй кырлар кайный...» бер-берсенә бәйләнмиләр. «Кырлар сулый белән чыңнашалар корыч — тимерләр» бөтенләй мәгънәсез булып чыкканнар. Кем сулый? Кырлармы әллә башкамы? Әллә юкса корычлармы «сулый» белән чыңлашалар? Аңлашылмый. «Сулый» урынына «сулы» алсагыз да, барыбер мәгънәсезлек килеп чыга.

Без үтәсе юллар ерак әле,
Без житәсе җирләр — таң кебек!

(Әбүзәр Түрәй шигыре.)

Түрәй монда без житәсе җирләрне таңга чагыштыра. Бердән, танга житеп булмый, икенчедән, таң ул һәр көн ата һәм һәр көн бетә. Димәк, без ул «житәсе» (Түрәй үзе шулай ди!) җирләргә бервакытта да житә алмабыз. Начар мәгънә килеп чыга. Аннары Түрәй кулланган «таң», «диңгез», «тау» бик иске сүзләр, иске сурәтләр. Аларны яңарак итеп алырга кирәк иде.

Ташкын боздай ташынып ачу килә,
Илебездә җуп яшерен ноемнәр.

. . . .

Исерек хулиганны, бюрократны
Бергә бәйләп букет ясадым...

(Әюв Гәрәй шигыре.)

Ачу бервакытта да «ташынып» акмый, акса да «ташкын булып» кына килә дияргә мөмкин. Ташыну сүзе бер җирдән икенче җиргә күчү, әйберләр ташып йөрү мәгънәсендә генә кулланыла. Ә бу шигырьдә ул урынсыз. Исерек хулиганнардан, бюрократлардан букет та ясап булмый. Букет бит ул хуш исләр аңкытып торган матур һәм сокланырлык бәйләм рәвешендә йөри. Ә монда ул начар бер күренешне күрсәтергә, шул күренештән әче рәвештә көләргә теләгән шигырьнең көчен югалта. Хулиган чәчәкләрнең дә булганы юк бит!

Бу мисаллар сайланмыйча, тикшерелмичә алындылар. Эзли башласаң, хәтта эзләмәсәң дә, аларны бик күп табып була. Бу хәл безнең язучыларыбызның нәфис сүз өстендә эшләмәүләрен күрсәтә. Сүзгә әһәмият бирергә кирәк, чөнки урынлы кулланылган сүз — ул мәгънә дә, идеология дә, ул матурлык та.

Язучы үзенең сүзлеген баетырга тиеш. Моның өчен куе гаммә эчендә яшәргә кирәк. Язучының сүзгә бай булуы, язган чакта күп сүзләр алуы аның тормыш белән яхшы таныш икәнлеген дә күрсәтә.

1929

ТАТАР СӘХНӘСЕНДӘ ОПЕРА

Опера — матур сәнгатьнең иң югары дәрәҗәдә торган ноктасы. Сөйләү урынына сәхнәдә җырлап кына уйнарга яраклы итеп язылган музыкаль әсәргә опера дип әйтәләр.

Операның төп кыйммәте дә уен яки сүздә генә булмыйча, музыканың үзендә була. Моңарчы безнең опера мәйданында бөтен ягы белән дә канәгатьләндерерлек дәрәҗәгә җиткән пролетариат операсын күргәнебез юк әле. Шулай да рус композиторлары тирәсендә совет пролетариат операсын тудыру юлында уңышлы гына адымнар да бар инде.

Буржуа тәнкыйтьчеләре һәм буржуа сәнгатьчеләре башта бу мәсьәләгә шаккатып карадылар:

— Драмага да пролетариатны керттегез, шигырь-хикәяләргә дә пролетариатны керттегез. Инде музыкага аны ничек кертергә телисез? — диделәр.

Без бу карашның тәнкыйтьтән түбән икәнлегенә авторитетлы иптәшләрнең әсәрләреннән өземтәләр китереп тормыйбыз. Музыка өлкәсендә әле нәни бала булган татар музыкасы — «Эшче» операсы белән генә җавап биреп китәбез.

Без татар операсына кагылган вакытта да иң беренче сүз итеп операда да, музыкада да һәрбер сыйныфның сәясәте, идеологиясе бар дибез. Музыка ул күңел ача торган нәрсә генә түгел, бәлки шулай ук тормышны төзүдә ярдәмче булган матур сәнгатьнең югары бер нечкәлеге дибез.

Билгеле, революциягә чаклы татарларда опера тууын уйларга да, хәтта ул турыда хыялланырга да мөмкин түгел иде. Ул чорда опера түгел, гармонь да әле кирәгенчә мунчадан чыкмаган иде. Тик бары революция алдыннан гына без «Беренче чәчәкләр», «Галиябану» шикелле драма әсәрләренә, операга башлангыч итеп, музыка күренешләренең керүен күрәбез. Бу да әле бик аз микъдарда.

Революциядән соң культура фронтының бик күп өлкәләре чәчәк аткан шикелле үк, музыка өлкәсе дә чынчыннан чәчәк ата башлый. Бер яктан Совет власте яңа гына күтәрелеп, калкып чыга торган культура өлкәләренә зур иркенлекләр, мөмкинлекләр бирә, кызу темп белән барган тормыш, музыка капкаларын да киң итеп ача. Төрле җирдә һәм төрле шәһәрләрдә театр-музыка студияләре оештырыла. Мәйданга Солтан Габәши көйләре, Салих Сәйдәшевнең «Казан сөлгесе», «Сүнгән йолдызлар»ы, Х. Ибраһимовның хәзерге көнне бик түбән табылса да, вакытында музыкага этәреш биргән «Башмагым»нары калка.

Менә болар бар да татар операсына зәмин хәзерлиләр, һәм күп тә үтми, беренче татар операсын язарга тотынучы көчләр дә табыла.

Габәши, Виноградов һәм башка иптәшләрнең тырышлыклары нәтиҗәсендә, «Сания» операсы язылып бетеп, шул ук елның 25 нче июнендә Татарстанның 5 еллык юбилеена сәхнәгә дә куела.

«Сания» операсының язылып сәхнәгә куелуы бер Татарстан хөкүмәтенең генә түгел, бәйрәм чаткылары еракка җәелгән бөтен Советлар Союзының культура бәйрәме иде.

Чынлап та, революциягә «мунча музыкасы» белән кергән татар хезмәт ияләренең «бизгәкле» биш ел эчендә саны меңгә җиткән мәктәпләр ачуы, дәүләт театры торгызуы, матур сәнгать техникумнары ачуы һәм беренче татар операсын өлгертеп, шуны сәхнәгә менгезүе буржуа хадимнәренең: «Большевиклар — алар вәхшиләр, аларгамы көчле сәнгать тудыру?» — дип өрүләренә зур җавап иде.

«Сания» операсы турында рус-татар матбугатында да, чит ил матбугатында да күп язылып үтте. Татар укымышлыларыннан Гали Рәхим «Сания» операсындагы кан коюны яратып бетермәсә дә, операның үзе турында милли күзлектән карап шатлана-шатлана:

«Менә без «Сания» дигән татар операсын, хыялый романда уку урынына, Казанның опера театры залында утырып, күзебез белән күреп, колагыбыз белән ишетергә муафыйк булдык»,—ди.

Ләкин без Гали Рәхим шикелле милли күзлекләрдән карап, шатлык яшьләрен түкмибез. Без «Сания»ләрнең җитешүенә хезмәт ияләренең җимеше, Советлар иленең экономика, культура мәйданнарында киң адымнар белән алга баруы итеп кенә карыйбыз.

Музыка тәнкыйтьчеләреннән С. иптәш «Сания» куелгач: «Зур ышаныч белән әйтергә мөмкин ки, татар операсы Татарстан җөмһүриятеннән тыш та уңышлык казаначак», — дигән иде.

Профессор Бороздин «Сания» турында язылган мәкаләсендә, «Сания» операсының зур культура күренеше икәнен әйткәннән соң, түбәндәге сүзләрне язып үтә:

«Бу опера театр музыкасының стенографиясе генә түгел, бәлки опера композициясе хәленә җиткән музыка икәнлеген күрсәтә. Бу музыкада күп кенә психологик моментлар, бигрәк тә лирика моментлары яхшы бирелгәннәр, алар мелодиядә матур яңгырыйлар».

Шушындый ук рухтагы сүзләр башка галимнәр тарафыннан да язылалар. «Сания» турында, рәсемнәр, ноталар белән бергә, Берлинда чыга торган бер журналда да, «Таге Блат» кушымталарында да мәкаләләр чыга. «Сания» операсы турында Франция һәм Италия матбу-

ғатлары да тукталып үтәләр. Мәсәлән Италиядә, Римда чыга торган «Европа ориенталы» журналының 1925 нче ел, 31 нче октябрьда чыккан номерында татар музыкасы һәм беренче татар операсы турында 5 битлек зур гына мәкалә чыга.

«Сания» операсы Франкфурт-на-Майнеда бөтендөнья музыкасы күргәзмәсендә зур гына урынны ала. Бу турыда матбугатта болай дип язылa:

«Күргәзмәдә совет бүлеген меңәр-меңәр кешө карап уза. Совет экспонатлары арасында халыкны кызыксындырган нәрсә татар операсы «Сания» булды. «Сания» Татарстан җөмһүриятендә музыканың үскәнлеген күрсәтә. Немец матбугатында «Сания»гә яхшы урын бирелә».

Кыскасы, «Сания» операсының язылуы һәм сәхнәдә куелуы бөтендөнья музыка матбугатыннан башка гомуми матбугатта да җылы каршы алына. Бу турыда «Известия», «Правда» шикелле үзәк газеталарында да мәкаләләр басыла.

Әгәр дә 25 нче елны «Сания» операсы язылып беткән булса, быел инде без татар операсы дип кенә түгел, татар совет операсы дип тә сөйләшә алабыз. Быел, икенче татар операсы буларак, шул ук Солтан Габәши һәм Виноградов иптәшләр тарафыннан язылган «Эшче» операсын да күрәбез. «Эшче» операсы үзенең мөндәриҗәсендә эшчеләр тормышыннан алынып, пролетариат идеологиясенә якын килерлек дәрәҗәдә язылган.

Соңгы 3—4 ел эчендә татар совет музыкасы тагы да киңәйде. Салих Сәйдәшевнең «Зәңгәр шәл», «Наемщигы» һәм маршлары макталып үттеләр. Солтан Габәши һәм Виноградов иптәшләрнең, «Эшче» операсы өстендә эшләүләре белән бергә, бөтенсоюз күләмендә тәсдыйк ителгән «Яңалиф маршы» һәм башка аерым көйләре музыка өлкәсендә зур гына урынны алдылар. Менә болар бар да Татарстанда музыка театры тууында да, татар операларының арта баруларында да ышандырырлык үсешләр.

Быел инде без татар операларының бәйрәм уңае белән генә түгел, бәлки хәзерге Татар дәүләт академия театры каршында булса да, музыкальный сезон төсендә куелуларын күрәбез. Январь аеннан башлап Академия театрында татар операсы сезоны башлана.

«Сания» операсы берничә мәртәбә куелгач та: «Эшчеләр операны яратып карадылар, мактап, канәгатьләнеп киттеләр», — дип язган хезмәт ияләре беренче январь сезонына тагы да игътибар биреп караячаклар.

1929

МИНЕМ ФАҖИГАМ *

Партия Үзәк Комитетының соңгы Ноябрь пленумы югары мәктәпләрнең тормышына моңарчы күрелмәгән зур борылыш ясый. Бу борылыш үткән елгы Июль пленумында ук билгеләнсә дә, быел ул кызу кискенлек ала.

Бу карарны тормышка уздыру, югары мәктәпләрдә чын-чынлап революция ясау, югары мәктәпкә социализм тормышын кертү дигән сүз. Югары мәктәпне сыйнфый нигездә совет белгечләре хәзерләп чыгара торган белем фабрикасына әйләндерү дигән сүз.

Әйе, мин дә бит кайчандыр студент идем. Менә пленум карарларын өйрәнеп утырган чакта, студент булып йөргән елларым, бик күп елларым искә төште. Югары мәктәпләрдәге хәзерге борылышны ачыграк аңлатыр өчен, мин аны сезгә дә сөйләп узмакчы булам.

Ул студентлык чагымны мин «Минем фаҗигам», дип атыйм. Чөнки хәзерге борылыш белән чагыштырганда, аны башкача атарга мөмкин түгел.

Мин башта политехник институтта укыдым. Инженер булырга теләдем. Иртәдән алып көндезге сәгать икегәөчкә чаклы лекцияләргә йөрдем. Ә кич белән төрле түгәрәкләр, концерт ясаулар, газет чыгарулар, кыскасы, һәр көн саен нинди дә булса җыелыш, утырыш булмыйча калмый иде.

Башта ике-өч ай лекциягә йөреп карагач, бернәрсә дә аңламаганымны сизеп, мин дә, башка иптәшләрем кебек үк, лекциягә йөрүдән туктадым. Чөнки профессорның

* «Минем фаҗигам», «Журналист хаты» мәкаләләрен, «Алар өчәү иде» исемле очеркны редакциягә Р. Нуруллина тапшырды.

лекциясен беребез дә аңламый идек. Гомер дә күрмәгән, белмәгән нәрсәләрне күрмичә, шуның арасында булмыйча, шулар белән тәҗрибә ясап карамыйча, лекциядән генә аңлау мөмкин түгел иде. Лекция залларында соңга таба йөз-йөз илле кешедән бары ике-өч кенә кеше кала башлады. Ә профессор һаман сөйли, һаман укый. Чөнки ул үзе дә—лекция ул бары форма гына, зачетны китаптан укып, лекция тыңламыйча гына да бирергә мөмкин икәнлеген белә иде.

Менә бер вакытны зачет вакытлары, зачет бирү сессиясе килеп житә. Кыш буе бернәрсә дә аңламыйча лекция тыңлап йөргән студентлар төн-көн йокламыйча зачет хәзерләргә керешәләр. Бер кочак китаплар алып, кайсы ятлый, кайсы укып чыга, ә кайсы өстән-өстән генә караштыргалый, һәм атна саен бер зачет бирә башлый. Ә профессор бер атна эчендә генә өлгергән специалистның зачет дәфтәренә бер дә исе китмичә «зачтено» дип яза. Чөнки — зачет ул форма гына, традиция буенча күптән шулай килгәнен яхшы белә. Студент шатлана да, кайгыра да. Ул бер зачет бирдем, анысы яхшы, әмма ни өчен мин җүләр баш бер атнада әзерләнә торган фәнне кыш буе тыңлап йөрдем, ди. Икенче зачетны биргәнче студентның беренче зачеты баштан чыгып, җил белән бергә очып китәргә дә өлгерә инде.

Шулай итеп мин дә зачет арты зачет бирдем. Ләкин институтны бетергәндә минем башымда интеграл, геодезия, машиностроение, органик химия, физика, на плоскости, в пространстве исемнәреннән башка бернәрсә дә калмаган иде. Тик бары башкаларны шатландырган кебек мине дә куен кесәсенә бөкләп куелган инженер исемен алу дипломы гына шатландыра иде.

Шунысы бар тагын: яшьлек ике килми, бер генә килә ул, студент чагында файдаланып калырга кирәк, дип без башыбызга значоклы фуражкалар киеп, вечердан вечерга, җыелыштан җыелышка йөрергә дә бик ярата идек. Кирәгенә дә барасың, кирәкмәгәненә дә барасың. Нәтиҗәдә дүрт елда бетерәсе институтны биш-алты елда бетерү ешрак була иде.

Ярый, дипломны тотып, фабрикка барып кердем. Менә бөтен фаҗига да шунда башланды. Мин инженер булып чыкканмын, ә фабрикны күрмәгәнмен. Минем кул астында эшләгән эшче миңа караганда күбрәк белүче булып чыкты. Фабрикта эш лекцияләргә караганда

бөтенләй башкача бара икән. Нишләргә? Калошка утырып, эшчеләр алдында оятлы булып калырга ярамас бит. Яңадан укырга тотындым. Ләкин бу юлы инде мин фабрикның, заводның үзендә укырга керештем. Өч ел эчендә фабрикның серләренә төшенә дә башладым. Вакыты белән бик авыр, газаплы, фаҗигале көннәр, атналар булгалады. Менә шунда инде:

— Их, иске методлар, их, традиция, их, вузның практикадан, производстводан аерылып яшәве, — дип бер генә түгел, минутына әллә ничә кат иңсәңне кашыйсың. Чынлап та бит, китап яхшы нәрсә, ләкин үз белемеңне тормышка, производствога бәйләмичә бер китап белән генә эш итү ифрат та авыр нәрсә. Формаль зачетка карап кына инженерлык исемен алу да хәзер бик гаҗәп тоела. Чөнки вуздан алган диплом өстенә производствода барыбер яңа диплом алырга туры килә.

Минем фаҗигам, иптәшләр, әнә шуннан гыйбарәт. Тирәнтенрәк уйлап караганда, бу зур фаҗига. Ышанмасагыз, үзегез исәпләп карагыз: тугыз ел урта мәктәптә укылган, алты ел югары мәктәптә — унбиш булдымы... Шуңар тагын өр-яңадан башлап заводта өйрәнә башлаудан да бер дүрт елны салыгыз. Унтугыз булдымы? Күп бит. Минем чәчләр агара башлады инде. Ә ил синең унтугыз ел укып йөрүеңне көтми, илгә яңа белгечләр, совет белгечләре кирәк.

Югары мәктәпләрнең хәзергәчә килгән хәле, куелышы, үзеннән-үзе күренеп тора, үзгәрергә тиеш иде. Партия моны вакытында күрә белде. Хәзер зачет өчен генә, диплом өчен генә уку түгел, чын совет белгече булып чыгар өчен уку куела. Теориянең йөрәге производство була.

Ноябрь пленумының карарларын тормышка уздырганда, минем шикелле фаҗигаләргә очраучылар булмас инде.

Шуның өчен дә пленум карарларын бер минут та көтмичә йөз проценты белән тормышка ашырырга кирәк. Киләсе елга соң булачак. Чөнки Советлар Союзы белем фабрикасыннан яңа белгечләр көтә.

1929

ЖУРНАЛИСТ ХАТЛАРЫ

Дүртенче хат

Без барганчыга чаклы, украин халкының күпчелеге Татарстанны бары, бу якта күп таралган, Иж суы шешәләрендә басылган печатьләр аркылы гына белә иде. Ә кайберләре безгә:

— Кырым татарлары, яки мугаметане, — дип тә эндәшкәләделәр.

Шуңа күрә дә ТАПП оешмасы язучыларының Харьковка барып чыгулары Украина халкы өчен яңа бер хәл булса, Татарстанның үзе өчен дә, татар культурасын киң юлга чыгару өчен дә тарихка язып калдырырлык матур сәхифә.

Украина культурасы турында мин «Украина атнасы» уңае белән язылган мәкаләдә дә, алдагы хатларда да бераз тукталып киткән идем. Ул киң адымнар белән үсә. Украина культурасы хәзер алгы сафларга баса. Монда аның махсус язучылар йорты ачылуын да, вак-вак шәһәрләренә кадәр Шевченко кебек шагыйрьләренә ачылган һәйкәл памятникларын да әйтмим... Культура эшендә зур урын тоткан Украина Фәннәр академиясенә дә тукталмыйм. Әдәби газеталарын да күрсәтмим. Боларны санап, аларның һәрберсенә аерым-аерым тукталып китсәң, дистәләп хат кирәк.

Украина халкы иске заманда, үзенең көченә карамастан, иң изелгән, иң кысылган милләтләрнең берсе иде. Октябрь аны башка милләтләр белән тигез итте. Сөргеннәрдә йөргән революционер Скрыпникларны эшкә меңгезде. Украинага үсү юлларын ачты.

Украина тарихы — авыр һәм борылмалы тарих. Анда иске хөкүмәт кысуы да, Петлюра, гетман еллары да, көнбатышка ярүне дәгъвалаган чыгышлар да булды. Ләкин промышленность районы булган Украина хәзерге көндә, алда әйткән Петлюра, гетман калдыкларын музейларга тапшырып, пролетариат кадры белән пролетариат культурасын үстереп бара.

Украина пролетариат язучыларының тарихи Икенче съезды 26 нчы майда ачылып, алты көнгә сузылды. Иртә-кич утырышлар булды. Бу съезд һәр яктан да Украина әдәбиятының пролетариат язучылары кулына күчүен күрсәтте. Донбасстан, Днепропетровскидан һәм башка

районнардан съездны котлап килгән вәкилләр, тәбрикләп, Украина пролетариат әдәбиятының укучылары ул — без диделәр.

Съездны ачкан язучы Микитенко Украина пролетариат әдәбиятының бөтендөнья әдәбияты баскычына басканлыгын, чит телләргә тәрҗемә ителә башлавын әйтте. Бу уңышларны Коммунистлар партиясенең Украина Үзәк Комитеты тәбригендә дә, Скрыпник иптәшнең сүзләреннән дә, китаплар мәйданыннан да, укучылар кадрыннан да күреп була.

Украинада әдәбиятка партия тарафыннан да, хөкүмәт һәм совет җәмәгатьчелеге тарафыннан да зур әһәмият бирелә. Съездның шушылай күтәренке рух белән узуы моңар ачык мисал була ала.

Съездда Украина әдәбияты белән беррәттән рус, татар, грузин, белорус, еврей, молдаван милләтләренең пролетариат әдәбиятларына да җитәрлек урын бирелде. Гомәр Гали иптәшнең татар пролетариат әдәбияты турында доклад белән сәхнәгә чыгуы җылы каршы алынып, бер сәгатьтән артыкка сузылган докладны күңел биреп тыңланды. Гомәр Гали съездны татар әдәбиятының тарихи үсү юллары белән таныштырып, докладының күп өлешен революциядән соңгы әдәбиятка багышлады. Материалга, фактларга, мисалларга таянып, ялган пафосларга бирелми-нитми съезд алдында татар әдәбиятының нәрсәдән, нидән гыйбарәт икәнлеген күрсәтте. Украина әдәбиятының марксистик тәнкыйтьчеләрен татар пролетариат әдәбиятының үрнәкләре белән кызыктыра алды. Украина газеталарында докладның өземтәләре басылып чыкты. Гомәр Галидән мәкаләләр, Галимҗан Нигъмәтидән беседа-интервьюлар алынды. Татарстан, татар театры һәм гомумән татар культурасы турында Украина журналларына мәкалә, материаллар җибәрүебезне сорадылар.

Татар әдәбияты турында булган докладның съездга тагын ничек тәэсир итүен күрсәтү өчен, доклад соңында берничә минутка сузылган өзлексез алкышлар булуын әйтү җитсә кирәк. Украина татар язучыларын яхшы каршы алды, яхшы тыңлады, күп әйбер белән таныштырды. Ике арада башланган элемтәне эш белән ныгытты. Үзара тәрҗемәләр бирү мәсьәләсе дә сөйләнде. Хәзер безгә бу адымны сүздә генә калдырмаска, бәлки чын мәгъ-

нәсе белән тормышка ашырырга кирәк. Шуның белән бергә безгә хәзер һәм идеология, һәм художество ягыннан бай булган, чит телләргә тәрҗемә ителерлек әсәрләр бирүне кайгыртырга кирәк. Язучыларыбыз үз эшләренә әһәмият биреп, әсәрләре өстендә ныграк эшләргә тиешләр. Бу борылыш турында бездә күп һәм күптән сөйләнә... Ләкин болар бар да партия, хөкүмәт һәм совет җәмәгатьчелеге, татар пролетариат әдәбиятына артыграк күңел, әһәмият биргәндә генә булачак.

Безнең культура мәсьәләсендә булган омтылышларыбыз кайвакытларны башлангыч хәлендә яки уртасында өзелеп калалар. Менә без берничә ел инде татар пролетариат язучыларының һәм гомумән татар язучыларының конференцияләрен җыю турында әнгәмәләр алып барабыз... Ләкин җыела алганыбыз юк әле. Ә шуны җыйган вакытта татар пролетариат әдәбияты турында никадәр әһәмиятле мәсьәләләрне хәл кылган булыр идек. Ялгыз яшәгән язучылар, күмәклектән аерылып шыңшып йөргән шагыйрьләр алдына яңа бурычлар куелыр иде. Пролетариат әдәбиятының үзәге булырлык яңа каләмнәргә әдәбият ишекләре ачылыр иде. Ә бу килеш, булды ни дә булмады ни дип барган вакытта татар пролетариат әдәбиятының тиз арада гына чәчәк атуын күреп булмас.

1929

ХИКӘЯ ӨСТЕНДӘ ЭШЛӘҮ

Укучылар алданмасыннар: мәкаләдә язылган фикерләрне уку белән генә язучы булып булмый. Чын язучы булыр өчен, кагыйдәләрне өйрәнүдән элек, талант иясе булырга, шул өлкәдә эшли ала торган сәләтле кеше булырга кирәк. Пушкин, Толстой, Горький, Тукай, Такташ — болар берсе дә мәкалә укып, кагыйдә өйрәнеп кенә язучы булмаганнар.

Мәкалә — ярдәм генә ул. Биредәге фикерләр яза алган, язып килгән, яки шул өлкәдә көчен сынап карарга теләгән иптәшләргә булышлык күрсәтү йөзеннән генә әйтеләләр.

Матур әдәбият кешелек культурасының иң югары, иң саф җәүһәрләреннән тора. Укучылар аңа тирән бер игътибар белән, җылы ихтирам белән карарга тиешләр.

Язучы — кеше рухының инженеры ул. Ә кеше рухы инженеры булу өчен тормышны, җәмгыятьне, кешеләрне яхшы белергә һәм шуны әсәрләрдә дөрес чагылдыра алу өчен талантлы кеше, культуралы кеше булырга кирәк.

Чын язучы бервакытта да язам дип язмый. Язмыйча түзә алмый ул. Аның тормышта булган күзәтүләре, йөрәккә җыелган хисләре, ачы яки татлы уйлары шулчаклы өлгереп җиткән булалар ки, аларны тизрәк уртаклашасы, язып системага китерәсе килә һәм ул саф йөрәктән яза башлый.

Хикәяләр дә шулай язылалар.

Тормышта булган, яки булуы мөмкин булган берәр вакыйганы хикәя итү, ягъни язып, я булмаса сөйләп чыгу хикәя дип атала. Бүтән төр әсәрләрдәге кебек, хикәяләрдә дә тема, идея һәм эчтәлек була.

Тема — хикәянең исеме генә түгел. Тема — әсәр язганда язучының үз алдына куйган соравы ул. Мәсәлән, без укучылар тормышыннан бер хикәя язарга керештек, ди. Ә ни өчен язабыз? Нәрсә әйтергә телибез? Бик күп сораулар куярга мөмкин. Хикәябез өчен без күп сорауларның берсен нигез итеп алабыз. Әйтик, совет укучысы кем ул, нинди укучы ул? Менә шул сорау хикәянең төп темасы була.

Куелган сорауга хикәя барышында җавап бирү — әсәрнең идеясе дип атала. Тема буенча сөйләү, хикәя итү — әсәрнең эчтәлеген тудыра.

Биредә әйтелгән фикерләрне үзегез укып чыккан хикәяләр өстендә тикшереп карагыз, һәрбер әдәби әсәрдән сез теманы да, идеяне дә табарсыз.

Хикәя җиңел һәм кызыклы укылсын өчен, язучыларның күбесе язар алдыннан әсәрләренең планнарын сызып чыгалар. Зуррак китапларда план аерым кисәкләргә, кисәкләр аерым главаларга бүленеп биреләләр. План белән язу, ягъни хикәяне ничек башлау, ничек бетерү, алынган вакыйга күренешләрен кайсын алдан, кайсын соңыннан бирүне ачыклау эшкә җиңеллек китерә, әсәргә җыйнак төс бирә. Вакыйганың бер системага салынып бирелүе — композиция, ягъни әсәрнең төзелеше дип атала.

Әйтик, тормыштан алынган вакыйгабыз да, аңа язар өчен эшләнгән планыбыз да, төп темабыз да, идеябез дә бар, ди. Ләкин моның белән генә хикәя тумый. Язучының шул материалны бирә алырлык теле булырга тиеш. Әдәби әсәрләр башка төр әсәрләрдән (мәсәлән, дәреслекләрдән) укучының хисен, хыялын кузгата, дулкынландыра, күренешләрне укучы алдына җанлы рәвештә китереп бастыра торган тасвирлау, сурәтләү белән аерылалар.

Бу нәрсәгә язучы сүзгә бай булуы, сүзләрне урынлы куя белүе һәм сурәтләүләрне дөрес куллануы белән ирешә. Моңа түбәндәге нәрсәләр керәләр:

Өндәү — язучының яки сөйләүченең берәр кешегә яки берәр әйбергә мөрәҗәгать итүе.

«Әйт әле, күбәләк...»

Өндәү әсәрне җанландырып җибәрә. Хикәядә каракаршы сөйләшүләр (диалоглар) байтак кулланганга күрә, өндәүләрне дөрес алу әсәргә уңышлык бирәчәк.

Гипербола — арттыру, көчәйтеп әйтү.

«Мең тапкыр әйттем ләбаса. Нишләвең инде бу?»

Күп булса, ике-өч тапкыр әйткәндер.

Кабатлау (тавтология) — аерым сүзләрне яки җөмләләрне кабат куллану.

«*Юк, юк,* мин бармыйм!..»

«*Ул шатлана, ул* шундый *шатлана...*»

Антитеза — каршылыклы, капма-каршы куелган сүзләр, күренешләр куллану.

«Зур түгел, бик кечкенә...»

Җанландыру — җансыз әйберләр җанлы итеп биреләләр.

«Кояш көлә... җил елый».

Чагыштыру — бер әйберне икенче әйбер белән чагыштырып күрсәтү.

«Йоклый шунда йолдызлар да өелешеп,
Оядагы йоклап яткан *кошчыклардай*».

Параллелизм — бер күренешне икенче бер күренеш яктысында тасвир итү. Әйтик, бакчада чәчәкләр арасында уйнап йөргән шат йөзле балаларны күрсәтү. Биредә чәчәкләр һәм балалар параллель рәвештә тасвир ителәләр.

Метафора — бер әйбер урынына аңа мөнәсәбәттә булган икенче әйбер алына.

«— Эч инде, эч! Бал кабып эч...

— Җитәр. Болай да ике стакан *эчтем* инде».

Стаканны түгел, стаканга салынган чәйне эчте ул.

Символ — бер әйбер урынына аңа ерак мөнәсәбәттә булган икенче әйбер кулланыла.

«Безнең *лачыннар* яхшы очалар».

Лачыннар биредә батырларны — очучыларны аңлата.

Эпитет (сыйфат) — әйбернең нинди дә булса сыйфатын күрсәтү.

«*Кыю* егет. *Зәңгәр* күк. *Саф* һава».

Гармония — сүзләрнең үзара бәйләнеп барышларында укырга җиңел, колакка ятышлы итеп бирелүләре.

Хикәяне җанландыра торган сурәтләр бик күп. Без биредә аларның кайберләрен генә алдык.

Ләкин, телем матур булсын дип, сурәтләүләрне чиксез күп кулланырга да ярамый. Төче бизәкләрдән качарга кирәк.

Пушкин: «Хикәянең уңышлы ягы — кыска, ачык, динамикалы булуында», — ди.

Кайбер мисаллар алыйк:

«Идәнгә биш тиен акча төште». Бу гаять коры җөмлә. Күз алдына бернәрсә дә килеп басмый. «Идәнгә биш тиен акча төште һәм зыңгылдый-зыңгылдый идән буена тәгәрәп китте». Менә биредә инде акча төшкән тавыш та, акчаның тәгәрәп китүе дә бар.

«Диңгез өстендә сирәк-сирәк акчарлаклар күренгәли; алар ак канатларын селтәп-селтәп бер югары, бер түбән очып, тонык һәм эчпошыргыч тавыш белән елаганга да, көлгәнгә дә охшашлы чикылдап-чикылдап кычкыралар... Газизә хәзер аларны карамый, ул диңгез кырые буйлап очмыйча гына китеп барган канатсыз акчарлакларны гына карый иде...» (*Шәриф Камал.*)

Биредә без санап үткән сурәтләүләрнең бөтенесе дә бар диярлек. «Ак канатлар...», «тонык тавыш» (сыйфат), «елаганга да, көлгәнгә дә охшашлы» (җанландыру һәм чагыштыру), «канатсыз акчарлаклар» (символ), диңгез өстендә канатлы акчарлаклар... диңгез кырыенда канатсыз акчарлаклар (параллелизм) һәм башкалар.

Үз эшеңдә яхшы мастер булу өчен, күп өйрәнергә, талантыңны үстерергә кирәк. Язарга сәләте булган

иптәш өчен иң яхшы мәктәп — тормыш һәм китаплар. Бөек язучыларның әсәрләрен, әсәр өстендә ничек эшләүләрен өйрәнү — яза башлаучы иптәшкә бик күп байлыклар ачачак.

1939

«ДАВИД САСУНЛЫ»

I

Әрмән халкының бөек эпосы булган «Давид Сасунлы» әсәренең телдән телгә әйтелеп йөрүенә мең ел тулды. Кешелек культурасына яңа байлык алып килгән бу даһи әсәрнең мең еллыгын СССР халыклары зур бәйрәм итеп каршы алдылар.

Мең елга чыдаган, мең ел эчендә бик күп сынауларны үткән һәм быел төрле телләргә тәрҗемә ителеп бөтен дөнья халык әдәбиятының гүзәл үрнәге саналган «Давид Сасунлы» поэмасының эчтәлеге әрмән халкының ирек өчен, үзенең бәйсезлеге өчен гарәп хәлифәлегенә каршы көрәш алып баруына нигезләнгән.

Гарәп хәлифәлеге әрмән халкын өч йөз ел буена (VII—X гасырлар) изеп килде. VII гасырда ул, Әрмәнстанны басып алып, әрмән халкына авыр ясак сала, аның җирләрен кисә, малларын үзләштерә, улларын үтерә, кызларын мәсхәрә итә. Гарәп хәлифәлегенең тиранлыгына каршы Әрмәнстанда восстаниеләр җәелә башлый. 772 нче елны, мәсәлән, баш күтәргән әрмән халкы гарәп ясак җыючыларын үтерә, ә 775 нче елны сугышка каршы каты сугыш белән җавап кайтара. Дошман гаскәрләренә каршы бөтен Әрмәнстан күтәрелә. Өч гасырга сузылган көрәштә аеруча зур рольне таулар арасында урнашкан Сасун өлкәсе уйный. IX гасыр уртасында, мәсәлән, сасунлылар зур восстание ясыйлар һәм гарәп гаскәрләрен тар-мар китереп, гарәп командарларыннан Юсыф дигән командарны үтерәләр.

Шундый героик көрәш утында төрле җырлар туалар. Культурага, прогрессив көчкә бай булган әрмән халкы үзенең легендар улларын җырлый, аларның гүзәл сыйфатларын мактап, әдәби җәүһәрләр иҗат итә. Бу җыр-

ларда әрмән халкының көче-куәте янгырый, ирекка, бәхетле тормышка омтылуы чагыла. Интернационализм белән сугарылган бу җырларга әрмән халкының иң якты уйлары, иң татлы хисләре салынган.

Шул җырлардан «Давид Сасунлы» әсәре туа.

Халык телендә бу бөек эпосның җитмешләп варианты бар. Ләкин аларны җыю, өйрәнү һәм бастырып чыгару Октябрь социалистик революциясенә чаклы бөтенләй мөмкин булмый диярлек,—җитмеш вариантның ике варианты гына басылып чыга: бер вариантын 1874 нче елны Гарегин Срванцгән, икенче вариантын 1889 нчы елны профессор Манук Абегән игълан итә. Сасунлы батырлары турындагы җырларны өйрәнүгә үзенең бөтен гомерен багышлаган профессор Манук Абегән бары тик Октябрь революциясеннән соң гына җәелеп эшләргә мөмкинлек таба — сасунлы батырлары турында 25 варианттан торган җырларны бастырып чыгара һәм шулай ук 25 вариантны эченә алган икенче томны басарга бирергә хәзерли. Бөек эпосны өйрәнү эшенә СССР Фәннәр академиясенең Әрмәнстан филиалы керешә. Профессор Г. Абов җитәкчелеге астында профессор М. Абегән катнашы белән махсус комиссия эшли башлый. Бу эшкә академик И. Орбелинең дә күп кенә көче керә. Җентекләп өйрәнү-тикшеренүләрдән соң сасунлы батырлары турындагы җырлар системага салыналар, тиешле бер тәртипкә китереләләр һәм эпоска, җырларда үзәк урын алган Давидка карап, «Давид Сасунлы» дип исем бирелә.

II

Реалистик стильдә язылган һәм драматик вакыйгаларга гаять бай булган бу бөек әсәр беренче җырлары белән үк укучыны үзенең эченә алып китә.

Гарәп хәлифәлеге тарафыннан таланган Әрмәнстанга ясак җыючылар киләләр. Урам буйлап йөргәндә, алар кояшка гына тиң булган бер матур кызны күрәләр. Бу кыз әрмән патшасының кызы гүзәл Совинар була. Ясак җыючылар кешене һуштан яздырырлык күркәм кыз турында хәлифәгә кайтып сөйлиләр. Гарәп хәлифәсе, Совинарны үзенә хатынлыкка таләп итеп, әрмән патшасына кискен хәбәр җибәрә, юкса, илеңезне

кырам, себерәм, халкыгызны үтерәм, бетерәм, шәһәрләрегезне көлгә китерәм, ди.

Кан коелудан, халык кырылудан курыккан Совинар хәлифәгә чыга. Ләкин ул шарт куя: хәлифә аңа сарай салдырырга тиеш һәм бер ел шул сарайга аяк басмаска тиеш.

Туган-үскән җирләр белән саубуллашу өчен Совинар йөрергә китә. Сөт чишмәсе янына бара, диңгез буйларында йөри. Эчәсе килә, һәм шул ук минутта аның алдыннан татлы су ага башлый. Гүзәл кыз ике уч су эчә һәм балага уза. Тугыз айда тугыз көн һәм тугыз сәгать үткәч, Совинар ике игезәк таба. Тулы уч итеп эчкән судан Санасар, ярты уч итеп эчкән судан Багдасар туа.

Хәлифә үзенең палачларына Совинарның башын кисеп ташларга әмер бирә. Ләкин гүзәл кыз бик акыллы һәм бик зирәк була. Ул, сезнең илдә хаклык юк икән, минем башым киселгәч, балаларыма кем күкрәк сөте бирер, дип палачларны кайтарып җибәрә, төрлечә хәйлә корып җәза көнен суза.

Багдасар белән Санасар ел үсәсен көн үсәләр. Әнкәсе аларны укырга-язарга өйрәтә. Алар шундый батырлар булып үсәләр ки, уен арасында бүтән балаларга суга калсалар, әкрен сугудан да тегеләрнең куллары өзелә, башлары җимерелә. Вәзирләрнең балалары да шулай яньчелә башлагач, хәлифә Совинарның да, Санасар белән Багдасарның да башларын кисәргә палачлар җибәрә. Батыр Санасар үтерергә килгән палачларның, яңакларына сугып, башларын бәреп төшерә. Ачуланган хәлифә яшь батырларга каршы гаскәр җибәрә. Диңгез суыннан яралган батырлар бу гаскәрләрне дә кырып бетерәләр.

Ныгып житкән Санасар белән Багдасар, гарәп хәлифәлеген ташлап, ерак тауларга китәләр һәм анда ярлыларга йортлар салалар, тау кадәр ташлар ташып, сарай торгызалар. Сарайга Сасун (Ярсу) дип исем бирелә.

Санасар, диңгез төбенә төшеп, кешеләрчә сөйләшә белә торган Җәләли исемле ат һәм Яшен кылыч таба. Батыр егетләр, гарәп хәлифәсен үтереп, әнкәләрен коткаралар.

Шуннан соң эпоста Санасарның сихерле ил кызы Дехсун-Самга, Багдасарның Дехсун-Сам сеңелесенә өйләнүләре һәм халыкны бик күп төрле бәлаләрдән кот-

карулары турында жырлана. Сасун егетләренең батырлыклары турында илдән илгә дан китә. Анда ясак юк, анда тормыш яхшы, дип Сасун шәһәренә төрле жирләрдән халык агыла башлый.

Санасарның Вирго, Ован һәм Мһер исемле өч улы була. Ләкин Вирго да, Ован да батыр булып тумыйлар. Ованның бөтен батырлыгы күк күкрәгән тавыш чыгарып бик каты кычкыра алудан тора. Кычкырыр алдыннан ул, корсагы ярылмасын өчен, тәненә әллә ничәшәр кат тиреләр бәйли торган була. Бары тик Мһер генә батыр булып туа.

Эпосның беренче өлеше Санасарның үлүе белән бетә.

Санасарның үлүен ишеткән дошманнар Әрманстанга каршы яңадан сугыш башлыйлар. Гарәп хәлифәсе Мәлик әрмән халкына зур ясак сала, аның терлек-туарларын ала, алтын-көмешен ташыта, хатын-кызларын әсир итә.

Мһер дә, Санасар шикелле үк, ел үсәсен көн үсә, укырга-язарга өйрәнә. Ауга йөри. Шәһәрләрен ачка калдырган арсланны үтерә. Үсеп җиткәч, әнкәсе аңа Санасардан калган сугыш киемнәрен һәм Җәләлине бирә. Коралланган Мһер, диңгез дулкыннарыннан яралган атка атланып, юлбасарларга каршы сугышка китә. Аларны үтереп, халыкка азатлык китерә. Җиде ел буе әсирлектә яткан гүзәл кыз Армаганны коткара һәм аңа өйләнә.

Чит ил җирләрен басып алучы Мсра-Мәлик Мһергә каршы көрәшкә чыга, ләкин өч көн, өч төн барган каты сугыштан соң, Сасун батырын җиңә алмаганын белгәч, килешү ясый.

Мһер Сасун өлкәсен ныгыта. Мсра-Мәлик үлгәч, аның яшь һәм матур хатыны Исмил Мһернең Мисырга килеп китүен сорый. Исмилнең хәйләсен сизгән Армаган Мһерне бармаска өнди, аның янына барсаң, син 40 ел минем ятагыма кермәссең дип ант итә.

Усал Исмил Мһерне эчемлекләр белән сыйлап исертә, аңа җиде ел буе айнырга бирми һәм аңардан балага уза. Балага Кече Мәлик дип исем кушыла.

Мһер, Исмилнең балага тукыган: «Син безнең Мисырыбызны ныгыт, син Сасунны бетер»,—дигән сүзләрен ишетүгә, кинәт айный һәм, шушындый эшкә баруына, дошман хәйләсен башта аңламауга борчылып Сасунга кайта. 40 ел ялгыз яшәргә ант иткән Армаган Мһергә ишек ачмый. Һәртөрле түбәнлеккә барырга хәзер торган

дин башлыклары ярдәмгә киләләр. Нәрсә кайгырырга! Шәригать безнең үз кулыбызда ич, 40 елны без—40 айга, 40 айны—40 атнага, 40 атнаны—40 көнгә, 40 көнне—40 сәгатькә, 40 сәгатьне—40 минутка исәплибез дә вәссәлам! диләр.

Армаган балага узып, дөньяга Давид исемле батыр китерә. Ләкин озакламый Мһер дә, Армаган да үләләр. Сасунны кайгы баса. Бичара Давид ятим кала.

Эпосның иң зур өченче өлеше Давидка багышлана.

Ятим калган Давидны күкрәк сөте белән ашатыр өчен Мисырга Исмил янына җибәрәләр. Ләкин Давид өч көн үткәч тә Исмил күкрәген ташлый. Ул Сасун халкы җибәреп торган икмәк, бал, май ашап искиткеч батыр булып үсә. Аның батырлыгына кызыккан Кече Мәлик Давидны үтерергә теләп, төрле хәйләләр кора. Ләкин әрмән халкының яңа батыры бу хәйләләрнең берсенә дә бирелми.

Хезмәт яраткан Давид үз иленә кайтып көтү көтә. Ярлы халык белән аралаша. Зур көчкә ия булган Давид Әрмәнстанны талаган, аны бөлгенлеккә төшергән юлбасарларны үтерә, таланган малларны халыкка өләшеп яхшы тормыш тәэмин итә. Ясак җыярга килгән гарәп гаскәрләрен җиңә.

Ачуына чыдаша алмаган Кече Мәлик хисапсыз күп гаскәр белән әрмән җиренә килә. Ләкин ул үз иленең ирке һәм бәйсезлеге өчен көрәшкән Давидка каршы тора алмый — җиңелә. Давид аны кара-каршы көрәштә юкка чыгара. Исән калган гарәп гаскәрләрен гуманист Давид: «Барыгыз, өйләрегезгә кайтыгыз! Мин сезгә ирек бирәм»,— дип кайтарып җибәрә.

Сугыш күренешләрен оста тасвирлаганнан соң эпос Давидның гүзәл Хандутка өйләнүе һәм фаҗигале рәвештә һәлак булуы турында сөйли. Давид үлгәч, аның якын иптәше Хандут та манарадан ташланып үлә. Аларның Кече Мһер исемле уллары кала.

Эпосның соңгы дүртенче өлеше Кече Мһер турында сөйли. Мһер, Давидның шанлы эшен дәвам итеп, бик күп патшаларны җиңә, попларның пычрак эшләрен фаш итә.

Дөнья гизгән, күп урыннарда булган Мһер, җирнең зәгыйфьләнә, кешеләрнең ваклана баруын күреп, авыр уйларга чума. Җир шулхәтле көчсезләнә ки, ул инде Җәләлигә атланган Мһерне үз өстендә бөтенләй тота

алмый — уела. Батыр Мһер җирдә усаллык бетмәс борын, җир яңармас борын чыкмаска сүз биреп, текә тау эченә кереп югала.

III

Уникe мең юл шигырьдән торган бу бөек әсәр — әрмән халкының тарихы, аның әдәби көзгесе. Татар шагыйре Г. Тукайның «Халык — шагыйрь ул, әдип ул» дигән сүзләрен искә алып әйтсәк, «Давид Сасунлы» эпосында әрмән халкы үзенең өч йөз еллык (VII—X гасырлар) тарихын җырлый, дошманга каршы өзлексез көрәшеп килүен чагылдыра. Ләкин халык — шагыйрь генә түгел, ул философ та. Эпосны ул Мһернең үлүе белән бетерми. Мһер җир яңарганчы гына югалып тора. Халык үзенең киләчәген күрә, бәхетле тормыш тууына ышана.

Бөек Октябрь социалистик революциясе җир йөзенең алтыдан бер өлешендә җирне яңартты. Халыкның аһ-зарын бетереп, шатлыклы тормыш тәэмин итте. Совет Конституциясе кояшының җылы нурлары ватаныбызны яктыртты. Мһер көткән якты көннәр килде.

Эпосның беренче чиратта әйтелергә тиешле тирән фәлсәфи ягы әнә шунда — якты көннәрнең тууына, җирнең яңаруына ышануда.

Әсәр баштан алып ахырына чаклы интернационализм белән сугарылган. Сасунлы батырлары халыкка каршы түгел, ә гарәп хәлифәләренә, патшаларга һәм символик нигездә алынган арсланга, юлбасарларга каршы көрәшәләр. Шунысы характерлы, алар һичбер вакытта да чит ил җирләрен басып алмыйлар, сугышка чыкмаган халыкка тимиләр, киресенчә, андыйларга алар ярдәм генә итәләр. Һәм шундый яхшы сыйфатлары өчен Сасун батырларына әрмән халкы гына түгел, бүтән ил халыклары да рәхмәтләр әйтәләр. Моңа мисал итеп тагын грузин батырының Давидка ярдәм күрсәтүен алырга була. Яки гарәп карты. Давид янына ул үз баласы янына килгән кебек килә һәм болай ди:

Безне бит көчләп, балам,
Шул Мәлик куып китерде
Яу итеп сезгә табан...
Дошманың синең — Мәлик ич!
Без сиңа дошман түгел!
Бар аның белән сугыш син.

Гарәп карты Давидка Мәликнең чатырын күрсәтә. Димәк, булыша. Ә Мәликне үтергәч, Давид гарәпләрнең җирләрен дә алмый, ясак та салмый, гаскәрләренә дә тими. Киресенчә, барыгыз, өйләрегезгә кайтыгыз, мин сезгә ирек бирәм, дип кайтарып җибәрә.

Эпосның беренче чиратта әйтелергә тиешле мөһим ягы әнә шунда — интернационализм рухта җырланган бөек гуманистик әсәр булуында.

Хезмәт әсәрдә гаять зур урынны тота. Туган-үскән җирләре белән саубуллашырга чыккан гүзәл Совинар, хезмәт тавышларын ишетеп, үзенең кайгысын җиңеләйтә.

Кыз күрә якты җиһанны, күрә кояшны.
Хезмәт янгырый, һаваларда кошлар сайрыйлар.
Әнә — көтүчеләр, менә — җирне казучылар,
Ә тегендә әнә сукачылар җырлыйлар.

Батыр егетләр хезмәт итеп, халыкка эш күрсәтеп үсәләр. Олы Мһер бала чагында ук ауга йөри һәм бөтен Сасунны ит белән тәэмин итә. Җиде яшьлек Давид үзенең кардәшләреннән, зинһар мине хезмәткә урнаштырыгыз, дип инәлеп сорый. Үз эшен Давид яратып эшли. Пычракка батып үләргә җыенган көчсез хайваннарны ул җилкәсенә күтәреп ташый, кадерләп тәрбияли һәм ярлы халыкны бәладән коткара.

Сасун батырлары чын мәгънәсе белән халык уллары, ватан патриотлары булып күз алдына калкалар. Алар бөтен гомерләрен халыкның көнкүрешен яхшыртуга, азат тормыш тудыруга багышлыйлар. Дан, шөһрәт өчен яшәмиләр алар. Санасар да, Давид та, Мһерләр дә яшьтән үк ярлы халыкның булышчылары булалар. Санасар, ярлыларның өйләре булырга тиеш дип, ярлыларга өйләр сала. Давид көтүчеләрне яклый, юлбасарлар тарафыннан таланган хисапсыз күп малны ул халыкка өләшә, ә үзенә ул бер ат кына ала. Мһер, халык әллә кайдан уратып йөрмәсен һәм суга батмасын дип, күперләр сала. Сасун батырлары, тормышларын аямыйча сугыш уты эченә кереп, халык бәхете өчен көрәшәләр.

Эпосның әйтелергә тиешле тагын бер мөһим ягы әнә шунда — хезмәтне раслауда, халыкны сөюдә, патриотизм хисләрен тудыруда.

Художество мастерлыгы белән жырланган «Давид Сасунлы» әсәрендә сугыш күренешләре жылы лирика белән, мәхәббәт күренешләре белән аралаш бирелә. Эпоста укып туйгысыз мәхәббәт вакыйгалары бар.

Шунысы характерлы, әсәрдә хатын-кызлар ирләр белән бер хокукка куелалар. Совинар, Дехсун-Сам, Армаган һәм Хандут онытылмаслык матур образлар итеп биреләләр. Сасун батырлары белән бергә алар да халык бәхете өчен яналар, дошманга каршы көрәштә батырларның сугышчан иптәшләре булып гәүдәләнәләр.

Халыкны изелүдән, авыр фажигалардан коткарырга теләп, Совинар үзенең тормышын корбан итә. Дехсун-Сам Давидны сугышка озата, җиңеп кайтырга теләк тели һәм кеше телен аңлаган атка болай ди:

. . . . Жәләли!
Атасыз минем Давид — ата бул аңа!
Анасыз минем Давид — ана бул ана!
Абыйсыз минем Давид — абый бул аңа!

Эпосның әйтелергә тиешле янә бер мөһим ягы әнә шунда — хатын-кыз хокукы өчен көрәшне күрсәтүдә.

«Давид Сасунлы» әсәре юмор-сатира элементларына гаять бай әсәр. Жылы юмор белән бирелгән куркак Виргә, бушбугаз Ован образлары бик нык истә калалар. Козбадин, Кече Мәлик һәм Игумен образлары әче сатира буяулары белән биреләләр.

Үзе белән иң көчле мең пәһлеванны алып, гарәп гаскәрләренең башлыгы Козбадин Давидка каршы сугышка китә. Давидны юкка чыгарырга бара, янәсе. Юлда хатын-кызлар очрыйлар. Кая барасыз дип сорауга, Козбадин: «Давидны бетерергә, Сасунны җимерергә»,— дип мактанып куя. Давид гарәп гаскәрләрен тар-мар итеп ташлый, ә Козбадинның тешләрен сындырып мангаена утырта һәм атка атландырып бәйли дә: «Бар, хәлифәңә бүләк ит»,— дип жибәрә. Янадан хатын-кызлар очрыйлар. Алар:

Бүре булып киткән идең сугышка,
Куркак көчек булып кайттың сугыштан... —

дип мыскыл итеп каршы алалар. Чынлап та, мин тегеләй итәм, мин болай итәм, дип мактанган кешенең пычракка батып сәләмә хәлдә кайтуы бик көлке. Бу күренеш Хасан күле янында көлкегә калган япон самурайларын хәтерләтә.

Яки менә шундый күренеш: гарәп хәлифәсе Санасарны үтерергә җыена. Ул да шулай ук, Козбадин шикелле, мин дә мин дип бик мактанырга ярата торган була. Ләкин Санасар аның арткы битенә шундый тибеп җибәрә ки, хәлифә йөзгә бөтәрләнеп әйләнеп китә, аякка баса, тагын бөтәрләнә һәм егыла.

Мәликнең Давидтан куркып базга төшүе, кырык кат тиреләр һәм тегермән ташлары белән каплануы да әче сатира булып яңгырый. Ләкин барыбер Давидның Яшен кылычы дошманны таба.

Халык кебек үк, Сасун батырлары да сугыш теләмиләр. Ләкин сугышка чыкканга сабакның менә дигәнен укыталар. Давид дошманга мондый кисәтү ясый:

— Моннан соң сугышмагыз... Сугыша калсагыз, белегез, нинди генә базларга качмагыз, нинди генә ташлар, тиреләр белән капланмагыз, барыбер безнен кылыч сезне табар һәм тиешле җәзаны бирер,— ди Давид.

Бу сүзләр бүген дә бик урынлылар.

«Давид Сасунлы» — халык иҗат иткән җәүһәрләрнең берсе. Андагы батырлар бүген дә 170 миллионлы совет халкының намуслы, кыю, батыр уллары булып яшиләр.

1939

ҺАДИ ТАКТАШ

Кабат-кабат укыла торган, укыган саен яңа булып тоелган язучылар бар. Шагыйрь Һади Такташ әнә шушындый язучылар сафына керә.

Мин Такташның байтак әсәрләрен үз авызыннан ишеткәнем бар. Аларны ул искиткеч матур итеп укый иде. Аның хискә бирелеп укуы хәтердә нык саклана. Мин аның ялкынлы шигырьләрен көн саен диярлек

Гадел Кутуйның Һади Такташ белән төшкән рәсеме.

укыйм. Үземә генә түгел, балаларым, танышларым өчен дә укыйм.

Һади Такташ бөек шагыйрьләргә генә хас булган җылылык белән гаять матур итеп, гади итеп яза иде. Аның ялкынлы сүзләре, ягымлы гармониясе шагыйрьнең саф йөрәгеннән туганнар һәм укучылар йөрәгенә барып җитәрлек итеп төзелгәннәр.

Мин аның язып утырганын күргәнем бар. Мин килеп кергәндә, ул гаҗәп бер фаҗигалы кыяфәттә, зур борчылу, авыр югалту алдында торган кеше шикелле, язып утыра иде. Кашлары җыерылган, болай да җыерчыклы йөзен тирән җыерчыклар баскан. Язу өстәле һәм өстәл тирәсе язылып ташланган кәгазь кисәкләре белән тулган.

— Менә ничек язасың! — диюгә, ул:

— Мин дүрт юллык шигырь язу өчен, күбесенчә, егерме дүрт юл язам. Шул егерме дүрт юлдан иң яхшы дип табылган дүрт юлны сайлыйм, — диде.

— Төсең киткән, Һади, арыгансың, ял итәр иден, — дигәч, ул:

— Шигырьгә мин үземдә булган бөтен җылылыгымны, барлык татлы хисләремне, матур фикерләремне, тирән уйларымны бирергә тырышам. Бу эш чиксез шатлыклы да, авыр да, — диде.

Мин сыйныфның бөек көрәшенә
Артык айнык күзләреш карадым,
Һәрбер юлым, һәрбер хисем өчен
Мин үземне мәсьүл санадым! —

ди Такташ.

Ул нык зиһенле шагыйрь иде. Ул үзенең бөтен иҗатын күңелдән белә иде. Бу мәсьәләдә без, берничә иптәш, аңа «имтихан» да ясап караганыбыз бар. Күп санда булган шигырьләре арасыннан берсен сайлап алып, шуның бер генә юлын әйтеп карый идек... Ә Такташ шуны һич тотлыкмыйча дәвам итә иде. Такташ үзенең шигырьләрен басарга биргәнче дусларына, танышларына укырга ярата иде. Җылылык белән әйтелгән тәнкыйтьтән соң шигырен төзәтә иде. Шуңар бәйләп, сөекле шагыйребезнең киң масса белән, халык белән тирән мөнәсәбәттә булуын да әйтергә кирәк. Урамда, бакчада, театрда, клубларда, мәктәпләрдә, җыелышларда аны һәрвакыт яңа кешеләр, яна таныш-

лар белән күреп була иде. Бу танышларны Такташ зурлар арасында гына түгел, балалар арасында да таба иде. Бервакыт ул башлангыч мәктәпкә барып чыккан. Шуны ул зур бәйрәм итеп:

— Иң саф, иң якын дусларым арасында булдым,— дип бик озак сөйләп йөрде.

Шуннан соң аның «Нәни шаярулары», «Кыр казлары», балалар өчен язылган төрле-төрле шигырьләре туа башлады.

Бөек Такташның арабыздан югалуына быел 8 нче декабрьда 8 ел тулды. Бик авыр, тирән, кайгылы югалту. Ләкин безне бернәрсә тынычландыра: Такташ шикелле бөек талантлы шагыйрьләр үлмиләр. Аларның әсәрләре тере. Такташның искиткеч матур шигырьләре безнең йөрәгебездә яшиләр. Аның ялкынлы сүзләрен без радиодан да ишетәбез, сәхнәдән дә тыңлыйбыз, өстәлебез өстендәге китаптан да укыйбыз.

Пионер, алга!
Зур көрәш алда,
Комсомолларга
Салют бирәбез,
Алмашка киләбез!..—

дип тере Такташ пионерлар белән бәхетле тормыш строенда яши.

1939

РУС ХАЛКЫНЫҢ БӨЕК УЛЫ

Быел, 29 нчы октябрьда, атаклы рус язучысы, бөек революционер Николай Гаврилович Чернышевскийның үлүенә 50 ел тулды.

Чернышевский үзенең бөтен гомерен халык бәхете өчен царизмга каршы көрәш юлында үткәрде. Крестьяннарны социалистик революция ясарга чакырды. Аның тарафыннан ялкынлы прокламацияләр, гүзәл гыйльми хезмәтләр, үткен үклы әдәби мәкаләләр, яшьләргә юл күрсәткән «Нәрсә эшләргә» дигән роман язылды.

Чернышевскийның тормыш юлы — халык эше өчен үзен аямаучы чын көрәшче юлы.

Ул 1828 нче елның 24 нче июлендә Саратов шәһәрендә туа. Әтисе зирәк балага яхшы тәрбия бирергә тырыша. Чернышевский крепостной балалар белән бергә уйный, бергә вакыт уздыра. Ләкин аның якын дуслары — китаплары була. Яшьтән үк ул дүрт тел өйрәнә.

Берничә ел Саратов гимназиясендә укыганнан соң, Чернышевский университетка укырга керү өчен Петербургка китә. Сөекле әнисе аны үзе озата бара. Тимер юл булмаганлыктан, алар атта бер ай баралар.

Университетка кергән елларны Чернышевский үзенең «көндәлек дәфтәр»енә... азатлык, тигезлек һәм туганлык өчен... мин үземнең гомеремне дә кызганмам»,— дип яза һәм шул изге теләкне тормышка ашырыр өчен ант итә.

Университетны тәмам итүгә, ул Саратов гимназиясенә укытучы булып билгеләнә. Монда ул үз тирәсенә иң алдынгы яшьләрне оештыра һәм царизмга каршы, крепостной правога каршы алар арасында пропаганда алып бара.

1853 нче елда Чернышевский өйләнә һәм Петербургка күчә. Өйләнер алдыннан сөекле иптәшенә ул:

— Бел, Ольга, мине кулга алулары мөмкин. Төрмәдән чыкмавым мөмкин минем, — ди.

Бу сүзләр укытучы булган елларында ук Чернышевскийның революцион эшкә нык бирелгәнен һәм шул эш өчен кулга алыначагын яхшы төшенгән булуын күрсәтәләр. Петербургта ул, бераз вакыт әдәбият укытучысы булып хезмәт иткәннән соң, язучылык эшенә бирелә, гыйльми әсәрләр өстендә эшләвен дәвам иттерә. Некрасов һәм Добролюбов белән бергә ул «Современник» журналын царизмга каршы көрәш органына әйләндерә. Некрасовның җырлары, Чернышевскийның мәкаләләре халыкның күзен ачалар, яшьләрне революциягә чакыралар.

1861 нче елда «реформа» игълан ителә. Ләкин патша тарафыннан ясалган бу «реформа» крестьяннарны бер коллыктан икенче коллыкка ташлый — халык богауланган килеш кала. Чернышевский әнә шуны аңлатырга керешә. Чын азатлык мондый булмый, «чын азатлык — халык үзе хуҗа булган вакытта гына була ул», — дип, Чернышевский революциянең кирәклеге турында сөйли. Шул турыда ул крестьяннарга мөрәҗәгатьләр яза.

Патша «реформа»сына крестьяннар бунтлар ясап

җавап бирәләр. Бөтен Россия буена восстаниеләр дулкыны җәелә. 1862 нче елда «Современник» журналы туктатыла, ә аның илһамчысы — революционер Чернышевский кулга алына. 678 көн төрмәдә ята, дүрт ай ярым буена аны бер генә тапкыр да допроска чакырмыйлар. Шул вакыт эчендә жандармерия Чернышевский өстеннән ялган документлар хәзерли.

Ялкынлы революционер төрмәдә дә тик ятмый. Аның кыю тавышы, үткен сүзе төрмә ишекләрен җимереп чыга. Төрмәдә ул үзенең «Нәрсә эшләргә» исемле зур романын яза.

Патша хөкүмәте Чернышевскийны каторгага, ә аннан соң мәңгелек сөргенгә Себергә җибәрергә карар чыгара. 1864 нче елның язында ерткыч хөкүмәт, халык улын мәйданга чыгарып «хурлык баганасына» бастыра. Чернышевскийның муенына «Дәүләт җинаятьчесе» дип язылган такта тагыла, аның баш өстендә кылыч сындырыла. Ләкин бу вакыйга шунда җыелган халыкның күзләрен ачарга гына ярдәм итә. Чернышевскийга чәчәк ыргыталар. Яшьләр:

— Без синең шәкертләрең, — дип, Чернышевский утырып киткән карета артыннан йөгерәләр.

Чәчәк ыргыткан кеше кулга алына, халык куыла.

Минем алдымда Чернышевскийның ике рәсеме тора. Беренчесендә — ул яшь, батыр, кыю, сакалсыз, мыексыз, яп-якты йөз. Монысы аның кулга алынганчы төшкән рәсеме. Икенчесендә — ул бөтенләй карт булып күренә. Чал сакаллы, хәлсез чырайлы. Монысы аның 21 ел каторгада һәм сөргендә йөргәннән соң төшкән рәсеме. 21 ел... 21 ел буе ул иң авыр шартларда яши. Сөргендә ул ревматизм эләктерә, цынга белән авырый. Ничә ел буе ул итмәй күрми. Сөргенлек аны шулхәтле изә, яньчи ки:

— Син хәзер азатсың, — дигән сүзләрне ишетүгә, нык Чернышевский шатлыктан елап җибәрә. Ләкин царизм аны бөтенләйгә азат итми. Чернышевский Астраханьга күчерелә. Рудникта эшләгәндә дә, Якутиянең иң ерак почмагында яшәгәндә дә революцион пропаганда эшен ташламаган Чернышевский Астраханьда да өзлексез эш алып бара.

Эшсез яту — үлем ул, дип караган бөек революционер 4—5 елда Веберның 12 томнан торган 10 мең битле китабын русчага тәрҗемә итә. Добролюбовның биографиясенә карата яңа материаллар хәзерли.

Замандашларының белдерүенә караганда, Чернышевский һәр көн иртә белән 7 сәгатьтә торган. 8 сәгатьтән 1 сәгатькә кадәр язган. Бердә ашаган. Аштан соң газета-журналлар укыган. Кич белән китап укыган, беседа алып барган.

1889 нчы елның июлендә Чернышевскийга туган шәһәренә Саратовка күчәргә рөхсәт итәләр. 9 нчы июльдә ул Саратовка күчә, ә 29 нчы октябрьда үлә.

Аның каберенә Мәскәүдән, Петербургтан, Харьковтан, Варшавадан һәм башка шәһәрләрдән веноклар килә. «Чернышевскийның хезмәтләре исән, даны исән», дип телеграммалар җибәрелә.

Әйе, аның хезмәтләре исән, аның даны исән. Чернышевский халыкның якты киләчәгенә ышанып яшәде һәм халыкны шуңа чакырды. «Киләчәк якты һәм гүзәл. Аны сөегез, аңа омтылыгыз». «Тарихта көрәшсез бернәрсә дә алынмый», ди ул. Һәм ул үзенең бөтен бөек гомере буена шул якты киләчәк өчен көрәште. Хәтта, «Нәрсә эшләргә» исемле романында ул шул киләчәк бәхетле тормышны үз аңлавынча күрсәтергә дә тырышты.

Кешелек дөньясының иң алдынгы бөек галимнәре — даһи юлбашчыларыбыз Карл Маркс, В. И. Ленин Чернышевскийның хезмәтләренә зур ихтирам белән карыйлар.

Рус телен өйрәнгәннән соң Карл Маркс беренче чиратта Чернышевскийның әсәрләрен укып, аңа «русның бөек галиме һәм критигы» дип бәя бирә.

Чернышевский әсәрләре, аеруча аның «Нәрсә эшләргә» романы — совет яшьләре өстәлендә булырга тиешле әсәрләр.

1939

БЕРЕНЧЕ ОЧРАШУ

1925 нче елның кышы. Мәскәүдә матбугат йортында язучылар киңәшмәсе бара. Доклад буенча фикер алышуларда чыккан драматургларның берсе, бик кызыклы бер фактка тукталып:

— Бәлки мин ялгышамдыр, мин сөйләгән нәрсә бәлки дөрес түгелдер, — диде.

Шул вакытта иң арткы сафлардан берәү калын тавыш белән:

— Мин раслыйм: дөрес! — дип кычкырды.

Әлеге драматург: «Әнә Маяковский раслый»,— дип сүзен дәвам итә башлаган гына иде, без, залда утыручы яшьләр, гөр килеп, калын тавыш килгән якка борылдык һәм ишек янында басып торган озын буйлы мәһабәт кешене күрдек.

Киңәшмәдә атаклы язучылар һәм шагыйрьләр күп иде. Ләкин башлап язучылар арасында һәм, гомумән, бүтән шәһәрләрдән килгән шагыйрьләр арасында Маяковский иҗаты белән кызыксынучы, ялкынлы шагыйрьгә мәхәббәт тотучы иптәшләр шулкадәр күп иде, алар тәнәфес вакытында Маяковскийны сырып алдылар. Киң коридор халык белән шыгрым тулды.

Үз бәхетләрен матур әдәбиятта сынарга теләгән башлап язучыларның шушындый кайнар мәхәббәтләренә Маяковский, әлбәттә, бик шат иде. Коридорда пальтосын салып ук, көлә-көлә:

— Гадәттән тыш киңәшмә ачык. Мин председатель. Кем сүз ала? — диде.

Маяковский белән күңелле генә сөйләшкән вакытта берәү:

— Менә бу иптәш Казаннан. Татар шагыйре. Сезнең «Сул марш»ны ул татарчага тәрҗемә иткән, — диде.

Ул елларны Маяковскийны бик нык «тәнкыйть» итәләр иде. Матбугатка кереп сырышкан дошманнар һәм аларга ияргән җиңел акыллы кешеләр Маяковский талантыннан көлеп, аның турында пычрак мәкаләләр язып чыгалар иде. Хәтта әлеге киңәшмәгә дә Маяковский киңәш бирү хокукы белән генә чакырылган иде.

Менә шундый көннәрдә үз әсәрләренең төрле телләргә тәрҗемә ителүен белү Маяковскийга бик җылы тоелды. Таза гәүдәле, җитди чырайлы шагыйрьнең йөзендә рәхәт дулкынлану сизелде. Әле хәзер генә аңа шигырьләренең украин теленә тәрҗемә ителүе турында сөйләгәннәр иде. Инде менә татарчага да бар.

— Ничек чыкты соң? —дип, ул миңа сорау бирде.

Мин аңа әле яңа гына басылып чыккан «Көннәр йөгергәндә» китабын суздым һәм шул китапка кергән «Сул марш»ны күрсәттем. Русчадагы кебек үк, юллары чәчелеп басылган татарча сүзләргә карап бераз торганнан соң, Маяковский:

— Кызганычка каршы, мин татарча укый белмим! Үзегез укып күрсәтегез, — диде.

Маяковский шигырьләрен мин яшьтән үк яратып укый идем һәм, шигырьнең үзенчәлеген саклап, дөрес укырга тырыша идем. Яраткан шагыйрең укы дигәч, мин оялуымны оныттым. Тәрҗемәдәге беренче тәҗрибәне дә уңышлы итеп күрсәтәсе килде ахры, мин дәртләнеп:

Марш эчендә көчле әйләнегез!
Буш сүзләргә монда урын юк,
Ораторлар, акрын!
Сезнең
Сүз,
Иптәш маузер...—

дип шигырьне яттан укып чыктым.

— Һәйбәт яңгырый!—дип ул, минем кулымны кысты. Без сөйләшеп киттек. Шунда ул Казан хәлләрен сорашты, татар әдәбияты турында сораулар бирде һәм үзенең дә Казанга килергә җыенуын әйтте.

«Сул марш»ны татарча тыңлау тәэсирен Маяковский соңыннан үзенең «Казан» дигән шигырендә чагылдырды.

Беренче очрашуның икенче көнендә Маяковский доклад буенча фикер алышуга катнашты. Аның чыгышын без түземсезлек белән көттек. Аны тыңлау гаҗәп рәхәт. Трибун-шагыйрьнең үткен акылы, образлы теле, кызыклы мисаллары тыңлаучылар күңелендә ораторлык сәнгатенең онытылмаслык үрнәге булып калалар. Маяковский төшенкелеккә каршы, урынсыз сүзләр куллануга каршы сөйләде һәм киңәшмәнең кайбер «түрәләре» тарафыннан макталган берничә китапны тәнкыйть уты астына алды. Сугышчан шагыйрьнең тәнкыйтенә түзә алмаган «түрәләр» Маяковскийны җыелыштан куып чыгару мәсьәләсен күтәрделәр. Ләкин Маяковскийның көрәштә чигенеп калмавы һәм делегатлар арасында аны яклаучыларның күплеге бу тупас тәкъдимне шунда ук юкка чыгарды. Маяковский җиңүче булып киңәшмәдә калды.

Революция җырчысының бу киңәшмәдә никадәр хаклы булуын еллар тулысынча расладылар. Аңа каршы чыккан «язучылар» да, алар мактаган «әсәрләр» дә күптән онытылдылар. Ә Маяковский иҗаты яши һәм яшәр.

1940

СОВЕТ ЭПОХАСЫНЫҢ ИҢ ЯХШЫ, ИҢ ТАЛАНТЛЫ ШАГЫЙРЕ

Укучыга тәэсир итү ягыннан Пушкинның «Һәйкәл» исемле шигыре белән янәшә торган «Бөтен тавыш белән» поэмасында Маяковский:

Төкерәм мин
Мәрмәр лайласына,
            бронзалар авырлыгына.
Дан хакында килешербез —
Без үз кеше бит,—
Булсын безгә
            әйдә
Сугышларда төзелгән
            социализм
                уртак памятник,—

дип язды.

Маяковский 20 еллык иҗат юлын үтте. Үтелгән данлы иҗат юлына карап, ул:

— Кешелекнең матур киләчәге өчен көрәшүчеләргә уртак һәйкәл — социализм! — дип әйтергә хаклы иде. Чөнки социализм темасы аның иҗатында төп темаларның берсе булып тора.

Революциягә кадәр үк Маяковский буржуа җәмгыятенә каршы бунт күтәреп чыкты. Игорь Северянин, Бальмонт шикелле тормыштан ерак торган шагыйрьләр төрле аһәңнәргә бирелеп мещанлыкны җырлаганда, Маяковский дингә, милекчелеккә, буржуа моралена каршы тавыш күтәрде һәм шигырьләрне тормыш турында язарга чакырды. Буржуа җәмгыятенә каршы шигырь көрәш алып барырга тиеш, диде.

Ул елларны Маяковский капитализмга каршы көрәшнең реаль юлларын белми иде әле. Бунтарь, ялгызак иде ул. Үзен ялгыз хис итү нәтиҗәсендә, шагыйрь коточкыч образлар тудырды. Бер шигырендә Маяковский үзенең бөтен байлыгын, үлмәс даһилыгын әйтә дә:

Телисезме,
Шуның һәммәсен мин
    тик бер сүзгә,
        кешелекле, ягымлы
            бер сүзгә бирәм, —

дип фаҗигалы пафос белән кычкыра.

Әй, син!
　　Күк!
　　　　Мине каршыла!
Эшләпәңне сал да
　　　　Минс каршыла!
Тынлык.
Йолдызлар белән кысылган колагын
　　　　куеп аягына
　　　　йоклый бар дөнья.

Капитализм тарафыннан изелгән кешеләрнең авыр газапларын аңлаткан бу юллар — буржуа җәмгыятенә каршы көчле протест булып яңгырадылар.

Иҗатының беренче дәверендә үк иске дөньяга каршы бунт күтәрү белән бергә, Маяковский яңа көннәрнең туачагын да җырлады. Җирдә оҗмах төзелүен теләде ул, һәм:

Мин җырлаган
　　　　ирекле кеше
　　　　　　　　килер,
Ышаныгыз миңа,
　　　　мин беләм!.. —

дип кешенең азатлыкка ирешәчәген хәбәр итте.

Кайдан бу кадәр ышаныч? Шагыйрьнең алгы көннәрне күрә белүенә сәбәп 'нәрсә? Бу сорауларга җавап бирү өчен шагыйрьнең тәрҗемәи хәленә күз төшерик.

Гүзәл Грузия иленең Багдади исемле кечкенә генә авылы түбәләре күккә менгән очлы таулар, виноград тулы яланнар белән уратылып алынган. Авыл уртасыннан көмеш тавыш чыгарып тау елгасы — Ханис-Цхали ага. Елга аша күпер салынган.

Әнә шул күпер янындагы өйдә, 1893 нче елның 19 (7) нчы июлендә ярлы урманчы семьясында шагыйрь Владимир Маяковский туа.

Ир баланың тууына ата-аналары бик куаналар. Семьяда үсеп килгән Люда белән Оля исемле кыз балалар да «энебез булды» дип шатланалар.

Шагыйрьнең атасы — урманчы Владимир Константинович көр тавышлы, шат күңелле, озын буйлы кеше була. Аны крестьяннар бик яраталар, аңа дус итеп карыйлар һәм үз итеп аңа кунакка йөриләр.

Урманчы буларак, Владимир Константиновичка йөрергә, урман гизәргә туры килә. Өйгә кайтырга туры

килмәгәнлектән, ул башын ияргә куеп, урманда ук йокларга да мәҗбүр була.

Аның көченә кешеләр сокланып карыйлар. Бүтәннәр ике кул белән күтәрә алмаган әйберне ул бер кул белән күтәрә. Ачуланып кычкырган вакытларда аның калын тавышы киң Ханис-Цхали елгасының аръягында ишетелә.

Володя әтисенә охшап үсә. Әтисе аны үзе белән бергә урман карарга алып бара. Ата белән бала гаять дус булып яшиләр.

Алты яшендә Володя Маяковский укырга өйрәнә. Ләкин ялгыз гына укып чыгарга туры килгән беренче китабы бик начар китап булып чыга. Күңеле кайтып. Володя: «Моның өчен укырга өйрәнәсе дә калмаган. Барлык китаплар да шундый күңелсез була торган булсалар, тотам да укый белүемне онытам!» — ди.

Аның апасы Люда бервакыт шулай дәрес хәзерләгәндә Пушкинның «Тоткын» исемле шигырен кычкырып укый. Бу шигырь Володяга шулкадәр тәэсир итә ки, ул, дулкынлануын кыз балалардан яшерү өчен, тауларга кача.

Пушкинның «Тоткын»ын тыңлаганнан соң ул үзе дә күп укырга һәм шигырьләр язарга керешә.

Урманчы семьясына кунакка килгән кешеләр русча, грузинча, украинча җырлар җырлыйлар. Володяны урындыкка бастыралар. Володя шигырьләр укый. Ә сокланып тыңлап торучылар урманчыга карап:

— Синең улың зур кеше булыр,— диләр.

Володяның да көр тавышлы буласы килә. Һәм ул бик кызыклы тәҗрибәләр ясый. Виноградтан эчемлек ясар өчен ишек алдында җиргә зур чүлмәкләр казылып куелган. Володя буш чүлмәк эченә керә, апасын ишек алдының икенче ягына җибәрә, ә үзе:

— Тыңла, еракмы ишетелә? — дип шигырь укырга керешә.

Озакламый туганнары Володяда тагын бер яңа нәрсә сизәләр. Ул шигырь чыгара башлый, хәтта рифмаларны да килешле итеп китерә.

Сервантесның «Дон-Кихот»ын ул баштан алып ахыргача берничә тапкыр укып чыга. Агачтан кораллар ясап Володя үзе дә романда язылган кешеләр шикелле кыланып йөри башлый.

Володя динсез булып үсә.

Бервакыт ул ата-анасы белән монастырь карарга бара. Монастырь янындагы чиркәүгә керәләр, Грузин телендә поп «Мамиса, дадиса, сулиса...» дип нәрсәдер мыгырдый. Шул вакыт Володя, поп көйләгәнчә көйләп:

Әйләндер тәгәрмәчне әйдә.
Юкса безнең эш тора бәйдә, —

дип кычкыра башлый. Баланың тавышы яхшы ук көчле булганга, моны чиркәүнең һәрбер почмагында ишетеп алалар һәм, түзә алмыйча, кычкырып көлә башлыйлар.

Володяны чиркәүдән куып чыгаралар.

Сигез яшь тулгач, әнисе, Александра Алексеевна, аны Кутаиси гимназиясенә укырга илтә. Бу хәл 1902 нче елны була. Арифметика буенча имтихан яхшы уза. Күңелсезлек тел буенча булган имтиханда туа. Поп аңардан:

— «Око» нәрсә? — дип сорый.

Уйлап-нитеп тормыйча, Володя җавап кайтара:

— Өч кадак.

Володя грузин балалары белән уйнап үсә һәм грузинча «око» сүзенең «өч кадак» икәнен белә. «Око»ның нинди мәгънәдә диндә йөргәнен ул уйлап та карамый.

Мондый җавапка ачуланган поп Володяга:

— Син грузин базарында түгел, ә гимназиядә утырасың,— дип кычкыра.

Шулай да аны гимназиягә кабул итәләр, яхшы укуы, таза булуы, рәсем ясый белүе, кирәк чагында көлдерә алуы белән укучылар алдында ул бик тиз дан казана.

Иң яраткан әйбере аның рәсем төшерү була. Люда белән ул бервакыт художник Краснуха студиясенә барып чыга. Люда художникка үзенең рәсемнәрен күрсәтеп дәрес турында сөйләшкән арада, Володя кәгазь кисәгенә художникның үзен төшереп ала. Рәсемне ул карикатура итеп эшли. Моны сизеп, Люда оялуыннан нишләргә белми. Ә художник рәсемгә карап түзә алмыйча кычкырып көлә. Художник Володяның талантлы бала булуын сизә һәм аңа рәсем буенча түләүсез-нисез дәрес бирергә хәзер икәнлеген әйтә.

1906 нчы елны Володяның әтисе үлә. Семьяда болай да ярлы яшиләр. Ә Владимир Константинович үлгәннән

соң, бу ярлылык тагы да көчәя. Шул турыда сөйләшкәндә шагыйрьнең апасы Людмила Владимировна:

— Әти үлгәннән соң безнең семьяда бары тик өч кенә сум акча калган иде, — ди.

Володя төрле-төрле рәсемнәр ясап сата башлый. Квартирант булып аларда революционерлар торалар. Алар Володяның иң якын дуслары булалар. Володяга алар халык бәхете өчен көрәшүчеләр турында укырга китаплар бирәләр.

Володя яхшы дип санаган кешеләрне патша хөкүмәте төрмәләргә утырта. Володя хаксызлыкны күрә. Һәм үзе дә революцион хәрәкәткә катнаша. Аны гимназиядән чыгаралар. Шуннан соң Володя Мәскәүгә күчә, ул анда Мәскәү большевиклары оешмасында пропагандист булып эшли. Патша хөкүмәте 16 яшьлек Володяны ике тапкыр кулга ала. Ләкин нык үсмер бала яшерен саналган, сер булган бер генә әйберне дә жандармнарга әйтми. Иптәшләре кулга эләкмәсен өчен, ул адреслар язылган блокнотны переплеты белән бергә чәйнәп йота. Патша хөкүмәте аны бер ел чамасы Бутырка төрмәсендә яткыза.

1909 нчы елның январенда Маяковский төрмәдән болай дип яза:

«Кадерле Люда!

Теге көнне мине өйдән чыккач та иртә белән 11 сәгатьтә урамда кулга алдылар. Хода белсен, нәрсә өчен, һич көтелмәгәндә булды бу хәл, шунда ук тентү ясап, участокка озаттылар».

Маяковский китаплар китерүне сорый һәм болай ди:

«Бу китапларның һәммәсен дә минем бүлмәдә табарсың. Аннары Владимирдан яки Сергейдан белеш, аларда Маркс «Капитал»ының I томы юкмы икән».

16 яшьлек Маяковскийның Маркс әсәрләрен белүе, төрмәгә эләккәч тә шул әсәрләр белән кызыксынуы бик характерлы нәрсә.

Хатның соңгы өлеше Маяковскийлар семьясының ул елларда кыенлыкта, мохтаҗлыкта яшәвен аңларга мөмкинлек бирә:

«...Сергейдан мин плакат ясаган Виктор Михайловичның адресын сораш һәм барып акча ал (8 сум сора), әгәр дә плакатта тагын берәр нәрсә буярга кирәк булса, зинһар, шуны минем өчен эшлә. Бирелгән акчага училищега барып акварель краскалар сатып ал... Ләкин 3—5

сум калырлык булсын, һәм шуны миңа җибәр: монда акча кирәгер. Хуҗалыгымны рәткә китерермен дә акрын-акрын яши башлармын...»

Күрәсез, төрмәдә утырганда да Маяковский үз тормышын үзе кайгырта. Читлеккә озакка эләктем дип уйласа да, пошынмый, төшенкелеккә бирелми: «хуҗалыгын» рәткә китереп, иҗат эшенә чумарга хәзерләнә.

Тәэсиргә тиз бирелә торган Маяковский ярлы халыкның изелүен күрә. Аның якын дуслары булган грузин революционерларын эзәрлеклиләр, кулга алгач, кыйныйлар, төрмәләргә ябалар. Менә болар барысы да Маяковскийда буржуа җәмгыятенә каршы утлы нәфрәт тойгыларын үстерәләр.

Төрмәдән чыккач, ул «социалистик сәнгать» тудыру турында уйлый башлый. Мәскәүдә рәсем мәктәбенә керә һәм шунда футурист Давид Бурлюк белән очраша. Маяковский белән танышуга Бурлюк бик шатлана һәм Василий Каменскийга хат яза: «Тизрәк кайт, безгә Володя Маяковский исемле яңа көрәшче килеп язылды. Шаян, бик бәйләнчек һәм гаять тапкыр сүзле. Синең шикелле үк, безнең бөтенебез шикелле үк табигать баласы. Күрерсең. Синең белән очрашуны, авиация турында, шигырь һәм бүтән футуризмнар турында синең белән сөйләшүне түземсезлек белән көтә. Маяковский гел минем янда гына тора һәм яхшы шигырьләр яза. Табигый талантлы егет, үз-үзенә ышану белән яна. Мин аны яшь Джек Лондон дип ышандырдым. Бик канәгать...»

Күп тә үтми, алар халык алдына чыгалар. Шагыйрьнең энисе Александра Алексеевна әдәби кичәдә чыгар өчен улына сары кофта тегә. Мәскәү урамнарына сары афишалар эленә. Политехнический музей кассасында сары билетлар сатыла. Кичә буласы көнне буржуа газеталары Маяковскийлар турында мәкаләләр, фельетоннар басып чыгаралар. Фельетоннарның берсенә «Кесәләрегезне саклагыз» дигән исем бирелә. Ахмак журналист:

«Футуристлар кичәсенә бармагыз, футуристлар шагыйрь түгел, ә алдакчылар, караклар, сәхнәгә чыккан бер төркем алдакчы начар шигырьләр укыган вакытта, икенче төркеме сезнең кесәләрегезне капшап йөриячәк», — дип яза.

Әдәби кичә зур уңыш белән уза.

Маяковскийның сары кофтасы турында ул елларны күп яздылар һәм күп сөйләделәр. Ә хакыйкатьне белүче бик аз иде. Сары кофта турында Василий Каменский миңә мондый аңлатма бирә:

«Беренчедән, бу — тамашачылар алдына чыгучы язучылар өчен шарт итеп куелган сюртукларга һәм фракларга каршы протест иде.

Икенчедән, бу — эстет әфәнделәрнең «күркәм җәмгыяте»н тынычсызлый иде.

Өченчедән, бу — ике генә сум тора иде.

Дүртенчедән, Маяковский бик ярлы яши иде, хәтта пиджагы да юк иде аның.

Бишенчедән, сары төс — кояш төсе».

Маяковскийларга каршы булган көрәш әдәби кичәдән соң оешкан төс ала. Маяковскийны рәсем мәктәбеннән чыгаралар. Ләкин шагыйрь пошынмый. Бу мәктәптә уку-укыту эшләре шулкадәр начар куелган була ки, чыгарылуын ишеткәч, Маяковский болай дип җавап кайтара:

— Чыгарасызмыни? Рәхмәт! Бу мәктәптән чыгу — бәдрәфтән саф һавага чыгу белән бер бит.

Маяковский әдәбият эшенә бирелә. Аның иҗат итү минутлары бик үзенчәлекле була. Өстәлсез яза ул. Теманы урамда да, кешеләр белән сөйләшкәндә дә эшли. Шигырь юлларын кычкырып, декламировать итеп иҗат итә. Искиткеч зиһененә аның гаҗәпләнмәгән кеше булмый. Бер-ике тапкыр укып чыгуына, шигырьләрне генә түгел, гыйльми мәкаләләрне ул яттан сөйли ала. Дуслары арасында гаҗәп җылы сүзле булган Маяковский дошманнар белән очрашканда, аларга каршы көрәшкә чыкканда кискен төс ала һәм өзлексез утлы тапкырлыгы белән дошманны адәм мәсхәрәсе итеп ташлый.

Маяковский үзенең беренче дәвер әсәрләрендә үк («Штанлы болыт», «Владимир Маяковский», «Сугыш һәм дөнья» һ. б.) индивидуаль бунтарьлык тойгыларын җырлау белән бергә, байларга, изүчеләргә, тукларга капма-каршы куеп, ярлылар, изелүчеләр, ачлар дөньясын да җырлый. Шагыйрь көрәшкә чакыра. Таш, пычак һәм бомбалар алып мәйданга чыгыгыз, ди, куллары булмаганнар маңгайлары белән көрәшсеннәр, ди. Империалистик сугышка каршы чыгып, сугышның йөзенә төкерә.

Бөтен Европага
ут төртелгән,
Һәм Европа
шәмдәл итеп
күккә эленгән, —

дип гигант образлар тудыра.

Буржуа шагыйрьләре, авыз суларын корытып, империалистик сугышны мактаганда, патша һәм дин исеменнән халыкны үлемгә чакырганда, Маяковский «Тере кешегә мәхәббәтемне ничек итеп җиткерим», — дип кайгыра. «Улау, чинау эчендә» чын кеше тавышын саклауга, «киләчәк халыкларның хәбәрчесе булып» йөрүгә ул шатлана.

Революциянең чәчәкләр бәйләмен күтәреп,
уналтынчы ел килә, —

дип алдан ук хәбәр итә. Күрәсез, Маяковский бик азга ялгыша.

Табигый, шагыйрьне эзәрлекләү туктамый.

— Барыгыз, чиратка басыгыз һәм Маяковскийның «Штанлы болыт» китабын сатып алыгыз! — диючеләр берәм-сәрәм генә булалар. Тынчу һавада Маяковскийны яклап чыккан бердәнбер зур язучы бөек Максим Горький була. Буржуа тәнкыйтьчеләренә каршы чыгып, Горький болай ди: «Мисалга сез Маяковскийны алып карагыз:

Ул яшь, аңа бары 20 генә, ул акыручан, ләкин, һичшиксез, талантлы ул. Аңа эшләргә, укырга, өйрәнергә кирәк, һәм ул менә дигән яхшы шигырьләр язачак. Мин аның шигырьләр китабын укып чыктым. Бу китап чын сүзләр белән язылган».

Социалистик революция гуманист шагыйрь Маяковскийга язу өчен бөтен мөмкинлекләрне бирде. Октябрь социалистик революциясен кабул итәргәме, юкмы дип Маяковский уйланып тормады. Прогрессив кешелекнең даһие Ленин тарафыннан җитәкчелек ителгән Бөек Октябрь революциясенең көчле өермәсендә шагыйрь үзенә якын һәм кадерле булган нәрсәне күрә, кешене азатлыкка илтә торган көчне сизә һәм:

— Бу революция — минем үз революциям! — дип Бөек Октябрьны җырларга керешә.

Шунысы характерлы, Маяковскийның Бөек Октябрьдан соң язылган әсәрләрендә шәхси моментлар, төшенке

рухлы шигырьләр бөтенләйгә диярлек югалалар. Аның «мин»е хәзер «без» булып яңгырый.

Эшчеләрнең,
Зур сыйныфның дошманнары
Минем дә
күптәнге
Һәм явыз дошманнарым барысы да.
Ачлы-туклы көннәр
Һәм хезмәт еллары
Әйдәделәр безне
Кызыл флаг астына.

Бер җирдә дә, бервакытта да сатлыкта булмаган иҗатын шагыйрь революциягә бирә һәм кызыл ракета-сыман югары күтәрелгән Октябрь байрагына дан җырлый.

Маяковский күп санда шигырьләр, поэмалар, пьесалар яза. Бу әсәрләрдә ул үзен социалистик революциянең ялкынлы трибуны, политик шагыйрь-көрәшче итеп таныта.

Маяковский тормышта булган һәрбер хәлне, һәрбер политик вакыйганы социализм төзү бурычларыннан карый. Ул социализм төзү өчен файдалы әсәрләр бирүче кешеләрне генә чын язучы дип атый. Мәгълүм ки, В. И. Ленин тарафыннан макталган беренче совет шигыре дә Маяковский шигыре була. 1922 нче елның 6 нчы мартында металлистлар съездында речь сөйләгәндә, В. И. Ленин Маяковскийның шигыренә карата: «Политик һәм административ күзлектән караганда, мондый ләззәтне мин күптән татыганым юк иде... Шигърият ягыннан ничектер, белмим, әмма политик яктан, өстемә алам, бик дөрес», — дип әйтә.

Бүтән шагыйрьләр социалистик тематика өстендә эшләргә кирәк дип сөйләнеп йөргәндә, Маяковский берсе артлы берсе әсәрләр бирә.

Маяковский РОСТАда эшли. Анда ул фронттан алынган хәбәрләр буенча рәсемнәр ясый һәм рәсемнәргә шигырь белән аңлатмалар яза. Шатлыклы хәбәрләрне халыкка тизрәк житкерү өчен ул төннәр буенча йокламыйча иҗат итә. Ял итәргә ятканда да озак йокламас өчен баш астына утын агачы куеп ята. Маяковскийның шул чордагы тау кадәр эшләренә карап, аның революцион эшкә, Советлар власте өчен көрәшкә никадәр тирән, ярсу бирелгәнен күрәсең! Барлыгы 1800 плакат

ясала, шуларның иң күп өлеше Маяковскийның шигырьләре белән чыгалар. РОСТАда чыккан шигырьләрен шагыйрь үзе «алар минем икенче җыелма әсәрләрем», дип атый.

Киләчәк токымнарга мөрәҗәгать итеп, Маяковский:

Әгәр дә сез
    китап курганнарында
        шигырь юлларының
            тимер кисәкләрен тапсагыз,
        сез аларны
            иске,
            ләкин дәһшәтле коралдай
хөрмәт белән тотып капшагыз, —

дип әнә шул елларда язылган әсәрләрен истә тота.

Әйе, алар дәһшәтле кораллар иде!

Гражданнар сугышы елларында социализм темасы Маяковскийның бөтен эшенә кайнар дәрт бирә. РОСТА плакатларына язылган шигырьләр, «Мистерия — Буфф» пьесасы, «150000000» поэмасы, «Сул марш» кебек әсәрләр — менә болар бөтенесе дә социализм темасы белән яктыртылганнар.

Ленин партиясе җитәкчелеге астында көрәш алып барган халыкның җиңүенә Маяковский нык ышанган иде. Көрәштә ул миллионнарны күрде, миллионнар белән бер сафта үзе дә барды һәм миллионнарны җырлады.

Маяковский СССРның 56 шәһәрендә булды. Үз ватанын ул бик яхшы белә иде һәм Октябрьга багышланган «Яхшы» поэмасында шундый юлларны язды:

Кешелекнең
    хезмәттә һәм сугышларда
        туган язы шикелле,
Туган илне җырлыйм җырларымда,
Җырлыйм
    Республикамны!

В. И. Ленин образын әдәбиятта чагылдырырга теләү Маяковскийда күптән туа. Ленинга багышлап ул берничә шигырь яза. Ленинның үлүе Маяковскийны тирән кайгыга сала.

Аның бер сулышы өчен,
    куана-куана
        гомеремне бирер идем
            мин аңа, —

ди Маяковский. Иң кешелекле булган бөек кеше турында Маяковский үзенең «Владимир Ильич Ленин» исемле поэмасын яза. Социализм өчен көрәштә большевиклар партиясенең роле никадәр зур икәнен бик ачык аңлаган шагыйрь бу әсәрдә, бөек Ленин образын бирү белән бергә, Ленин партиясе турында да мәңге җуелмас шигъри юлларны язды.

«Владимир Ильич Ленин» поэмасы Маяковский иҗатында иң мактаулы зур урынны ала. Ленинга ул дөнья ышанычын һәм үз ышанычын җырлады.

Маяковский гасыр белән, заман белән бергә барды. Үз чорының алдынгы вәкиле буларак, ул көнкүрешнең гади тоелган вакыйгаларында да иртәгәсе көннең тууын күрде. Чын шигърият, безнең бүгенге көнебезне чагылдыру белән бергә, безнең иртәгәбезне дә күрергә тиешле.

1925 нче елны Маяковский совет авиациясенә багышлап «Очучы пролетариат» исемле реалистик фантазия яза. Бу фантазиянең инде тормышка ашуына, котыплар аша үткәндә, дошманны җимергәндә сыналган самолетларның һәм геройларның бүген чынбарлыкта булуларына без үзебез шаһит.

Шул ук 1925 нче елларны Маяковский метро турында шигырьләр яза, моның да инде тормышта булуына без шаһитбыз. Совет балаларын Маяковский кем булырга өйрәтә.

Яңа винтовкалар алыйк,
штыкка — флаглар,
Һәм җыр белән тирга барыйк,
тигез сафлар...
Өермәле сугыш купса,
сафка килик, —
Дошманнарга туры төзәп
ата белик... —

дип, Маяковский балаларны сугыш һөнәрен өйрәнергә чакырган иде. Шул җырны җырлап төз ату түгәрәкләренә йөргән элекке балалар хәзер ак финнарга каршы көрәштә батырлыклар күрсәттеләр, данга күтәрелделәр.

Иртәгәсе көн турында уйлау, киләчәккә омтылу, киләчәк кешеләргә мөрәҗәгать итү — менә болар бөтенесе дә Маяковскийны совет эпохасының иң талантлы шагыйре итеп характерлыйлар.

Иҗат кыюлыклары чорының иң яхшы шагыйре Владимир Маяковский үз әсәрләрендә яңа кешенең

социалистик хисләрен чагылдырды. Зур пафос, гаять көчле тойгы белән жырланган «Совет паспорты турындагы шигырь» совет патриотизмы темасын, Ватан өчен булган гражданлык горурлыгын әдәбиятта беренче тапкыр югарылыкка күтәрә. «Ураклы, чүкечле совет паспорты» социализм иленең көче, куәте, символы булу дәрәҗәсенә үсә. «Укыгыз, көнләшегез: мин — Советлар Союзының гражданины!» — дигән сүзләр совет кешесенең горурлыгын аңлата торган шигъри формула булып калдылар.

Совет патриотизмы темасы Маяковскийда интернационализм тойгысы белән нык бәйләнгән. Әдәбият трибунасында торып, Маяковский Англия эшчеләре белән дә сөйләшә. Халыкара аренада күренгән һәрбер политик вакыйга Маяковскийда тирән кызыксыну тудыра...

Бер ел болгатсаң да,
Болгата алмассың безне.
    һәрбер маневрда
һәм
    алдан узган роталарда
    мин ишетәм тик бер көйне:
Әй, англичанка,
    сак бул борылышларда!

Моннан 13 ел элек язылган бу юллар Англия империалистларының бүгенге кыланышларына карата әйтелгән түгелме!

Чит ил специалистлары тарафыннан җимерелмәс дип табылган ак финнарның сугыш крепостьларын Кызыл Армия ватып ташлады. Шул сугышта дан казанган батырлар турында Маяковский нинди гүзәл шигырьләр язар иде! Шагыйрьнең үткен күзе моннан 13 ел элек үк англичаннарның бомбалар, миналар төяп Финляндиягә «кунакка» килүләрен күргән иде.

Дуска — мәхәббәт, дошманга — нәфрәт тойгысы Маяковскийда бик көчле бирелә. Сатирик темпераментының бөтен көче белән ул сыйнфый дошманнар, капитализм калдыгы булган мещанлыкны, бюрократизмны, вак «мин»лекне, төрле төстәге буржуа милләтчелеген фаш итте.

Сыйнфый дошманны һәм аның идеологиясен шулай кискен фаш итүе өчен троцкийчы-бухаринчы бандитлар Маяковскийны куралмадылар. Шагыйрьнең көр тавышын юкка чыгарырга теләделәр алар. Совет чорының

казанышларын җырлаган революция җырчысы турында алар пычрак мәкаләләр язып чыктылар, шагыйрьнең иң яхшы әсәрләрен бозып күрсәтергә маташтылар.

Маяковский үлүгә 10 ел узды. Бу 10 еллык вакыт эчендә без Маяковский иҗаты никадәр тормышчан, никадәр көчле икәнен аеруча нык сиздек. Аның шигырьләре әле генә язылгансыман безне дулкынландыралар, бездә матур тойгылар кузгаталар.

Маяковский тормышка якын иде, кайнап торган тормыш эчендә иде һәм аның иҗаты да тормыш турында иде. Үзен аңламаган яки аңларга теләмәгән тәнкыйтьчеләргә ул:

— Сезгә мин шагыйрь түгел, мин — тормыш! — дия иде. Әйе, ул тормыш иде, ләкин тормыш белән бергә ул искиткеч шагыйрь дә иде. Тормыш аның иҗатында тулысынча чагылды.

Аның әсәрләрендә гаять зур җылылык бар. Моны без «Бу турыда» дигән мәхәббәт поэмасында да, «Атларга карата яхшы мөнәсәбәт» дигән шигырендә дә һәм бүтән әсәрләрендә дә күрәбез.

«Безнең җаннар төрле, сугышларда — күкрәү, ә кроватьта — пышылдау», — дип Маяковский кешенең төрле хәлдә булуын әйтте һәм кеше хисенең бөтен якларын эченә алган лирика тудыру өчен көрәште.

«Мәхәббәткә дә без мамыктан түгел, ә йөрәктән ясалган үз сүзебезне табарбыз»,—дип, ул мамыклы лирикага каршы торды.

Маяковский шигъриятенең көче — аның социалистик фикер, революцион дәрт, революцион хис шигърияте булуында. Маяковский иҗаты революцион эчтәлекле һәм шул эчтәлекне тулысынча аңлата ала торган яңа формалы иҗат. Маяковский яңа стиль тудырды.

XIX гасыр башларында рус әдәбиятына өр-яңа темалар, өр-яңа шигырь белән кояшлы яктылык алып Александр Пушкин килде һәм шуның белән үз исемен мәңгеләштерде. XX гасыр башларында әдәбиятка өр-яңа темалар, өр-яңа шигырь белән кояшлы яктылык алып Владимир Маяковский килде һәм шуның белән үз исемен мәңгеләштерде. Халык шагыйре Александр Пушкинның юлы — реалистик шигърият югарылыгына житкән юл иде. Халык шагыйре Владимир Маяковский юлы — социалистик реализм шигърияте югарылыгына җиткән юл.

Пушкинга багышлап язылган шигырендә Маяковский үзен Пушкин һәм Некрасов белән тиңли. Шагыйрь хаклы. Маяковский исеме Пушкин, Лермонтов, Некрасов шикелле халык шагыйрьләре исеме белән янәшә тора.

Совет әдәбияты хәзер бөтен дөнья әдәбиятының авангарды булырлык хәлгә килде. Тираж зур булса да, китапларның тиз таралып бетүе, язучылар белән укучылар арасында булган нык мөнәсәбәт, төрле-төрле конференцияләр, юбилейлар, иҗат кичәләре — менә болар барысы да халыкның әдәбиятны никадәр якын итүен күрсәтәләр. 180 язучыны СССР орденнары белән бүләкләү дә шул ук тойгыны аңлаталар...

Маяковский иҗаты, Маяковский көрәше, аның намуслы хезмәте — язучыларыбыз өчен яхшы үрнәк булырга тиешләр.

«Бөтен тавыш белән» дигән иң соңгы әсәрендә ул, 20 еллык иҗатына нәтиҗә ясап, болай ди:

Баштанаяк
коралланып беткән,
егерме ел җинүләрне үткән
шушы гаскәремнең барын да
соңгы битенәчә
бирәм
сиңа —
Планетаның пролетариатына...
...Партияле
китапларымның
томнарын алып,
барырмын мин
киләчәк һәм якты көннәр
Цека Ка Ка сына,
һәм аларны
большевистик
Партбилет күк итеп
күтәрермен
комсыз һәм өтелгән
Шигъри бандаларның өстенә.

В. И. Ленин 1905 нче елны ук «Әдәбият партияле булырга тиеш» дип әйтте. Үз иҗатын Ленин карашына буйсындырган шагыйрьләр арасында Маяковский беренче шагыйрь иде. Даһи шагыйрь булу, әлбәттә, зур нәрсә. Ләкин гасырларга керү өчен коры даһилык кына житми. Даһилыкның халык өчен, прогрессив кешелек өчен хезмәт итүе дә кирәк. Маяковский әнә шул сыйфат-

ны әдәбиятны партияле итеп караудан тапты. Әнә шуңа күрә дә Маяковский иҗаты, үлмәс совет халкының үлмәс әдәби байлыгы булып, буыннан буынга, гасырлардан гасырларга күчәр...

Ленин турындагы китабының беренче битенә Маяковский бу әсәр большевиклар партиясенә багышлана дип язды. Шагыйрьнең бөтен иҗаты большевиклар партиясенә һәм аның идеяләренә багышланды. Максим Горький һәм Владимир Маяковский ленинизм идеяләренең шигъри трибуннары иделәр.

Ленинизм беркайчан да үлмәс. Ленинизм идеяләрен җырлаган Маяковский иҗаты да мәңге яшәр.

1940

ҺӘРВАКЫТ ИСТӘ

1928 нче елда Максим Горькийның Казанга килү хәбәре шәһәребезгә бәйрәм төсе кертте. Шатлыклы хәбәр яшен тизлеге белән таралды — пристань тирәсе халык белән тулды. Без ерактан күренгән аксыл пароходтан күзебезне алмыйча, аның тизрәк килеп җитүен көттек...

Пароход палубасында рәсемнәре буенча күптән таныш булган сөекле кешенең озын буйлы сыны күренде. Бу — бөек Горький иде. Ул, башындагы бизәкле түбәтәен кулына алып болгый-болгый, аңа кайчандыр университет булган тарихи Казанны һәм Казанның яңа кешеләрен котларга кереште. Җыелган халык бөек давыл кошын, әдәбиятның горур лачынын ура кычкырып сәламләде.

Каршы алырга килгән партия, хөкүмәт вәкилләре һәм язучылар белән салонда бераз вакыт дусларча сөйләшкәннән соң, Алексей Максимович Горький яр буена чыкты. Халык диңгезе аның сөйләвен көтте. Ләкин кайнар рәвештә каршы алып олылаудан һәм яшь чагында йөргән җирләрне кабат күрүдән дулкынланган Горький 2—3 кенә җөмлә әйтә алды. Китәргә торган машинада аягүрә торып болай диде ул:

— Иптәшләр, хәйран калырлык эшләр торгызган-

сыз... Бик шатмын. Мин искиткеч үзгәреш күрәм... Котлыйм... Чын йөрәктән котлыйм... Мин шулкадәр дулкынланганмын ки, хәзер сөйләрлек хәлдә түгелмен... Рәхмәт, иптәшләр!..

Кич белән зур театрда тантаналы утырыш булды. Язучыларның һәм матбугат работникларының Горький белән очрашуларына аерым кичә багышланды. Элекке мәдәният йортында булырга тиешле бу кичәгә чакырып, мәрхүм Такташ белән мин «Казан» гостиницасына Горький янына бардык һәм җыелыштан соң, Островский, Бауман урамнары ерып үтмәслек дәрәҗәдә халык белән тулганга күрә, Горькийны без караңгы тыкрыклар буенча яңадан номерга озаттык. Бөек әдипне күрергә теләгән халык бик озак таралмыйча торды. Горький гостиница балконына чыгып кыска гына речь сөйләде.

Язучылар белән очрашу кичәсендә А. М. Горький илебездәге уңышларга тукталып, бу уңышлар турында кичекмәстән язарга кирәклекне әйтте. Һәм шуңа багышланып чыгачак «Наши достижения» журналына язышырга чакырды.

Татар әдәбияты белән болай да таныш булган Горькийның татар культурасына мәхәббәте һәм аны тагын да күбрәк белергә тырышуы гаять зур иде. Татар җырларын яратып тыңлавы әле дә хәтеремдә. Тәнәфес вакытларында һәм банкетта Горький: «Татар халкының талантлы Тукае бар», — дип кайта-кайта сөйләде. Шундый ук югары бәяне ул соңыннан (татар язучылары Мәскәүдә Максим Горькийда кунак булганда), татар телендә шигырьләрен тыңлаганнан соң, Һади Такташка да бирде.

Казанга Горький үзенең улы Максим Алексеевич белән килгән иде. Казанның һәрбер почмагы диярлек Горькийга аерата якын тоелганга күрә, ул күп кенә җирләрдә булырга тырышты. Үзе булырга өлгермәгән урыннарга улының баруын үтенде. Һәм без, берничә татар совет язучысы, Максим Алексеевичны Казан белән таныштырып йөрдек. Соңыннан Горький:

— Рәхмәт, улым — минем булышчым. Аны таныштыру — мине таныштыру дигән сүз. Ул миңа барын да сөйләр, — ди иде.

Заманыбызның бөек әдибе белән очрашу бездә, татар совет әдәбиятының яшь вәкилләрендә, мәңге җуелмас-

лык кайнар тойгы калдырды. Бу тойгы безгә аны һәрвакыт тере күрергә, безне намуслы эшкә, халык бәхете өчен көрәшкә чакырган әдәби атабыз итеп һәрвакыт күз алдында тотарга ярдәм итә.

1941

«АЛТЫНЧӘЧ» ПРЕМЬЕРАСЫНДА

Яхшы әсәр бервакытта да үзенең кыйммәтен югалтмый. Киресенчә, аның көче тарихи вакыйгалар фонында тагы да ачыграк сизелә. Нәҗип Җиһановның Татар дәүләт опера һәм балет театрында зур уңыш белән бара торган «Алтынчәч»е (М. Җәлил либреттосы) әнә шундый бөек әсәрләр рәтенә керә.

Бу гүзәл операда без халыкның үлмәс көч булуын, халык улларының Ватанга булган кайнар мәхәббәтләрен күрәбез, опера безне җиңелмәс Тугызак шикелле көчле булырга, табигать баласы Җик шикелле батыр, патриот булырга чакыра.

Әсәр безгә кояш төсле Алтынчәчнең матурлыгын һәм Җик Мәргән белән Алтынчәч арасындагы мәхәббәтнең сафлыгын, тирәнлеген җырлый. Баһадир Җик Тугызак иленә кыргый һөҗүм ясаган канечкеч Мәмәт ханның гаскәрләрен тар-мар итә. Ул, елан нәселеннән килгән Кулупайны үтереп, халык азатлыгы өчен көрәшә.

Бер үк вакытта ерткыч та һәм куркак та булган Мәмәт хәзерге заман каннибалларын күз алдына китерә. Ул Тугызакның күзләрен чукып алдыра, аның аякларын яралата, йорт-җирләрен яндыра һ. б. Мәмәтнең котыруы халык тарафыннан аның юкка чыгарылуы белән бетә. Тамашачылар беләләр: шакал гитлерчылар шулай ук юкка чыгарылачаклар.

Җиһанов — көр тавышлы композитор. Аның музыкасында безнең илебезгә хас яхшы авазлар күп. Аның әсәрләрендәге образлар да хезмәт халкының көчен-куәтен чагылдыра торган батыр образлар. «Качкын»дагы Булат, «Ирек»тәге Шамил һәм «Алтынчәч»тәге Җик — болар барысы да композиторның төп иҗат юлын билгели торган образлар.

Лирик нечкәлекләрне оста бирү белән бергә (Алтынчәч, Җик һәм Тугызак арияләре), хорларда һәм дуэтларда композитор элекке операларына караганда тагын да тирәнрәк художество югарылыгына ирешә.

Дирижер Җәләл Старжиһанов, әсәрне сәхнәгә куючы Л. Баратов, художник Б. Матрунин, хормейстер В. Гаврилов, режиссер З. Сафин һәм постановка өстендә эшләгән бөтен коллектив бу спектакль белән опера театрыбызның тарихында иң яхшы сәхифәләрнең берсен ачтылар.

Спектакльдә театрның балет труппасы да күренекле урын ала. Балет солистларыннан анда Балтачеева, Шәмсетдинов, Кумысников һәм Рәхимов иптәшләр катнашалар. Балетмейстер Г. Таһиров аргамакларда җилдәй очкан атлыларны хәтерләткән «Аучылар биюе»н һәм сарай пәрдәсендә кызларның шарфлы биюләрен сәхнәгә куюда күп кенә иҗат кыюлыгы күрсәткән. Ләкин бүтән биюләр куелыш ягыннан канәгатьләнерлек түгел әле. Алар я әсәргә ятышлы түгелләр, я Җиһанов музыкасындагы матурлыкны биреп җиткермиләр.

Төп партияләрне башкаручыларга килгәндә, Рахманкулова, Зәбирова (Тугызак), Әлмиев (Урмай) һәм Кайбицкая белән Котдусова (Алтынчәч) иптәшләрнең җырлауларыннан, уйнауларыннан тамашачыларда тәмамлашкан образлар тәэсире калуын әйтергә кирәк. Тугызак аерата көчле тәэсир калдыра. Бүтән партияләр дә уңышлы башкарылалар. Ләкин алар өстендә эшлисе бар әле. Насретдинов һәм Даутов, лирикага күбрәк әһәмият биреп, Җикнең баһадирлыгын, аның эчке һәм тышкы мәһабәтлеген ачып җиткермиләр. Ростовцев ханы вокаль яктан яхшы үтәлсә дә, образ буларак, сәхнәләрдә күренеп узган рыцарьларны хәтерләтә. Алеев ханы уңышлырак бирелә, бары тик образга хас булган кара буяуларны (ерткычлыкны, комсызлыкны) тагын да арттыра төшәргә кирәк. Музыкада болар бик табигый һәм мул бирелә. Тугызакның Мәмәткә «җәллад» дип эчке нәфрәт ташлавы Алеевның уенында тулысынча күренергә тиеш. Сәйфетдинов Урмае да начар тәэсир калдырмый. Ләкин анда Алеев бирә алган мәкерлек һәм тапкырлык җитешми.

Бу кимчелекләр операның кыйммәтен югалтмыйлар һәм спектакльгә зур зарар китермиләр, әлбәттә.

«Алтынчәч» — зур спектакль. Ул татар совет сәнга-

тенең бөтен дөнья культурасы юлына чыгуын күрсәтә һәм совет чорында чәчәк аткан татар культурасының зур казанышы булып тора.

1941

ӘДӘБИЯТ ЭШЕ — ДӘҮЛӘТ ЭШЕ

Председатель: Сүз фронтовик язучы иптәш Кутуйга бирелә.

Кутуй: Ленинград фронтында, юлда очраган барлык киртәләрне җимереп, бертезлексез алга барган совет гаскәрләре арасында Волга буе сугышларында туган Н нче гвардия часте бар. Аның солдатлары һәм офицерлары Ватан өчен көрәштә үзләрен һәм үзләренең дәһшәтле коралларын мәңгелек данга күмделәр. Бу частьта татарлар да, Татарстаннан булган рус иптәшләр дә байтак санала. Җай туры килүдән файдаланып, аларның әманәтләрен үтим: сезгә, сезнең аша Татарстандагы барлык хезмәт солдатларына һәм командирларына фронтовик якташларыгызның ялкынлы сәламнәрен тапшырам. (Кул чабулар.)

Элек «Туплар сөйләгән чакта, музалар тын тора»,— диләр иде. Хәзер бүтәнчә әйтәләр: «Совет орудиеләре тавышы шагыйрьләр тавышы белән бергә кушылып яңгырый», — диләр.

Ватан өчен барган изге көрәш сугышта шагыйрьнең һәм әдипнең урынын күрсәтте. Шагыйрь сүзе — сөңгегә тиң: ул дошманны чәнечте һәм чәнчә. Әдип сүзе трибун большевик сүзенә тиң; ул совет кешеләрен батырлыкларга өнди.

Әдип-шагыйрьләр саны 50 дән арткан Татарстан совет язучылары союзы халык белән бергә сугышның беренче көннәрендә үк үзен сугышка җәлеп ителгән санады. Иң алдынгы каләм көчләребез үзләре теләп фронтка киттеләр. Алар арасыннан кайберәүләрен без инде мәңге күрмәячәкбез: алар туган ил өчен көрәшкә җырларын гына түгел, гомерләрен дә бирделәр.

Язучыларыбыз Бөек Ватан сугышы көннәрендә дәүләт эше дәрәҗәсенә күтәрелгән гаять зур, җаваплы эш алып баралар. Фронтларда газеталар чыгаралар, китаплар бастыралар. Газеталар һәм китаплар аша сугышчы-

ларыбызга көч, дәрт бирәләр, батырларга дан җырлыйлар. Язучыларыбызның күбесе сугышта күрсәткән хезмәтләре өчен орденнар һәм медальләр белән бүләкләнделәр.

Кулына мылтык тотып, турыдан-туры сугыш утына кергән язучыларыбыз да аз түгел. Героик халкыбызның бүтән батыр улларыннан алар һич тә аерылмыйлар: немец илбасарларны аяусыз кыйнауда искиткеч кыюлыклар күрсәтәләр.

Татарстан Совнаркомы һәм ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты тарафыннан күрсәтелгән җитди игътибар аркасында, татар совет әдәбияты сугыш чорындагы бу өч ел эчендә тагын да ныграк үсте, тирәнәйде, аның халыкка йогынты ясау көче артты.

Фронтларда йөргән язучыларыбыз да, тылда яшәгән язучыларыбыз да Ватанга кайнар мәхәббәт, дошманга чиксез нәфрәт белән тулы күп кенә әсәрләр бастырып чыгардылар. Без сугышка кадәр ничектер читтәрәк, тормыштан аерылыбрак эшли идек. Китапларыбызның каһарманнары итеп алына торган кешеләрне дә аз өйрәнә, аз белә идек. Сугыш безне кабинетлардан бәреп чыгарды һәм кайнаган тормыш эченә ташлады. Бу хәл иҗатыбызга уңай йогынты ясады. Китапларда бөек гадилек һәм тормыш чынлыгы, тере кешеләр һәм дөрес тойгылар тулырак күренә башлады. Муса Җәлилнең «Тупчы анты», Фатих Кәримнең «Мәхәббәт һәм нәфрәт»е, Мирсәй Әмирнең «Миңлекамал»ы, Кави Нәҗминең «Фәридә»се, Михаил Бубенновның «Ак каен»ы, Хатип Госманның «Ялкынлы йөрәк»е, Әхмәт Ерикәйнең «Геройлар турында»сы һәм башкалар әнә шушындый рухта язылганнар. Гомәр Разинның «Намус»ы да әнә шул ук рухта языла.

Депутат иптәшләр! Мин әле Татарстандагы авыл Советлары председательләренең күптән түгел генә булып узган киңәшмәсенә катнаштым. Анда мин иптәшләрнең китаплар, уку йортлары һәм көтепханәләр турында сөйләүләрен аерата кызыксынып тыңладым. Халкыбызның культура үсеше 1944 нче елга билгеләнгән бюджетта да нык чагыла. Бюджеттагы барлык сумаларның 72,4 проценты социаль-культура чараларына билгеләнә. Үткән елдагы үтәлешкә караганда, бу 71 568,8 мең сумга артыграк.

Матур әдәбият — культура үсешенең иң зур тармагы. Яшь буынны тәрбияләү өчен яхшы китаплар кирәк.

Җырлар, либреттолар рәвешендә китап композиторларга, пьесалар рәвешендә театрга, артистларга кирәк. Китап — сугышчының иң якын дусты.

Татар әдәбияты — тамыры гасырларга сузылган бай әдәбият. Ләкин, аянычка каршы, әдәбиятыбызның үткән юлы кирәгенчә өйрәнелми. Әдәбиятка караган бик күп кыйммәтле документлар, язучыларыбызның кулъязмалары, классик әдип-шагыйрьләребезнең тормышларын яктырткан теге яки бу материаллар бер кулга — дәүләт кулына тупланмаганнар.

Пушкин язган каләмне күргәнем бар минем. Лев Толстой язган «Яңадан туу» (Воскресение) вариантларының янмас шкафларда мәхәббәт белән саклануына сокланып караганым бар. Пушкин бик күптән, моннан йөз ел элек үлде, ләкин аның каләме дә, кулъязмалары да сакланган. Ә Тукайның үлүенә 30 гына ел, әмма аның каләмен күрсәтүче табылмас. Тукайга баглы материаллар гына түгел, әле бары тик моннан 10—15 кенә ел элек үлгән Мәҗит Гафури, Һади Такташ шикелле шагыйрьләрнең дә материаллары төрле кулларда төрлечә чәчелеп яшиләр.

Әдәбият музее кирәк, иптәшләр. Аның мөһимлеген мин түбәндәге исемнәр белән дә исбат итә алам. Казанда Пушкин һәм Маяковский булдылар. Казанда Лев Толстой, Максим Горький һәм русның бүтән зур язучылары озак вакытлар яшәделәр. Бу турыда материаллар җыю һәм әдәбият музее аша шуның белән киң массаны тәрбияләү гаять зур эш бит.

Татарстан совет язучылары союзы, ВКП(б) өлкә комитетының Казанда әдәбият музее ачу турындагы карарын котлап, депутатлардан бюджетта шуңа акча билгеләнүне сорый.

Казан — университетлы карт шәһәр, югары мәктәпләр шәһәре ул, индустрия шәһәре ул, татар культурасының үзәге ул.

Без 1941 нче елда Казанда атаклы француз язучысы антифашист Жан Ришар Блокны, мәшһүр итальян язучысы антифашист Джерманеттоны һәм рус язучыларыннан Демьян Бедный, Александр Фадеев һәм бүтәннәрне күрдек. Алар Тукай иҗаты белән бик кызыксындылар, Тукай һәйкәлен күрергә теләделәр. Шуны күрсәтүне бездән үтенделәр. Аяныч хәл: татар совет язучысы аларга Тукай һәйкәлен күрсәтә алмады.

Бәрсә дә дулкыннарың, һич алмады, гарык итмәде,
Алды дүрт ягымны ялкын, якмады, харык итмәде.
Бу сәбәптән аңладым мин, и туган жирем, синең
Җанга ягымлы икәндер ялкының да дулкының!
Җөмләтән изге икән ич: инешең, чишмән, кырың,
Юлларың, авыл, әвен, кибәннәрең дә ындырың.

Мин менә шушындый патриотик әсәрләр язган татар халык шагыйре Габдулла Тукайга һәйкәл салу турында әйтәм.

Пушкин белән Лермонтовны Тукай үзенең остазлары дип атады. Иң элек ул аларның җәүһәр әсәрләрен татарчага тәрҗемә итү эшенә керешге. Хәзер дә әле Тукай тавышы иблис хөкүмәте вәкилләренә — адәм ашаучы гитлерчыларга каршы каты җаваптай булып яңгырый:

...Рус жирендә без әсәрле, эзле без,
Тарихында бер дә тапсыз күзге без,
Рус белән тормыш кичердек сайрашып,
Тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып...
Һич бетәрме тарихи бу бергәлек? —
Без туган бер жепкә бергә теркәлеп...

Китерелгән мисаллар халык шагыйре бөек патриот Тукайга һәйкәл салу турында ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты һәм Татарстан Совнаркомы чыгарган карарны тормышка тизрәк ашырырга кирәклекне житәрлек аңлаталар дип уйлыйм.

Татарстан совет язучылары союзы депутатларга мөрәҗәгать итә һәм сессиядән һәйкәл салырга акча билгеләүне сорый.

Депутат иптәшләр!

Теге яки бу халыкның культура үсеше турында сөйләгәндә, иң элек аның әдәбиятына тукталалар. Матур әдәбият аның ни дәрәҗәдә торганлыгын күрсәтә. Рус халкы арасында татар язучылары әсәрләрен укырга теләк бик зур. Максим Горький инициативасы белән татар матур әдәбиятыннан кайбер үрнәкләрне революциягә хәтле үк рус теленә тәрҗемә итү эше башланган иде.

Бу соңгы елларны безнең кайбер әсәрләребез Америкада да чыкты. Ленин милли политикасы татар әдәбияты алдында киң мәйдан ачты. Мәскәү, Киев, Тбилиси һәм башка шәһәрләр бездән тәрҗемәләр сорыйлар.

Язучылар алдында бик мөһим бурычлар тора: ТАССРның 25 еллыгына хәзерләнү, Советлар Союзы Геройлары исемен алган якташларыбыз турында китап чыгару, идея-художество яктан югары сыйфатлы романнар, пьесалар, поэмалар, хикәяләр — һәрбер телгә тәрҗемә итәргә яраклы яхшы китаплар бирү.

Менә шушындый зур эшләр өчен язучыларга иҗат командировкалары кирәк, подстрочниклар эшләтү өчен тәрҗемәче кадрларыбызны бүтән эшләрдән бушатып, язу өстәле артына утыртырга кирәк.

Татарстан совет язучылары союзы әдәбиятыбызны дәүләт эше дәрәҗәсенә күтәрү өчен сессиядән аңа өстәмә рәвештә акча билгеләүне сорый.

Без тарихи чорда, Совет чорында яшибез. Яхшы китап өчен әдип-шагыйрьләр зур сумалар белән бүләкләнеп тәкъдир ителә торган илдә яшибез.

Мин күтәргән мәсьәләләр сессия тарафыннан җитди каралыр һәм язучылар союзының үтенече кабул ителер дип уйлыйм.

Бу трибунадан минем шагыйрь буларак та файдаланасым килә: шигырь укырга рөхсәт итегез[1]. (Кул чабулар.)

УЛ СУГЫШТА ҮСТЕ

Без блиндаж янында басып тора идек. Ком сибелгән сукмак буйлап, салмак адымнар белән, ир уртасы офицер узып китте. Минем күптәнге танышым рядовой Петров:

— Беләсезме бу кем?—дип миңа сорау бирде.—Белмисезме? Ничек инде белмисез?!—Петров гаҗәпләнде һәм, үзенең иң яраткан кешесе турында сөйләгәндәй, җылы тавыш белән дәвам итте: — Солдатларның иң якын дусты, иң якын киңәшчесе һәм тәрбиячесе Мөхәммәт Едиханов була ул.

Петров мине аның тәрҗемәи хәле белән таныштырды. Ул Сакмар суы буенда үскән. Ләкин аңа матур табигать

---

[1] «Иртәнге уйлар» шигырен укый.



«Берлин юлында очрашу» исемдәге очеркның кульязмасыннан өзек.

кочагында бәхетле балалык көннәрен татырга туры килмәгән. Ул бик иртә ятим калган: аңа 9 яшь чакта әтисе, 13 яшь чакта әнисе үлгән. Мөхәммәтнең ике абыйсы һәм ике сеңелесе булган. Абыйлары яшь Совет республикасын яклаганда Кызыл Гвардия сафында корбан булганнар, сеңелләре авырып үлгәннәр. Ул ялгыз калган.

Ләкин безнең илдә кешенең ялгыз калуы мөмкин түгел. Мөхәммәт балалар йортына кергән, илнең мәрхәмәтле кешеләре аңа ярдәм кулы сузганнар, аны тәрбияләгәннәр, аңа белем биргәннәр. Соңыннан ул педагогия институтын тәмам итеп, үзе дә укытучылык эшенә керешкән.

Миңа иптәш Едиханов хезмәт иткән полкта берничә көн торырга туры килде. Мин һәрвакыт һәм һәр

җирдә дип әйтерлек аның фамилиясен ишетә идем. Я: «Моны Едихановтан сорарга кирәк», диләр, я: «Мин Едихановны күрдем, ул миңа болай дип әйтте», я: «Едиханов килсен, ул хәл кылыр», дип аның исемен сөеп әйтәләр. Һәр блиндажда, һәр отделениедә аның кулы сизелә.

Миңа иптәш Едихановның үзе белән дә танышырга туры килде. Аның агара башлаган чәче, йөзендәге яра эзләре һәм эшкә сәләтлелеге минем дә аңа мәхәббәтемне кузгаттылар.

Мин бу юлларны язганда иптәш М. И. Калининның «Кызыл Армиянең тарихи җиңүләре» дигән мәкаләсен хәтерләдем. Ул анда Ватан сугышын рядовой булып башлаган кешеләрнең бүген капитан, майор, хәтта полковник дәрәҗәсенә ирешүләре турында яза. Мөхәммәт Едиханов сугышка рядовой булып килә. Ул катнашкан беренче каты бәрелеш Мәскәү янында, Хорошиловода була. Мәскәү янындагы сугышларда Едиханов, миномет расчеты командиры буларак, күп кенә немецларның башларына җитә. Шул ук вакытта ул дивизия парторгы булып та эшли һәм батарея командиры яралангач, аны алыштыра, шәхси батырлык күрсәтеп, сугышчыларны дошманга каршы җиңүгә рухландыра.

Едихановка кече политрук исеме бирелә, һәм ул батареяда комиссар булып кала.

Башкалабызны яклап, немецларның арка сөякләрен сындырган сугышчылар Иделгә җитәләр. Монда Едихановка 13 кешедән торган кечкенә генә төркем белән (үзе 14 нче) 250 немецка каршы каһарманнарча көрәш алып барырга туры килә. 14 совет сугышчысы 160 гитлерчыны үтерә, әмма үзләре бары тик бер генә кешеләрен югалталар. Едиханов җитәкчелегендә барган бу каты бәрелешне генерал күзәтә һәм солдатларның батырлыкларына хәйран кала. Алар бөтенесе дә орденнар белән бүләкләнәләр, ә Едихановның үзенә, аның оста командирлыгын тәкъдир иткәндәй, Александр Невский ордены бирелә.

Шушы соңгы каты сугышлар нәтиҗәсендә булдыклы офицер Едихановка өлкән лейтенант исеме бирәләр һәм аны батальонга командир урынбасары итеп билгеләләр.

Немецлар Идел буенда да җиңеләләр. Мөхәммәт Едихановның сугыш юлы гел үзгәреп тора. Ул ике тапкыр

каты яралана, ләкин аның яшьтән үк чыныккан организмы бу яраларны тиз җиңеп чыга.

Каты сугышларның берсендә батальон командиры яраланып сафтан чыга, командирлык вазифасын иптәш Едиханов үз өстенә ала һәм ул, авыр шартлар булуга карамастан, барлык операцияләрне дә уңышлы башкара.

Мөхәммәт Едиханов II дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә һәм аның погоннарында тагы бер йолдыз арта: ул капитан була.

Минем белән очрашканда, Едиханов майор иде инде. Моңа ул үз өстендә эшләү, сугыш теориясен өйрәнү нәтиҗәсендә ирешә. Хәзер ул полк парторгы булып эшли. Полк командиры аның турында:

— Едиханов — яхшы оештыручы, кыю офицер, булдыклы командир, — ди.

Подполковник Ибраһим Яхин:

— Анда көч чишмәсе бар. Бу чишмә — партиягә бирелү, партия эшен ярату, — ди.

Солдатлар аның турында:

— Ул һәрвакыт безнең белән, ул безнең янга иң авыр минутларда да килеп чыга һәм безнең хәлне җиңеләйтә. Ул коммунистларны гына түгел, коммунистлар аша полктагы бөтен сугышчыларны да тәрбияли,—диләр.

Ватан сугышын рядовой булып башлаган һәм бүгенге көнне майор булган Мөхәммәт Едихановның сугышчан юлы Кызыл Армиянең үсүен һәм ныгуын күрсәтә.

Сугыш юлын Мәскәү янында башлаган Едиханов хәзер инде Берлинга якынлашып бара. Аның белән икенче тапкыр очрашуыбызны без Берлинда билгеләдек.

1944

КҮПЛӘРДӘН БЕРӘҮ

Нарев елгасының уң яры буенда булган каты сугышларда совет артиллеристлары искиткеч батырлыклар күрсәттеләр. Плацдарм сакланып калу гына түгел, ул бик күпкә киңәйтелде дә. Нарев елгасының аргы ягын-

да хәзер юллар әллә ничәшәр километрга сузылалар. Бу юллардан узганда күзләргә щитлар чагыла. Щитларга рәсемнәр эленгән, рәсемнәр астына «Плацдармны саклап калучы баһадирлар» дип язылган. Баһадирларның күбесе — артиллеристлар.

Окопларда һәм блиндажларда, танкларда һәм самолетларда сугышчылар кулында листовкалар йөри. Без блиндажга барып кергәндә, капитан Х. Муратов шундый листовкаларның берсен укый иде.

— Әмма һәйбәт сугышалар да соң безнең артиллеристлар! — диде ул безгә карап һәм: — Мә, укыгыз! — дип, әлеге листовканы сузды.

Кулдан кулга күчеп йөргән бу листовка татар улы Ким Нуретдинов турында иде. Бу кичне безнең бөтен сүзебез орудие командиры сержант Нуретдинов хакында гына булды диярлек. Иптәшләр аның аз сүзле, салкын канлы сугышчы, каты таләпле командир һәм яхшы иптәш булуы турында сөйләделәр. Аның күп төрле сугыш эпизодларын телгә алдылар.

Сугышчылар телендә йөргән эпизодларның берсе менә моннан гыйбарәт.

Таң вакыты иде. Немецлар безнең позицияләргә каты ут ачалар. Бөтен әйләнә-тирә һичнәрсә күренмәслек тузан һәм төтен белән каплана. Нуретдинов бу вакыт ут кырында була. Ул траншея буйлап алга чыга һәм дошманның кайда җыелуын, кайсы юлдан килеп чыгарга хәзерләнүен күзәтә, шунда ук, гитлерчыларның, көтү булып, байтак санда бер урында тупланып торуларын сизә.

Озак та үтми, ул үзенең расчетына:

— Дошман җыелган урынга осколочныйлар белән ут! — дип команда бирә.

Немецлар өере өстенә туры төзәп атылган ядрәләр төшә. Көтелмәгән бу дәһшәтле ут фрицларны таралырга, качарга мәҗбүр итә. Элекке урында дошманның Нуретдинов ядрәләре белән сафтан чыгарылган 50 дән артык солдат һәм офицеры кала.

Нуретдинов ялгышмаган. Нәкъ ул уйлаган, ул көткән юлдан немецлар танк һөҗүме башлыйлар. Нуретдинов расчеты янында ядрәләр ярыла. Салкын канлы командир куркып калмый. Орудие дошман уты астында бүтән урынга, немец танкларын каршы алу яхшырак һәм җайлырак булган урынга күчерелә.

— Атыйк инде, бик якын бит, — ди наводчик.

Нуретдинов дәшми. Аның күзләре җилпәзәсыман тезелешеп килгән немец машиналарына текәлгән. Якында дошман ядрәләре ярыла, баш очыннан пулялар сызгырып оча, әле анда, әле монда лып та лып тимер кисәкләре төшәләр.

— Атыйк инде! — ди наводчик.

Командир бу юлы да дәшми. Бары тик, бөтенесе дә хәзерме дигәнсыман, расчетка күз төшереп кенә ала. Сугышчылар аның сүзен танклар 200 метрга якынлашкач кына ишетәләр.

— Ватан өчен! — дип атарга команда бирә ул.

Бер-бер артлы утлы ядрәләр очалар. Җилпәзә тәртибе бозылган танкларның икәве дөрләп яна башлый.

— Кая качасыз? Кача алмассыз! Менә монысы туган илем — Татарстан өчен! — дип, Нуретдинов тагын, тагын ата.

Өченче танкка да ут каба.

Дошманның танк һөҗүме, уңышка ирешә алмыйча, кире кайтарыла. Ләкин бераздан атака яңадан кабатлана. Нуретдинов орудиесе ядрә тиеп зарарлана. Кыю артиллерия расчетын немецлар, камап алып, юк итәргә телиләр.

— Совет артиллеристлары тереләй бирелмиләр! — дип, Нуретдинов иң авыр хәлдә дә салкын канлылыгын югалтмый.

— Безнең кулларда винтовкалар һәм гранаталар бар әле, шулар белән үтерик дошманны! — ди ул.

— Винтовкасыз, гранатасыз калсак, тешләребез бар, дошман бугазын тешләребез белән чәйнәп өзәрбез! — ди ул.

Немецлар бу юлы да чигенергә мәҗбүр булалар.

...Капитан Х. Муратов Ким Нуретдиновны күреп тә белә булырга кирәк. Ул аның турында җырдай матур, җырдай тыңлап туйгысыз хикәя сөйли. Сүзгә майор Василий Кононюк та катнаша.

— Артиллерист Нуретдинов исеме, буыннан буынга күчеп, мәңгелеккә керер. Кешене үлмәс иткән батырлык әнә шул була инде, — ди ул.

Без блиндаждан чыгабыз һәм Нуретдинов көрәшеп алган таучыклар аша Көнбатышка таба — алга юл тотабыз.

1944

АЛАР ӨЧӘҮ ИДЕ

Җәйге айлы кичләрнең берсендә офицер Кәрәм Әхмәтҗанов кинога юнәлде. Кайдадыр күктә самолетлар гүләгән һәм якын гына туплар аткан тавышлар ишетелә иде. Ләкин ике ел буе фронтта яшәгән Кәрәмнең моңа исе китмәде. Ул үзен фронттан ерак шәһәрдә яшәгәндәй хис итеп, кәефле хәлдә атлый бирде. Аңа бүген ял рөхсәт иттеләр. Ул һәйбәтләп кырынды, юынды, өс-башын алмаштырды һәм җырлый-җырлый блиндаждан чыкты.

Бездә биек таулар бар,
Тау астында таллар бар,
Талда — яфрак, бездә — сагыну,
Сездә нинди хәлләр бар?

Туган йортың турында уйланудан килеп чыккан җыр өйне сагындырды. Кәрәмнең күптән, бик күптән инде өйдә булганы юк. Өйдән килгән хатларга караганда, өлкән лейтенант Кәрәмнең энесе дә, әтисе дә кайсыдыр фронтта немецларга каршы көрәш алып баралар: ләкин ул алар белән хатлар аша булса да багланышка керә алганы юк.

Ай болытлар арасына кереп югалды. Кәрәм кино булачак бина алдында танышларын очратты һәм, кино башланмаганлыктан, алар белән сүзгә кереп китеп, тәмәке кабызды.

— Иптәш өлкән лейтенант, сез Кәрәм Әхмәтҗанов түгелме? — дип кемдер аңа сорау бирде.

— Әйе, мин Кәрәм Әхмәтҗанов булам,— дип, ул тавыш килгән якка борылды. — Ә сез кем буласыз?

— Җентекләбрәк карагыз, бәлки, танырсыз...

Кәрәм бер генә секундка кесә фонарен яктырткан иде, кулларын җәеп сикереп куйды. Һавада саф татарча әйтелгән «Абый!», «Энем!» сүзләре яңгырадылар.

Озак вакыт күрешми йөргән туганнарның бергә туры килүләре, көтмәгәндә очрашулары бик шатлыклы була, ләкин очрашу шатлыгы, гадәттә, сүзсез уза. Бу вакыт кеше шундый хәлдә кала ки, шатлыгын аңлатырга сүз таба алмый ул. Әхмәтҗановлар белән дә шундый хәл булды.

— Әткәй дә монда,— диде бераздан кече Әхмәтҗанов.

— Кит аннан, кайда? — дип гаҗәпләнде Кәрәм.

Шулай итеп, ата һәм аның ике улы безнең фронтыбызда бер дивизиядә булып чыктылар.

Командование Кәрәм Әхмәтҗановка, әтисе һәм энесе белән күрешеп туйганчы сөйләшер өчен, өч көнлек отпуск бирә. Төнне Кәрәм йокысыз уздыра. Ул 1940 нчы елдан бирле күрми йөргән сөекле әтисе белән иртәгә иртән очрашуы турында уйлый.

Элекке колхоз председателе, хәзер батальон командиры урынбасары капитан Гаяз Әхмәтҗанов үзенең кадерле уллары белән үбешеп, кочаклашып күрешә. Беренче көн үткән тормышны, сугышка чаклы булган шатлыклы тормышны искә төшерү белән уза. Ата кеше:

— Әнкәгез Кәнзибану ни хәлдә икән? — дип уйга чума һәм кинәт: — Бүген үк хат языйк, өчәү бергә языйк,— ди.— Алар өчәү бергә икән дип, безнең очрашуга әнкәгез дә куансын, — ди.

Икенче көнне капитан Гаяз Әхмәтҗанов үзенең улларына «сынау» ясап карый. Аларның сугышка ничек катнашулары турында сораулар бирә, хәрби-политик белемнәрен тикшерә. Ул үзе Кызыл Байрак һәм II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары белән бүләкләнгән була, ә улларының күкрәкләрендә бер генә дә бүләк күренми.

— Тырышлыгыгызны, батырлыгыгызны арттырыгыз, улларым, — ди ата. — Мин әле сезнең командирларыгыздан белешеп карармын: начар сугышсагыз, мәңге риза түгелмен. Немецларны шундый кыйнарга кирәк ки, сугыш тәмам булганнан соң, «Алар өчәү иде» дип, Әхмәтҗановлар турында дивизия тарихында укырлык булсын...

Укучы очеркның азагын көтә. Аны язуы авыр. «Азагын полевая почта адресы буенча Кәрәм Әхмәтҗановтан сорагыз, ул сөйләп бирер», диясе килә.

Әлеге очрашудан соң бик каты сугышлар була. Ватанның ялкынлы патриоты капитан Гаяз Әхмәтҗанов үзенең сугышчылары белән иң алгы позициядә торып сугышка катнаша. Пулемет расчеты янына барып, ул күп кенә гитлерчыларны кыра. Аны күреп, безнең сугышчылар искиткеч батырлыклар күрсәтәләр. Ләкин капитан Гаяз сугыштан соң исән калмый: ул корбан була.

Агалы-энеле Әхмәтҗановлар сөекле аталары каберендә ант итәләр, аның кабер туфрагын үбеп, шул туфракка яшь коеп, явыз немецлардан үч алырга ант итәләр.

Изге антның ничек үтәлүен мин Әхмәтҗановларның күкрәкләренә карап белдем. Икәве дә алар орденнар һәм медальләр белән бүләкләнгәннәр. Кәрәм Әхмәтҗанов — хәзерге көнне капитан, батарея командиры. Аның батареясы немецларның 32 танкысын зарарлый һәм 24 пулемет ноктасын юк итә.

Капитан Кәрәм Әхмәтҗанов орудиеләрдән ут ачарга команда биргәндә, авыз эченнән бик еш:

— Әтием өчен дә! — дип әйтеп куя.

1945

МӘРФУГА АПА

Уртача буйлы, янып торган кара күзле, бөдрә чәчле лейтенант Сабир Мифтахов госпиталь ишек алдына килеп керү белән үк бөтен халыкның игътибарын үзенә җәлеп итте. Иң элек кызлар чыр-чу килделәр. Лейтенантның юк кына нәрсәгә дә балаларча үпкәләве, анысын-монысын таләп итүе аларга кызык тоелды. «Ләкин Мифтаховның матурлыгы өчен генә дә аның капризларын онытырга мөмкин», дип уйладылар алар. Докторлар аңарда бик каты бизгәк авыруы таптылар һәм шуның өстенә аның нервлары шактый какшаган булуын белделәр.

Аңа аш керттеләр. Ләкин ул: «Авызда һичбер тәм юк»,— дип ашны кире какты һәм, үзалдына сөйләгәндәй, белен ашыйсы килгәнен белдерде. Озак та үтмәде, аның алдына белен китереп куйдылар. Белен шундый тәмле итеп пешерелгән иде ки, башта кабып кына карарга теләгән Мифтахов ничек ашап бетергәнен дә сизмәде. Мондый беленне ул өйдә генә ашый иде, болай тәмле итеп аның әнкәсе генә пешерә белә иде. Ул, сөекле әнкәсе турында уйлый-уйлый, тыныч йокыга талды.

Тагы берничә көн узгач, ул пәрәмәч ашарга теләде һәм аны монда пешерә алмауларына ышанса да, теләген

докторга белдерде. Кич белән аңа саф татарча пешерелгән пәрәмәч бирделәр. Моңа хәйран калган Мифтахов түзмәде:

— Бу кадәр тәмле итеп кем пешерә? — дип сестрага сорау бирде һәм оста пешерүченең үзен күрәсе, шифалы ашлары өчен аның үзенә рәхмәт әйтәсе килгәнен белдерде...

Палатага өстенә ап-ак халат кигән кечкенә буйлы, елмаеп торган сөйкемле карашлы бер апа килеп керде.

— Менә ул сезгә беленнәр һәм пәрәмәчләр пешерүче кеше, — диде сестра әлеге апага күрсәтеп. — Без аны Мәрфуга апа дип йөртәбез.

Сабир Мифтахов үзенең күзләренә ышанмады. Газиз әнкәсе килә кебек тоелды аңа. Мәрфуга апага ул үз янында урын күрсәтте. Ләкин аларга икәүдән икәүгә генә татарча озак сөйләшеп торырга туры килмәде. Бүтән авырулар да урыннарыннан кузгалдылар һәм:

— Без дә ул пешергән тәмле ашларны ашыйбыз, безнең дә аның белән сөйләшәсебез килә, — диделәр һәм русча сөйләшүне үтенделәр.

— Знам, русский да немножко знам,—дип, Мәрфуга апа үзе дә русча сөйләүгә күчте.

Аңа күп төрле сораулар бирделәр. Аның 60 яшьтә икәнлеген белгәч, фронтта йөрүенә гаҗәпләнделәр.

— Нишләп кайтып китмисең? — диделәр.

Мәрфуга апа Якупова авылда туган, авылда үскән. Аннары Казанга күчеп килгән һәм тегү фабрикасына эшкә кергән. 1931 нче елдан бирле партия члены. Югары сыйфатлы яхшы эше өчен, норманы һәрвакыт арттырып үтәве өчен күп тапкыр премияләр һәм рәхмәтләр алып килгән тегүче Мәрфуга Якупова, күзләре начар күрә башлагач, трампаркка күчә. Шунда ук сугышны да каршы ала.

Аның Салих исемле бердәнбер улы була. Ул сугышка киткәч, Мәрфуга апа, Кызыл Армиягә ярдәм итәргә теләп, госпитальгә эшкә керә. Госпиталь фронтка китәргә булгач:

— Син карт инде, сиңа тынычлык кирәк, бармас идең,— дип, аны калырга үгетлиләр.

Ләкин Мәрфуга апаның мондый сүзләрне ишетәсе дә килми.

— Минем өчен борчылмагыз, яшем 60 ка житеп барса да, мин яшь әле. Яралы улларыма тәмле-тәмле ашлар пешерә алам әле мин, — ди госпиталь начальнигы иптәш Мансуровка.

Шулай итеп, Мәрфуга апа фронтка элэгэ. Апа дим, чөнки ул шундый тере, шундый житез, шулкадәр эшчән ки, һич тә әби диясе килми.

Сабир Мифтахов та, бүтән авырулар да, Мәрфуга апа белән сөйләшкәч, үзләрен терелеп киткәндәй хис иттеләр. 60 яшьлек карчыкның мәхәббәте аларга шифа булып тоелды.

Палатадан чыгып китәр алдыннан Мәрфуга апа авыруларга аналарча жылы караш ташлады һәм:

— Герман башына житмичә кайтмыйм әле, улларым, — диде.

1945

БЕРЛИН ЮЛЫНДА ОЧРАШУ

Без төнлә белән, утларны сүндереп, танкларда бара идек. Алда, таш юлдан бераз уңдарак, ут шәүләсе күренде. Без аңа якынлашкан саен, ут үсә, көчәя, ялкын тасмалары күккә үк сузылалар иде кебек. Тагын бераз бара төшкәч, без моның дөрләп янган бараклар шәүләсе икәнен аңладык.

Шул вакыт жыр ишетелде. Ул, әнә теге ут-ялкын эченнән чыгып, безгә таба килә, танклар шаулавын үтеп, безнең йөрәкләребезгә үк керә иде кебек. Сүзләрен ачык аңлап булмаса да, көе бик таныш көй иде. Озакламый сүзләрен дә аңлый башладык. Каргалган немец жирендә бу сүзләр һәм бу көй безгә тагын да якын булып ишетелделәр.

Илем минем, Москвам минем,
Иң кадерлем син минем...

Командир фараларны кабызырга, танкларны туктатырга кушты. Жыр кинәт өзелде. Алда шатлыктан елау, илерү тавышлары ишетелде.

— Безнекеләр! Без-не-ке-ләр! — дип кычкырды берничә кеше берьюлы.

Болар немец коллыгыннан азат ителгән безнең кызлар булып чыктылар. Алар йөзгә якын иделәр. Башта, әйтәсе сүзләрен әйтә алмыйча, дулкынланган хәлдә, аптырап тордылар.

— Без... без күбәү идек... Меңнән артык идек, — диделәр алар күз яше аша, — инде йөз кеше чамасы гына калдык. Без сезне бик, бик көттек. Ләкин бу шатлыклы көнне күрү бәхетенә ирешә алмабыз, без дә коллыкта үләрбез дип көеп, хәсрәтләнеп яшәдек...

Колонна кузгалып алга китте. Кызлар янында, алар белән сөйләшү, аларга ярдәм итү өчен, бер генә танк калды.

Үлемнән котылып калган бу кызлар арасында мин 17 яшьлек Хәят Тимербулатованы очраттым. Немецлар аны 1942 нче елда Харьковтан алып киткәннәр. Ул чакта аңа 14 яшь булган.

— Әй, абый җаным, бу кадәр хурлыкка, бу кадәр михнәткә ничек түздем икән дип үзем дә гаҗәпләнәм, — дип, Хәят елый-елый тарихын сөйләде.— Башта безне Франциягә озатканнар иде. Андагы заводлар бомбага тотыла башлагач, Польшага, Польшадан Германиягә күчерделәр...

Хәятлар авиация заводында эшләгәннәр. Аларга бик авыр хезмәт нормасы куйганнар. Норманы тутырмыйча, заводтан чыгып китәргә рөхсәт ителмәгән. 14—15 яшьлек Хәятның эш көне 18 сәгатькә җитә торган булган.

Русча сөйләшү бик каты тыелган. Көнлек ризык 200 грамм эрзац икмәктән һәм бака шулпасыннан гыйбарәт булган.

— Юк кына нәрсәне дә сәбәп итеп кыйныйлар иде, — ди Хәят,— «Рус дуңгызлары» дип атап, бездән көләләр иде, кадаклы итекләре белән безне типкәлиләр иде, өстебезгә этләр җибәреп, этләрдән талаталар иде безне...

Мин Хәят Тимербулатованың йөзенә карыйм. Ул тәмам сөяктән генә тора диярлек. Ул 17 дә түгел, 27 дә кебек.

— Каторга хезмәтенә, ач тормышка, авыр хурлыкка түзә алмыйча, — ди ул, — безнең бик күбебез үлеп бетте. Оля Урбанович, Зина Семенова һәм минем белән

бергә Харьковтан алып кителгән Елена Дорогойченко юталгә калып һәлак булдылар. Женя Зинкович бәдрәфтә асылынып үлде. Катя Петрова суга ташланды. Ә немецлар тарафыннан үтерелгәннәрнең исәбенә дә чыгар хәл юк.

Коллыкта газап чигү, көн саен рәнҗетелү Хәятның үзәгенә шул чаклы үткән ки, ул хәзер дә әле үзенең азат булып җитүенә ышана алмый.

— Коллык беттеме инде, абый? — дип сорый ул. — Бөтенләйгәме? Без бөтенләйгә азатмы?

— Бөтенләйгә, акыллым, бөтенләйгә, — дим мин.

— Манечка җаным, ишетәсенме, — дип, Хәят иптәш кызына борыла, аны кочаклап үбә, — без азат, без котылдык. Бөтенләйгә. Таң аткач та илгә кайтып китәбез. Хәзер үк киттекме әллә. Әйдә хәзер. Әткәй-әнкәйләрне шундый күрәсе килә... Төн йокламый очып барыр идем...

Ул тагы үксеп-үксеп еларга керешә.

Безгә озак туктап торырга мөмкин түгел иде. Без, кызлар белән саубуллашып, илгә ничек кайту турында аларга киңәшләр биреп, яңадан изге сәфәребезгә кузгалдык.

Дөрләп янган коллык бараклары да, туган илгә кайтырга хәзерләнгән кызлар да артта калдылар. Безгә аларның:

Илем минем, Москвам минем,
Иң кадерлем син минем... —

дип җырлаган тавышлары гына ишетелә иде.

IV. 1945

ТЕТРӘ, БЕРЛИН!

Мин атаклы танкист Катуков гаскәрләре белән бергә хәрәкәт итәм. Һөҗүм башланыр алдыннан без Варшава янында, Вислада тора идек. Биш көн эчендә, җир өстен чүп-чардан тазартып барган көчле өермәдәй, Позаньга килеп җиттек.

Дошман оборонасы өзелгәч тә, Катуков танкистлары алга ыргылдылар, барлык киртәләрне ватып-җимереп, Берлинга таба юл алдылар. Алар, аргта калган немец гаскәрләрен куып җитеп, кисә-кисә, безнең бүтән частьларыбызга юл арчыдылар. Куркуларыннан акылларын югалткан гитлерчылар карангы төшкәнне көттеләр, танклар төнлә белән бармаслар, туктарлар дип өмет иттеләр.

Ләкин нәфрәт утын сүндереп буламы соң! Совет танкистларының юлын изге теләк яктыртмыймыни!

— Тукталмаска! Фараларны кабызып, алга! — ди генерал.

Мусатов, оста маневр ясап, дошманның алдына чыга, күперне шартлата, аның юлын кисә. Шулай итеп, немецларның 500 гә якын машинасы алга да, артка да бара алмыйча киселеп кала.

Мусатов подразделениесе яңадан алга оча, ә ул кисеп калдырган дошман колоннасын безнең арттан килүче гаскәрләребез трофей итеп алалар.

Без яшен тизлеге белән барабыз. Безнең кайбер подразделениеләребез бер тәүлек эчендә 150 километр юл узалар. Безне туктатырлык көч, куәт юк. Познаньга җитәр алдыннан безгә каршы немецларның 4 танкысы чыкты һәм ата башлады.

— Иптәш командир, рөхсәт итегез дөмектерергә! — диде гвардия кече лейтенанты Сухарев.

— Дөмектер әйдә, ләкин озаклама...

Колонна узып китте, Сухарев немец танкларының эшен бетерергә калды. Өчәвен ул яндырды, берсен кулга төшерде.

Без Шверземга бәреп керәбез. Менә иң яхшы йортларның берсе. Өйдә берәү дә юк. Ләкин ут яна. Өстәл өстендә суынырга өлгермәгән аш тора. Өстәл янындагы урындыкта немец генералының мундиры ята. Кроватьта шинеле, идәндә итекләре. Күрәсең, немец генералы ачялангач сыздырткан!

Познань шәһәренә якынлаштык. Познань зур промышленность шәһәре. Аннан тармак-тармак булып 8 тимер юлы һәм 11 шоссе юлы чыга. Шәһәр тирәсендәге урман эчләрендә «Фокке-вульф» һәм танк заводлары яшеренеп ята. Складлар бик күп.

Познань — поляклар шәһәре. Ләкин немецлар аны үз шәһәрләре итеп хисапларга өйрәнгәннәр. Аңа Бер-

лин алдындагы иң соңгы капка итеп караганнар. Һәм аны саклап калу өчен барлык күперләрне дә шартлатканнар, тирән-тирән чокырлар казыганнар.

Катуковчылар өч урында Варта елгасын кичәләр, дошман уты астында күперләр ясыйлар, шәһәрне читләтеп узып, Берлин юлына чыгалар. Познань божрада калды. Пленга алынган немец профессоры Отто-Мар Брихалер:

— Бүтән профессорлар белән бергә мине, 56 яшьлек картны да, солдат иттеләр. Минем солдат булуым Германиянең җиңелүен күрсәтә,— ди.

Без немец авыллары аша үтәбез, вак-вак шәһәрчекләрен кичәбез. Юллар качарга өлгермәгән немец алпавытларының фургоннары белән тулган. Алар совет танклары астында шытырдап йомычкага әйләнәләр. Коралларын ташлап, кул күтәрергә өлгергән немец солдатлары пленга алыналар. Каршылык күрсәтергә маташканнары шунда ук юк ителәләр.

Совет халкының чиксез көч-куәтен күрсәтеп, аның азатлык һәм бәйсезлек байрагын күтәреп, иң алдан баручы данлыклы танкистлар арасында мин татар халкы улларын да күрәм. Менә II дәрәҗә Ватан сугышы һәм Кызыл Йолдыз орденнары, ике медаль белән бүләкләнгән гвардия капитаны П. Байчурин. Ул үзенең «Летучка»сында оча. Берәр танк зарарлана калса, ул аны хәзер үк төзәтә.

— Мин карап җибәргән танклар Берлинга барып керәчәкләр, кирәк икән, бөтен Германияне айкап чыгачаклар, — ди Байчурин.

Менә ике Кызыл Йолдыз ордены һәм берничә медаль кавалеры гвардия старшинасы Ф. Җиһаншин. Ул — радист.

— Берлинга керүебез турында беренче хәбәрне мин тапшырачакмын, — ди ул.

Менә батыр танкист — гвардия өлкән лейтенанты Б. Хисамов. Командирлар аның турында:

— Кыю, хәйләкәр егет, — диләр.

Мусатовлар, Сухаревлар һәм Хисамовлар белән бергә мәшһүр җырчы Җамбулның оныгы — атаклы танкист Кубис Җумабеков та Берлинга бара. Аның экипажында 4 милләт вәкиле бар. Бу — очраклы хәл түгел. Ерт-

кыч гитлерчылар оясын туздырырга СССР халыкларының мәңге какшамас дуслыгы бара!

Озак көткән, зарыгып көткән вакыт килеп житте. Моннан ике ел элек без Идел янында идек. Ләкин ул чакта да без «Берлин» сүзен кабатлый идек, хәрабәләргә карап авыз эченнән «Берлинга» сүзен әйтә идек.

Идел еракта калды инде. Висла, Варта сулары да кичелде. Без Одер елгасына килеп життек.

Мәскәү, Ленинград шәһәрләрен тупка тоткан немецларны хәтерләп, Берлинга килеп життек без. Ул хәрабәләрне истә тотып:

— Тетрә, Берлин! — дибез.

— Үлем фашистларга! Үлем иблис токымы гитлерчыларга!

Германия, 1945

ЭЧТӘЛЕК

Кайнар көннәр җырчысы. *Г. Минский* 3

ШИГЫРЬЛӘР

Җырлыйм чынын 7
Кояш гыйшкы 8
Күз 9
Биш минутка дөнья туктады 9
*** Комсомолны язам, туктамам 10
Пулеметчылар 11
Көн — кадак 12
Аттылар 13
Моржачы 14
*** Кеше! Бугаз кылың нәзек 15
*** Кызыл күлмәк киеп йөрим 15
*** Яратам мин, яратам 16
Илләр язы 16
Карт пычкычы 17
Кызыл мәйданда 18
Өч игезәк турында хикәя 19
Белмиләр 22
Озату җыры 23
Халык бара 24
Партизанка 25
Батыр каберендә 26
Яңа ел бүләге 26
Яңа частушкалар 27
Иртәнге уйлар 28
Туган ил 29
Талантлар Ватаны (поэма) 30

ХИКӘЯЛӘР, НӘСЕРЛӘР

Кайнар көннәр 42
Солтанның бер көне 44
Вөҗдан газабы 82
Нишләргә 96
Илһам 109

Рәссам 117
Яшен 122
Сагыну 127

Тапшырылмаган хатлар 129

ПУБЛИЦИСТИКА

Рус әдәбиятының Г. Тукайга тәэсире 189
Хәйдәр Фәйзи 195
Академия театрында «Галиябану» 197
Салих Сәйдәшев һәм татар музыкасы 199
Болай ярамый 201
Яза белеп языгыз! 204
Татар сәхнәсендә опера 206
Минем фаҗигам 210
Журналист хатлары 213
Хикәя өстендә эшләү 215
«Давид Сасунлы» 219
Һади Такташ 227
Рус халкының бөек улы 230
Беренче очрашу 233
Совет эпохасының иң яхшы, иң талантлы шагыйре 236
Һәрвакыт истә 250
«Алтынчәч» премьерасында 252
Әдәбият эше — дәүләт эше 254
Ул сугышта үсте 258
Кулләрдән берәү 261
Алар өчәү иде 264
Мәрфуга апа 266
Берлин юлында очрашу 268
Тетрә, Берлин 270

Адель Кутуй

ИЗБРАННЫЕ ПРОИЗВЕДЕНИЯ

(на татарском языке)

Редакторы *С. З. Сибгатуллина*
Художнигы *М. В. Виноградова*
Художество редакторы *Б. М. Альменов*
Техник редакторы *З. А. Ибраһимова*
Корректоры *А. Ш. Зарипова*

Производствога бирелде 12/XI-64 ел. Басарга кул куелды 4/III-65 ел. ПФ 10055. Кәгазь форматы 84×108 1/32. Учетн.-изд. табагы 14,12+рәс. 0,13. Басма табагы 8,63(14,49)+рәс. 0,06(0,11). Тираж 20000 экз. Заказ С-1691. Бәясе тышлыгыннан башка 57 тиен, тышлыгы 10 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19, 1965 ел.

67 тиен

ТАТАРСТАН
КИТАП
НӘШРИЯТЫ
1965